Безнең Мирас

11
ноябрь 2014

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

29 ОКТЯБРЬДӘ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНДӘ САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ИСЕМЕНДӘГЕ ӘДӘБИ ПРЕМИЯЛӘРНЕ ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ.

Наил Сәхапов фотолары

КӨЗ, САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА, «РУХИЯТ»...

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
11(34)
ноябрь 2014

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.

14

62 **ШАГЫЙРЬ ДУСМӘМБӘТ.** *Марсель Әхмәтҗанов*

86

МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ МУЗЕЕНДА РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН МИРАСЫ. *Чулпан Мөслихова*

ЭЧТӘЛЕК

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

3 Бергә булсак — көчлебез!

ТАРИХИ МИРАС

4 **Борынгы Чаллыга тарихи сәяхәт.** *Фаяз Хуҗин*
14 **Мишәрләр.** *Зариф Бәшири*

ДИНИ МИРАС

22 **Яңа татар бистәсе зиратының юл күрсәткече.** *Ильяс хәзрәт Җиһаншин*
26 **Хөрмәткә лаек исем.** *Альмира Таһирҗанова*

ПЕДАГОГИК МИРАС

30 **Әхлак.** *К.Бикколый, Г.Госмани*

ҖИҢҮ — 70!

32 **Бабайларыбызның каберләре кайда — 2.** *Ләбиб Лерон*
36 **Дәһшәтле еллар хатлары.** *Әлфия Шамова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

40 **Сүз һәм сурәт.** *Равил Фәйзуллин*

ТАТАР ГАМЕ

42 **Казан татарлары тормышыннан бер кисәк.** *Ибраһим Бикколов*
46 **«Җырлар чәчтем бакчага...»** *Фәйрүзә Мөслимова*

ӘДӘБИ МИРАС

52 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
56 **Солдат.** *Гаяз Исхакый*
60 **Ике рәсем тарихы.** *Әхтәм Зарипов*
62 **Шагыйрь Дусмәмбәт.** *Марсель Әхмәтҗанов*
68 **Кемдер калыр барыбер сагынып...** *Нәсим Акмал*
74 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*

77 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

78 **«Якутлар табыладыр вакыт белән»**

ХӘТЕР САГЫНДА

84 **Милли музейда күн эшләнмәләре.** *Руфия Мөхетдинова*
86 **Милли мәдәният музеенда Ризаэддин Фәхреддин мирасы.** *Чулпан Мөслихова*
88 **Кыштым афәте.** *Александр Филиппов*

ТАБИГЫЙ МИРАС

94 **Мөслим төбәге.**

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

98 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*
102 **Әткәм-әнкәм, балам-оныгым теле.**

100 ЕЛ ЭЛЕК

106 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның ноябрь ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

110 **Көлке көлә килә, артыңнан куа килә...** *Рабит Батулла*

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Ноябрь*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Техник хезмәткәр
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №А-2912. **Тираж** — 1548 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 5.11.2014
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән һәм Абдулла Дубин, авторларның архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Казан. Ушков йорты». Кәгазь, акварель. 2005 ел.
И.Айдаров рәсеме.

БЕРГӘ БУЛСАК – КӨЧЛЕБЕЗ!

Кадерле каләмдәшләр, мөхтәрәм галимнәр, мөгаллим-мөгаллимәләр, милли җанлы укучыларыбыз!

Төп таянычыбыз да, өметле ышанычыбыз да — сез, тугры дусларыбыз!

«Безнең мирас»ны яратып укыйсыз икән, димәк, сез — безнең абунәчеләребез. Киләчәктә дә журналыбызның иң якын кешеләре, газиз юлдашлары булырсыз, дип ышанам.

Бездә — яңалык: сайтыбыз www.beznenmiras.ru ачылды! Димәк, теләге булган һәркем сайт аша кызыклы сәхифәләребез белән таныша алачак. Анда фәһемле, затлы, гыйбрәтле язмалар, иң яхшы, иң кадерле хәзинәбездән матур-матур үрнәкләр, мирасыбызга кагылышлы, журналханәбезгә турыдан-туры бәйле булган аудио һәм видео язмаларга да урын түрдән булачак.

Кыскасы, мөхтәрәм вә газиз милләттәшләр, «Безнең мирас»тан аерылмагыз, тугры юлдашыгыз булырга һәрчак әзербез. Алдагы елларда да бергә булыйк, бердәм булыйк!



БОРЫНГЫ ЧАЛЛЫГА ТАРИХИ СӘЯХӘТ

Фаяз Хуҗин,
Татарстан Фәннәр Академиясе мөхбир әгъзасы, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр Академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институтының урта гасырлар археологиясе бүлеге мөдире



1973 елда Мәскәүдә чыга торган «Советская археология» журналында борынгы болгар тарихи истәлекләрен бик җентекләп өйрәнеп, тикшеренү нәтиҗәләрен киң халык арасында пропагандалау өлкәсендә активлык белән эшләүче галимебез **Равил Фәхретдиновның** Казан ханлыгы чоры археологиясен киләчәктә киң колач белән тикшерү кирәклеген фәнни нигезләгән мәкаләсе басылып чыкты[1]. Шуннан соң кырык елдан артык вакыт үтеп китте. Нинди казанышларыбыз бар соң татар халкының ханлык чоры археологиясен һәм тарихын өйрәнүдә?

Әлбәттә, галимнәр бөтенләй үк кул кушырып утырмады, әмма дә, дөресен әйтик, әллә ни мактанырлыгыбыз да юк. Тарихчылар бүген дә фәнни кыйммәтен югалтмаган мәгълүм китабын[2] 1923 елда ук бастырып чыгарган **Михаил Худяков** концепциясеннән һаман да ерак китә алмый әле. Ни кызганыч, Казан ханлыгы тарихы белән махсус шөгыльләнүче белгечләребез дә юк.

Археологлар исә, Казан кремлендә казу эшләре барган чорда, бераз тырышып-талпынып алды анысы: борынгы каланың саклану ныгытмалары, Хан сарае комплексына караган таш бина хәрабәләре, **Кол Шәриф мәчете** нигезе табылды[3], ханнар төрбәсе казып тикшерелде[4], музей фондларына XV гасырның икенче яртысына — XVI гасырларга караган әллә никадәр кыйммәтле табылдыклар тапшырылды[5]. Әмма ханлык чоры археологиясе Казан кремле белән генә чикләнми. Бүгенге көндә шул чорга караган 700дән артык авыл һәм кала урыннары билгеле. Аларның бер өлеше төрле документларда, бигрәк тә Писцовый кенәгәләрдә телгә алына. XV-XVI гасыр кабер ташларын, төрле елларда табылган акча хәзинәләрен дә кушсаң, ханлык чоры археологик истәлекләренең саны 800дән артып китә. Тикшерелү дәрәҗәсе ничек аларның?

Исемнәре елъязмаларда теркәлеп калган, риваять-легендаларда чагылыш тапкан **Иске Казан, Өтернәс (Мишә-Тамак), Җөри, Алат, Арча, Лаеш, Тәтеш, Алабуга** ише калаларның берсе дә археологлар тарафыннан юньләп өйрәнелмәгән. Сәбәпләре төрле. Казан ханлыгы һуннар, Төрки каганатлары чорында ук формалаша башлаган меңьеллык төрки-татар цивилизациясенең сүнеп бару чорына карый. Урта гасырлар цивилизациясенең төп билгеләреннән берсе булган шәһәрләр Казан ханлыгында да булган, әлбәттә, әмма алар азсанлы һәм Болгар, Алтын Урда заманнарындагы кебек зур һәм бай түгелләр. Хәтта каласының (кремльнең) мәйданы 10, һөнәрчелек бистәләренеке 150-200 гектар чамасы булган ханлык башкаласы Казанда да XVI гасыр урталарында халык саны 7-10 мең кешедән артмаган. Югарыда санап үтелгән Тәтеш, Алат, Лаеш, Арча, Алабуга һәм башка шундый тарихи торак пунктларын Казан ханлыгы шәһәрләре рәтенә кертеп буламы? Шикләнәм, һәрхәлдә,

---

[1] Фахрутдинов Р.Р. Задачи археологического изучения Казанского ханства // Советская археология. — 1973. — №4. — 133-122 б.

[2] Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1923 (репринт басмасы академик М.Г. Госманов сүз башы белән 1990 елда чыкты); күптән түгел әлеге китапның татарчага тәрҗемәсе дә дөнья күрде: Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар // Михаил Худяков. Тарихи-документаль җыентык. — Казан: «Җыен» нәшрияты, 2011. — 16-381 б.

[3] Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. О локализации в Казанской крепости исторической мечети Кул Шарифа // Гасырлар авазы. — 2005. — №2. — 10-23 б.

[4] Мавзолеи Казанского кремля. Опыт историко-антропологического анализа. — Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 1997.

[5] Хузин Ф.Ш., Ситдиков А.Г. Некоторые итоги археологического изучения Кремля ханской Казани (по материалам раскопок 1994-2005 гг.) — Российская археология. — 2009. — №1. — 99-111 б.

соравым әлегә җавапсыз кала. Археологлар көрәк төрткән Арча, Алабуга, Өтернәс кебек калаларның культура катламнары калын түгел һәм табылдыкларга да ярлы. Аннан соң шунысы да бар: Казан ханлыгы чорында яшәгән һәм яңа барлыкка килгән торак пунктлар шул ук урында яшәүләрен бүген дә дәвам итә. Димәк, борынгы катламнар төзелеш һәм хуҗалык эшләре вакытында җимертелә, табылдыклар юкка чыга, нәтиҗәдә, археологларның

Шул елны Владимир-Суздаль кенәзе Всеволод Зур Оя Киев, Рязань, Муром, Переяславль, Смоленск кебек шәһәрләрдән җыелган күп санлы гаскәре белән болгарларның башкаласы Биләргә – Олуг шәһәргә яу чаба.

эшләре тагын да катлаулана һәм алар мондый истәлекләрне казырга бер дә ашкынып тормый.

Мисал өчен мин исеме урыс елъязмаларына беренче мәртәбә 1496 елгы вакыйгалар уңаеннан кереп калган Арча каласында үткәрелгән археологик казуларга тукталып үтәм. Безнең мәгълүматларга караганда, Арча, мәйданы артык зур булмаса да, бик көчле ныгытылган кала булган. Казан тәхетендә бер ай чамасы гына утырырга өлгергән Мамук хан 1496 елда үзенең гаскәре белән Арчага яу чаба. Халыкны талап баю максаты белән килгән ханны сакчылар калага кертми. Мамук, биек манаралы көчле крепостьне күрүгә үк, арчалыларга каршы һөҗүм башлау ниятеннән баш тарта һәм гаскәрен кире Казан юлына бора.

1552 елда каланы Явыз Иван гаскәрләре камап ала. Шул чорларның шаһиты — кенәз һәм воевода **Андрей Курбский** үзе күргәннәрен кыскача гына болай тасвирлый: *«Дворы княжат их и вельмож зело прекрасны и воистину удивления достойны»*[6]. XVI гасырның икенче яртысында язылган «Казан тарихы»нда Арча крепосте турында мондый сүзләр бар: *«Острог тот старый, называемый Арским, построен словно укрепленный город: и с башнями, и с бойницами, и людей живет в ней много, и хорошо его охраняют. И не был он ни разу взят — ни в одном бою»*[7].

Менә шул каланы археолог **Альберт Борханов** 1996 елда, ә Татарстан Фәннәр Академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты археологлары **Айрат Ситдыйков, Зөфәр Шакиров** һәм мин фәкыйрегез 2006-2008 елларда казып тикшерде. Кызганыч ки, борынгы каладан бүгенге көндә берни дә калмаган диярлек. Аз гына элегрәк тотынырга кирәк булган икән бу эшкә. Соңгы елларда Арча крепосте урнашкан 2,4 гектар чамасы җирдә ике-өч катлы административ биналар үсеп чыккан. Ә бит район җитәкчеләре биредә борынгы истәлек барлыгын белеп торган. Шул биналарны төзү алдыннан өйрәнергә кирәк булган икән ул Арчаның борынгы тарихын! Шулай да иске крепость территориясенең җимертүләрдән сакланып калган кечкенә генә бер участогында казулар үткәрдек (районның ул чактагы җитәкчесе **Алмас Әмин улы Нәзировның** фатихасы һәм финанс ярдәме белән). Нәтиҗәләр: иң борынгы табылдыклар XII-XIII гасырларда тупланган катламда очрады; Алтын Урда заманында сугылган акчалар бар (XIV гасыр акчасы Арчадан ерак түгел Бужа авылы тирәсендә урнашкан болгар авылы урынында да табылды); табылдыкларның күп өлеше, әлбәттә, Казан ханлыгы чорына карый[8].

[6] Казанская история // Памятники литературы Древней Руси. Вторая половина XVI века / сост. и общая ред. Л.А.Дмитриева и Д.С.Лихачёва. — М.: Художественная литература, 1986. — 235 б.
[7] Казанская история // Памятники литературы Древней Руси. Середина XVI века / сост. и общая ред. Л.А.Дмитриева и Д.С.Лихачёва. — М.: Художественная литература, 1985. — 481 б.

Өтернәс каласында да шул ук хәл: культура катламы юк дәрәҗәсендә, табылдыклар да санаулы гына[9].

Лаешның көньяк-көнчыгыш ягында урнашкан һәм фәндә «Чакма» исеме белән билгеле зур гына болгар-татар авылы урыны бар. X-XIV гасырларда биредә тормыш гөрләп торган. Халык башлыча һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнгән. Лаешның Казан ханлыгы чорына караган тарихын өйрәнү өчен тикшеренүләр үткәрмәкче идек, әмма ниятебезне тормышка ашыра алмадык: шәһәрнең нәкъ шул чорга караган өлеше Куйбышев сусаклагычы астында калып юкка чыккан.

Тәтештә, шәһәрнең төньяк читендә, соңгы елларда Мәдәният һәм сәнгать университеты профессоры, археолог **Константин Руденко** бик активлык күрсәтеп эшләде. Тик ул казыган шәһәрлекнең — ә анда табылган иң борынгы табылдыклар VI гасырга, ягъни Төрки каганлыгы чорына карый — бүгенге Тәтеш белән бәйләнеше әлегә ачыкланмыйча калды[10]. Минемчә, Тәтешкә монголларга кадәрге болгарлар X-XI гасырлар тирәсендә нигез салган. Алтын Урда чорына караган табылдыклар да күп очрый, әмма шәһәрнең Казан ханлыгы чорындагы тарихы билгесез булып кала бирә. Димәк, биредә казу эшләрен дәвам итәргә кирәк әле.

Ниһаять, сүз башым бит шүрәле, дигәндәй, мәкаләмдә киңрәк сөйләргә теләгән **Чаллы каласына** да килеп җиттек.

Ул республикабызның **Балык Бистәсе** районында урнашкан. **Котлы Бөкәш** белән **Тәберде Чаллысы** авылларыннан ерак түгел **Шомбыт** һәм **Мәшләк** елгалары кушылган урында, биек тау башында. Элеккеге **Нугай юлы** өстендә.

Тәберде Чаллысы, Котлы Бөкәш авыллары турында минем элегрәк тә ишеткәнем бар иде. Хәләл җефетем **Чистай** якларыннан, ә биредә **Хәлфә бабайны** белмәгән кеше юк икән. Хан заманнарында яшәгән бер Изге, авыруларны сихәтләндерә, киләчәкне әйтеп бирә торган әүлия, сәләт иясе, дип сөйләгәннәре хәтердә. Хәлфә бабай чишмәсе — Изге чишмә! — Котлы Бөкәш авылы читендә. Үзе дә шушы авылда яшәп мәңгелеккә күчкән. Кабере — авыл зиратында. Бик кадерләп, саклап торалар.

Ниһаять, борынгы Чаллыны үземә дә күрү насыйп булган икән. Алай гына да түгел, хәтта ярыйсы гына уңышлы тәмамланган казу эшләре дә үткәрергә туры килде миңа биредә.

---

[8] Шакиров З.Г., Ситдиков А.Г., Хузин Ф.Ш. К ранней истории города Арска // Арск и Арская земля: актуальные проблемы изучения историко-культурного наследия. — Казань: Ин-т истории АН РТ, 2010. — 5-15 бб.; Некоторые итоги археологических исследований на территории Арского городища в 2006—2008 гг. // Шунда ук, 24-30 бб.

[9] Бурханов А.А. Археология Казанского ханства: история изучения, итоги последних исследований и перспективы. — Казань, 2002. — Б.9.

[10] Руденко К.А. История изучения археологических памятников в г.Тетюши // Материалы и исследования по средневековой археологии Восточной Европы. — Казань: Школа, 2009. — 45-65 бб.

Котлы Бөкәш урта мәктәбе укучылары антрополог Илгизәр Газимҗанов җитәкчелегендә археологик казу эшләре вакытында. 1997 ел

...1993 елның җәй башында мине институт бинасында Балык Бистәсе якларыннан килеп, Биектау районының Дачный посёлогы урта мәктәбендә физика-математика укытучысы булып эшләүче **Нурулла Гариф** исемле егет эзләп тапты һәм шунда ук Чаллы шәһәрлеге, аңа юкка чыгу куркынычы янавы, шуңа күрә, кичекмәстән, аз булса да казып-тикшереп калу кирәклеге турында сөйләп китте:

— Равил абый Фәхретдинов белән сөйләшкән идем, район башлыгы белән килеп тә киттеләр Бөкәшкә, тик, нигәдер, шәһәрлеккә үк барып тормадылар. Аннан соң аны бүтән күрә алмадым. Телефоннан сөйләшкәндә генә бу мәсьәлә буенча аны башка борчымаска сорады. Бөтен өмет синдә, Фаяз абый.

Ризалаштым. Институтыбыз директоры **Мирфатыйх Зәкиев** безнең теләккә каршы килмәде, рәхмәт төшкере, әмма экспедициягә бер тиен дә акча юк, дип кисәтеп куйды. Аллага тапшырып, чыгып киттек, аркага катомкабызны асып. Һәм дөрес эшләдек. Район җитәкчесе **Хатыйп Фатыйх улы Газизов** Нурулла Гариф тарафыннан кисәтеп куелган икән, ярдәме зур булды. Экспедициябезне мәктәп интернаты бинасына урнаштырдылар, авыл советы рәисе **Габделбәр** ага **Вәлиев** азык-төлек белән тәэмин итеп торды. Казаннан үзебез белән алып килгән мәктәп укучыларына булышырга Котлы Бөкәшнең тагын бер изге заты — тарих укытучысы **Кәримулла** ага **Ахунов** авыл балаларын да алып килде. Тиздән безнең төркемгә Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан археолог **Айрат Гобәйдуллин**, антрополог **Илгизәр Газимҗанов**, тарихчы **Гамирҗан Дәүләтшин** килеп кушылды. Хәтта үзенең студентлары белән Алабуга педагогия институтыннан археолог **Альберт Нигамаев** та килеп җитте. Эшләребез гөрләп барды.

...Менә без, бер төркем археологлар, тау башында, борынгы шәһәр урынында басып торабыз. Күр инде, нинди гүзәл табигатьле урынны сайлаганнар шәһәр кору өчен! Түбәндәрәк, көньяк һәм көнбатыш тарафта, чәчәкле болынлыклар җәйрәп ята. Аннан ары-

рак урман башлана. Тирә-юньдә, без басып торган биеклектән 7-8 чакрымлап та булмас, бер-берсенә терәлеп диярлек урнашкан зәңгәр мәчетле татар авыллары күренеп тора. Өстәвенә чишмәле як та икән әле бу! Чылтырап агып яткан чишмәләрнең кайберләрен **«Изгеләр чишмәсе»** дип атыйлар. Берсе аның **Кала-тау** куенынннан бәреп чыккан.

Әйе, тирә-юнь халкы әлеге шәһәрлекне Кала-тау дип кенә йөртә. Биредә кайчандыр болгар бабаларыбыз яшәгән, дип сөйлиләр. Авыл картлары исә, җай чыккан саен, без бәләкәй чакларда ул тирәләрдән ук һәм сөңге очлыклары, сугыш балталары, хатын-кызларның бизәнү әйберләре, чүлмәк китекләре һәм дә бик күп кеше сөякләре таба идек дип, әңгәмәдәшләренә кызыклы гына мәгълүматлар җиткерәләр. Берничә йөз еллар элек, әле хан заманнарында ук, зур сугыш булган монда, шул вакытларда җимертелгән кала түгелме икән дип, шикләнеебрәк булса да, үзләренең фаразларын да әйтеп куялар.

Без басып торган җирдән элек кирмән диварлары үткән. Шәһәрнең кремле, ягъни Кала-тау, төньяк-көнчыгыш тарафтан, басу ягыннан, дүрт кат ныгытмалар белән уратып алынган. Аның мәйданы алай зур түгел, бер гектардан аз гына артыграктыр, әмма болгар-татар археологиясендә шулай көчле ныгытылган калалар бик сирәк. Бу яктан караганда, Чаллы крепостен урта гасырлар тарихының уникаль истәлеге, дип атарга нигез бар. Биредә, һичшиксез, **Чаллы ханы** һәм аның хезмәтчеләре яшәгән, кечкенә хәрби гарнизон урнашкан булган. Биек манаралы мәчете дә, әлбәттә, тирә-юньне балкытып, ерактан ук күренеп торгандыр.

Шәһәр ныгытмаларына терәлеп диярлек урнашкан һөнәрчелек бистәләренә таба атлыйбыз. Борынгы Чаллының төп халкы — һөнәрчеләр, эреле-ваклы сәүдәгәрләр — биредә яшәгән. Аның территориясе кремльнекенә караганда күпкә зуррак — 60 гектар гына да түгелдер. Парга калдырылган иген басуы өстендә чүлмәк китекләре, кеше һәм хайван сөякләре аунап ята, берәнсәрән генә булса да, тимердән, бакырдан һәм сөяктән эшләнгән әйберләр очраштыргалый. Менә бу борынгы зират урыны бугай. Тирән чокыр янында, тау кадәрле чүп өеме белән янәшәдә генә, каберлек эзләре күренеп тора. Казып карарга кирәк булыр, дигән карарга киләбез.

Безгә мәгълүм чыганакларга караганда, Чаллының икенче зираты, беренчесеннән күпкә зуррагы, моннан бераз арырак, төньяктарак булырга тиеш. Барыбыз да шунда юнәләбез. Биредә колхозның машина-трактор паркы һәм ындыр табагы урнашкан. Ашлык саклау складлары, гаражлар, ремонт мастерскойлары — санап бетерерлек түгел аларны. Барысы да борынгы бабаларыбызның зираты өстендә утыра...

Тагын бер зираты бар борынгы Чаллының. Авыл ягыннан тауга күтәрелгәндә сул якта кала ул. Биредән авыл халкы, хуҗалык кирәкяракларына дип, кызыл балчык казып ала — инде кечкенә генә бер карьер да хасил булган. Кеше сөякләрен бер читкә алып ташлыйлар да, казуларын дәвам итәләр. Актарыла инде каберләр, балчыгы кирәк булгач, нишлисең? Авыл халкы шулай уйлый.

Әйе, Нурулла абзагыз дөрес әйтә: һич кичекмәстән өйрәнеп калырга кирәк бу каланы. Юкка чыгачак ул, дөньялар болай барса...

Һәм без эшкә тотындык.

Биредә мин, артык мактануларга урын калдырмыйча, шуны әйтеп үтәргә тиеш: без Чаллы шәһәрлегенең тарихи әһәмиятен, чын кыйммәтен аңлап, аны фәнни яктан өйрәнә башлаган беренче археологлар түгел. Аның турында әле XIX йөз галимнәре, шул исәптән, татар зыялылары да кызыклы гына язмалар калдырган. Шулар арасыннан мин, беренче чиратта, шушы төбәк кешесе,

Күгәрчен авылы мулласы **Бикмөхәммәд Зәетовны** атар идем. Ул 1884 елда Казан университеты каршындагы **Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте** чыгара торган **«Хәбәрләр»** журналында Чаллы каласы турында күләмле генә мәкаләсен бастыра. Биеклеге 4-5 метрга җиткән кремль ныгытмаларын, 8 метр киңлектәге тирән чокырларын, шәһәрлектә һәм аның тирә-юнендә табылган күп санлы борынгы әйберләрне ул профессиональ осталык белән тасвирлап биргән[11]. Заманында менә нинди муллаларыбыз булган безнең! Авыл җирендә бит әле ул! **Н.А.Толмачёв, И.А.Износков** кебек урыс галимнәре дә язганнар Чаллы турында, әмма дә аларның язмалары сыйфат һәм фактлар байлыгы ягыннан Б.Зәетовныкына караганда күпкә кайтышрак.

Беренче казу эшләрен биредә 1955 елда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты археолгы, күренекле галим **Н.Ф.Калинин** үткәрә. Аның фикеренчә, Чаллы ул — Казан ханлыгындагы иң эре шәһәрләрнең берсе, XIV-XVI гасырларда яшәгән феодал кенәзлекнең административ-сәяси үзәге.

Бу фикерне шәһәрлектә 1983 елда эшләгән Казан археологлары **Н.А.Кокорина** белән **С.В.Кузьминых** һәм 1989 елда Ижаудан килеп казыган **Удмуртия дәүләт музее** археологы **Т.И.Останина** яңа фактлар белән раслады. Әлеге археологлар Чаллы каласының барлыкка килү вакытын XIII гасыр белән билгеләделәр, кайбер табылдыкларның хәтта монгол яуларына кадәрге чорга караган булуын әйттеләр.

Кызганыч ки, бу материалларның берсе дә фәнни яктан җентекләп өйрәнелмәде, экспедиция нәтиҗәләре турында гыйльми басмаларда бер генә мәкалә дә күренмәде. Җитмәсә, 1955 елгы экспедиция коллекциясе тулысы белән сакланмаган булып чыкты, ә 1989 елгы табылдыклар **Ижауга** китеп барган. Кыскасы, Чаллы һәм шул төбәкнең тарихы әлегә язылмаган, ә бу тарихны өйрәнмичә торып, халкыбызның урта гасырлар чорына караган тарихын да тулысы белән, дөрес итеп күз алдына китереп булмаячак иде. Алга китебрәк булса да әйтеп үтәргә кирәк табам: үзебезнең экспедиция материалларын да, архивтан Н.Ф.Калининның отчётларын табып, аларны да, Н.А.Кокорина, С.В.Кузьминых һәм Т.И.Останина казылмаларыннан чыккан материалларны да, шуларга өстәп Б.Зәетов, Н.А.Толмачёв һәм И.А.Износков язмаларын — барысын бергә туплап, 2000 елда **«Борынгы Чаллы. Древние Чаллы»** дигән матур гына китап чыгардык[12].

Безнең экспедиция үз алдына бик гади һәм барыбызга да аңлаешлы максат куйды: инде җимерелеп бетүгә йөз тоткан шәһәрлектән археологлар өчен нинди мәгълүмат калган, шуны алырга да, табылдыкларын булдыра алганча җентекләп өйрәнеп, **Котлы Бөкәш мәктәбе музеена** тапшырырга. Халкыбыз тарихы аның үзенә кайтарылырга тиеш!

Хуш, нинди ачышлар белән куандырдык инде без беренче көннән үк казылмаларга ташкын булып агылган һәм үзенең тарихына бер дә битараф булмаган авыл халкын?

Казу эшләрен шәһәр ныгытмаларының тышкы ягында, ягъни гади һөнәр ияләре яшәгән бистә территориясендә башлап җибәргән идек. Казылмаларны әкренләп киңәйтә барып, каланың тышкы ныгытмаларын да эләктереп

[11] Заитов М.Б. О Чаллынском городище в Лаишевском уезде близ дер. Чаллы Шумбутской волости // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. — Казань, 1884. — Т.III. — 277-280 бб.

[12] Борынгы Чаллы. Древние Чаллы / отв. ред. Ф.Ш.Хузин, сост. Н.Гариф. — Казан: Мастер Лайн, 2000. — 320 б.

[13] Бахтин А.Г. XV-XVI века в истории Марийского края. — Йошкар-Ола, 1998. — Б.150.

алу иде исәбебез. Культура катламы соңгы елларда бик нык җимертелгән булса да, борынгы корылмаларның тирәндәрәк яткан өлешләре ярыйсы гына сакланган булып чыкты. Беренче табылдыклар — савыт-саба китекләре, хайван сөякләре һәм... XIV гасырда сугылган Алтын Урда акчасы — башлаган эшебезнең уңышлы тәмамланачагына өметләндерде. Менә шифер дип аталган йомшак шәмәхә таштан ясалган орчык башы — бусы X-XII гасырларда **Киевтан** ерак түгел генә урнашкан **Овруч** исемле борынгы рус шәһәрендә эшләнгән. Бронзадан асылмалы шар формасында коелган матур гына бизәнү әйбере — XI гасырда яшәгән болгар кызлары аларны бик яратып түшләренә, яисә бил каешларына тагып йөрткән.

Әзләре сакланып калган борынгы корылмалар арасыннан иң кызыклысы, әлбәттә, торак йорт урыны һәм аның янәшәсендә генә урнашкан һөнәрче остаханәсе иде. Биредә, һичшиксез, сөякне кисеп-шомартып пычак саплары, бала-чага уенчыклары, шахмат-шашка фигуралары һәм башка шундый вак-төяк әйберләр ясаучы оста эшләгән. Табылдыклар арасында махсус пычкы белән киселгән, әле шомартыла гына башланган болан мөгезләре, тимер безләр, пычаклар очрый, йорт нигезеннән исә сердоликтан һәм пыяладан ясалган муенса төймәләре, каеш прәшкәсе, йозак ачкычы килеп чыкты. Аларның бер өлеше бары тик монгол яуларына кадәрге чорда гына кулланылышта булган, икенчеләренең исә төгәл датасы бар — XI-XII гасырлар.

Моңа кадәр фәнни әдәбиятта Чаллы шәһәре һәм аның тирәсендәге авыллар Алтын Урда чорында гына барлыкка килә һәм Казан ханлыгында югары үсешкә ирешә, дигән караш өстенлек итеп килде. Чынбарлыкта исә болгар бабаларыбыз бу якларга моннан ким дигәндә 800-900 еллар элек килеп утырган булып чыга. Ныклабрак тикшерсәң, тагын да борынгырак истәлекләргә юлыгырга мөмкиндер, дип уйлыйм. Борынгы рус елъязмаларында да Чаллы кешеләре турында моннан 830 еллар элек, ягъни 1183 елда язылган хәбәрләр сакланган ич.

Шул елны **Владимир-Суздаль** кенәзе **Всеволод Зур Оя Киев, Рязань, Муром, Переяславль, Смоленск** кебек шәһәрләрдән җыелган күп санлы гаскәре белән болгарларның башкаласы Биләргә — Олуг шәһәргә яу чаба. Башкалабызның язмышы куркыныч астында, дигән хәбәр тиз арада илнең төрле төбәкләренә тарала. Биләргә ярдәм йөзеннән **Чулманга** якын утырган җирләрдә яшәүче болгарларның сабакүл (саба), челмат (чаллы), темтюзи (тәмте) исемле төркемнәре, 5 меңләп ир-аттан торган гаскәр туплап, урысларның корабларын, азыктөлекләрен сакларга калдырган отрядларына һөҗүм итә. Әлеге вакыйга

Хафиз Гәрәй хакимлек иткән дәвердә Чаллы белән Казан арасында сугыш башлана.

уңаеннан елъязмачы тарафыннан телгә алынган челматларны галимнәр берсүзсез «Чаллы кешеләре» дип укырга тәкъдим итә. Шулай икән, болгарларның хәзерге Чаллы төбәгенә килеп утырулары XII гасырга гына да түгел, бәлки, археологик материаллар күрсәткәнчә, тагын да борынгырак чорга карый булып чыга.

1994 елда безгә тагын бер урында, төньяк-көнчыгыш яктагы шәһәр яны бистәсен каладан аерып торучы тирән чокыр янында казырга туры килде. Беренче катлам җирен алырга да өлгерә алмадык, алдыбызда XV-XVI йөзләргә караган тимерче алачыгының ярыйсы гына сакланган эзләре пәйда булды. Әлеге корылманың мәйданы якынча 3х3 метр булган. Кирпеч ватыклары, кызыл балчык аралаш көл катламнары биредә тимер кыздыра торган учак

булганлыгына ишарәли. Кая карама — тимер-томыр кисәкләре. Зур гына бер чокырны агач күмере саклау өчен файдаланганнар. Тимер әйберләрдән ат дагасы, пычак, кадак, йозак ачкычлары ише әйберләр очрады.

Казылмаларыбыз арасында тирә-юнь халкы арасында иң зур кызыксындыру тудырганы, әлбәттә, **Алтын Урда** һәм **Казан ханлыгы** чорына караган борынгы зират иде. Антрополог **Илгизәр Газимҗанов** биредә ике дистәгә якын каберлек өйрәнде. Ул заманнарда мөселман бабаларыбыз мәетне агач табутка салып, ләхет алмыйча гына күмә торган булганнар. Тикшерелгәннәре арасында бала-чага каберләре күп иде. Якынча исәпләүләргә караганда, кешеләрнең уртача гомер озынлыгы **32-35** яшьтән артмаган. Хатын-кызлар ирләргә караганда да кыскарак гомерле булганнар. Халкыбызның килеп чыгышын өйрәнүдә антропологик материаллар тарихи чыганакларның иң әһәмиятле өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә, Чаллының борынгы зиратларын әле киләчәктә дә өйрәнергә туры киләчәк.

Каланың саклану ныгытмаларын озак еллар инде болгарларның фортификация корылмаларын өйрәнүче галимебез **Айрат Гобәйдуллин** махсус тикшерде. Казылмалар күрсәткәнчә, иң әүвәл, XII гасыр ахырларында булса кирәк, биредә нигезе таш-балчыктан торган бер метр чамасы биеклектәге вал өяләр һәм аның өстенә, юан бүрәнәләрне бер-берсенә терәтеп, агач койма утыртып куялар. Соңрак бу ныгытмаларны ике тапкыр төзекләндерәләр. XVI гасыр урталарында, мәсәлән, өсте таш белән тышланган балчык үрләрнең биеклеге 5-6 метрга кадәр җиткән була. Үр өстендә имән бүрәнәләрдән җыелган агач стеналар торган. Алары инде сакланмаган, эзләре генә сизелеп тора. Юка гына күмер катламы һәм берән-сәрән очраштыргалаган тимер ук очлары — Кала-тау диварларының фаҗигале язмышы турында сөйләүче бердәнбер шаһитлар.

...XV гасыр ахырларында-XVI гасыр башларында Чаллы шәһәре нык үсә, халык саны арта, һөнәрчелек һәм сәүдә алга китә. Чаллы бәге **Хафиз Гәрәй** көтмәгәндә Казан ханының җитди көндәшенә әверелә һәм үзен хәтта мөстәкыйль хан дип игълан итә. Хафиз Гәрәй хакимлек иткән дәвердә Чаллы белән Казан арасында сугыш башлана. Сугышның икенче елында ук Казан ханы Чаллыны ала, шәһәр ныгытмаларын җимереп ташлый, Хафиз Гәрәй исә гаиләсе белән Бохарага качып котыла.

Халык арасында таралган риваять кенә бу, әмма ул реаль фактларга, вакыйгаларга нигезләнгән булырга охшый.

Чаллының соңгы көннәре серләр пәрдәсенә күмелгән. Безнең фикеребезчә, югарыда сөйләнгән вакыйгалардан соң хәрабә хәлендә озак ятмагандыр ул. 1552 елда Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап алгач, мөстәкыйльлекләрен югалтырга теләмәгән татарлар Ватан сугышына күтәрелә. Чаллы каласын тиз арада яңадан торгызалар һәм ул баш күтәрүчеләрнең урыс баскынчыларына каршы көрәш үзәгенә әверелә.

Соңгы елларга кадәр күп кенә тарихчы галимнәр, Чаллы тәхетенә **Сөембикә**-ханбикәнең энесе **Али Әкрәмне** утыртып куялар, Казан ханлыгы Чаллы нигезендә яңадан торгызыла, дип яза иделәр. Тик бу фикер тарихи документлар белән расланмаган булып чыкты[13]. Чаллы халкы урыс баскынчыларына каршы, һичшиксез, көрәшкән. Бусы шик тудырмый. Билгеле булганча, 1556 елның язында Явыз Иван баш күтәрүчеләргә каршы махсус гаскәр җибәрә. Алар Чаллыны басып ала һәм яндыра, халкының күп өлешен кырып бетерә. Шәһәр яшәүдән туктый.

***

Миңа күптән түгел генә күренекле шагыйребез Равил абый Фәйзуллин һәм «ТАТМЕДИА» ААҖнең генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева җитәкчелегендәге бер төркем

Галим Фаяз Хуҗин Чаллы шәһәрлеге турында тәфсилләп сөйли...

татар зыялылары белән яңадан борынгы Чаллыда булырга туры килде. Шәһәр калдыкларын бергәләп карадык, үземчә экскурсия үткәрдем аларга. Әмма сизеп торам, Чаллы турындагы уйларым уйланып, фикерләрем әйтелеп бетмәгән икән әле. Казан ханлыгы чоры шәһәрләре бүгенге көнгә кадәр бик начар сакланган, бөтенләй диярлек җимерелеп беткән, дип искәртеп киткән идем югарыда. Чаллы шәһәре сакланган менә! Җимертүләр күп, әлбәттә. Нишлисең, тормышның үз кануннары, үз таләпләре була шул. Элегрәк язылган бер мәкаләмдә, халкыбызның кыйммәтле мирасын кадерләп саклый белмисез, Кала-тауның зиратларына кадәр актарып ташлагансыз дип, Бөкәш һәм Тәберде халкына үпкә белдергән идем. Бүген менә, ярый әле, ханлык заманнарыннан ук безнең көннәргә кадәр килеп җиткән тарихи һәйкәлләребез арасында Чаллыбыз бар! Рәхмәт моның өчен Бөкәш һәм Тәберде халкына, дип әйтәсем килә. Археолог галимнәр әле киләчәктә дә мөрәҗәгать итәчәк бай табылдыклар вәгъдә итүче Чаллы истәлекләренә.

Халкыбыз тарихы өчен аеруча кыйммәтле саналган археология һәйкәлләрен саклауның бик уңайлы бер юлы бар: анда ел саен аз булса да, казу эшләре үткәреп торырга кирәк. Табылдыкларның бер өлешен мәктәп музейларына тапшырсаң, бигрәк тә әйбәт. Яше дә, карты да бик кызыксына бит ерак бабаларының үткән тарихы белән. Мәктәп балалары безнең белән казу эшләрендә дә катнашырга әзер. Менә шулай яшьтән үк үзенең тарихын белеп үскән кеше борынгы һәйкәлләргә беркайчан да кул күтәрмәс. Алып карагыз шул ук Котлы Бөкәш халкын. Кала-тау территориясен кирәк булмаган хуҗалык корылмаларыннан чистартып куйдылар. Калага керә торган төп капканы элеккеге кыяфәтенә туры китереп һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы белгечләре белән киңәшеп, яңадан торгыза башладылар. Дөрес, ул эш ахырынача җиткерелмәгән әле, әмма дә эшләп бетерәчәкләр аны! Табылдыкларның бер өлешен, бездән сорап алып, хәтта район музеена да урнаштырдылар. Алай гына да түгел, Хәлфә бабай каберен һәм аның авыл читендәге чишмәсен тәртипкә китерделәр. Туган җиргә мәхәббәт менә шулай тәрбияләнә ул! ■

МИШӘРЛӘР*

Зариф Бәшири

3. МИЛЛИЛЕКТӘ ЯЛГЫШ ЮЛЛАРЫ, ТЕЛЛӘРЕ ВӘ СӨЙЛӘШЛӘРЕ

Мишәрләр ныктыр да миллиләр! Үзләреннән аз гына аерым булган татарларга да нык катнашасылары килми. Бу исә татарларның мишәрләргә хаксыз кырын карауларыннан да килә булыр. Фәкать аларның миллилек юлын тотып, миллилекнең иң нык бер нигезе булган тел мәсьәләсенә әһәмият бирмәүләре, үзләренең миллилектә ялгыш юлда идекләрен нык ачык белдерәдер.

Мәгълүмдер ки, һәр милләтнең тәрәккый вә бөек булуына сәбәп булган нәрсә — ул милләтнең ана телен югалтмавыдыр. ***Ана телен югалткан бер милләт — тәрбиясез ятим калган бер бала хөкемендәдер.*** Ул милләтне «үле вә рухсыз, тәрәккыяткә сәләтсез милләт», дип тәгъбир итү дә чиктән

Мишәр хатыннары балалары белән. XX йөз башы

*Дәвамы. Башы журналның 10 нчы санында.

тыш артыкдыр. Шулай булгач, мишәрләрнең бу миллилекләренә тәрәккый сәбәп булган бәгъзе әсәрләр күрсәтүләренә таянып, алардан бөек өметләр күзәтмәк күңелгә бик авыр бер хәлдер. Чөнки мишәрләр үзләренең ана телләрен бүген гаеп итеп тормактадыр. Аларга катышкан сүзләрнең иң күбе дә урыс сүзләредер. Мәгълүм булганча, аларда хәзер җиде йөздән арты урыс сүзе кулланылмактадыр. Хәлбуки, алар моңа һич әһәмият бирми, телләрен көннән-көн урыслаштыру белән мәшгульләрдер. Урамда йөргән кечкенә генә бер мишәр баласын тотсаң, ул шактый гына урысча сөйләшә белә. Ләкин үзе урысчаны һичкайда укымаган. ***Дөрес, мәмләкәтемезнең баш теле булган урысчаны белмәк бик зур бер бәхтиярлык исә дә, мөкатдәс булган ана телен шуның астына күммәк зур бер кайгыдыр.***

Надан халыкның тел җуюы читтә торсын, бәлки муллалары да сүз саен бер урыс сүзен катыштырып сөйләүне камиллек саныйлар. Күп мәртәбәләр ишеткән бер вакыйгаларны бу урында язуым белән, аларның телләре нык урыслашканны исбат итә алырмын, дип уйлыйм.

Ана телен югалткан бер милләт – тәрбиясез ятим калган бер бала хөкемендәдер.

Нижгаруд (Түбән Новгород) тарафында бер мулла гает көнендә зияратка бармыш. Бар белдеге: «Раббәнә әтийнә фи әд-дүнья хәсәнәтән вә фил-ахирәти хәсәнәтән вакыйна газаба әннар» дип, бөтенләй урыс артикуляциясе белән укыганнан соң, тирә-ягында булган халыкка карап: «Вафси нимнушка тульки нит Ибрушки, ун миня кармил сулянкум» — дип кылмыштыр. Укучым бәлки моны анекдот дип уйлар. Бу мәзәк түгел, ышанычлы бер чынбарлыктыр.

Мишәр кардәшләребезнең бу хәлгә әһәмият бирмәүләре, хәтта моны аңламаулары нидән дип беләсез? Уйлавымча, наданлыктан. Әгәр моны милләт өчен зарарлы, дип белсәләр иде, һичшиксез, моны бетерергә ты-

Сергач өязенең мишәр авылы старшиналары. XX йөз башы

рышырлар иде. Тулай «милләт өчен зарарлы» дип аңлаган нәрсәләр өчен дә унар елдан артык мәшәкатьләрдә йоклаган мишәр егетләре моны аңлаганда тагын да күбрәк мәшәкатьләргә баш иячәкләре табигыйдыр. Моның өчен мишәр балаларын милли вә моңа әһәмият бирә ала торган мөгаллимнәр кулында тәрбия итмәк лаземдер. Әгәр бу илә булса, аларны татарлар белән дә беректермәк бик кулай булачактыр. Чөнки, мишәрләрнең асыл телләре белән татар теле арасында аерма бик аздыр. Ләкин шунысы шаян гаҗәптер: бу бер-берсенә шулкадәр якын булган ике милләт арасында артык суыклык кайдан калган? Мин мишәрләрнең асыл телләрендә беркадәр чуваш сүзләреннән башка татар теленнән аерма бик аз табам. Ләкин алардагы «шит (кадак), бугул (кибән), карый (кайдан), әмән (гүя)» сүзләрен генә белгән телләрнең һичберендә таба алмадым.

Фәкать мишәрләрнең асыл сөйләшләре һичбер милләтнекенә охшамаслык дәрәҗәдә башкадыр. Тик бары бер сүзне ике мәртәбә әйтми сөйләүләре белән генә чуаш вә кыргыз-казакъ халкына охшаталар. Ләкин чуашлар сүзләрен бер-беренә тиз тоташтырып крута-крута сөйләдекләре хәлдә, мишәрләр һәр сүзләренең арасын нык аералар вә бер мәртәбә әйтү белән аңлатырлык рәвештә ачык әйтеп сөйлиләр. Җөмләләрен кыска төзеп вә ахырларын, төшкенрәк булган моң бер тавыш белән боргалыйборгалый сузып тукталалар. Кешегә эндәшүләре бик тупас вә диваналыктан гаять ерактыр. Шулай ук аларның кешедән «үтенү вә ялварулары» да «катгый әмер» кеби буладыр. Мәсәлән, бернәрсәне икенче бер урынга алып куюны үтенү урынында: «Амрук, амый, мә, шуны тегендә алып куй!» — диләр. Яхуд бер нәрсә сораганда гаять тупас вә килешсез иттереп: «Менә шуны миңа давай!» — диләр.

Амрук Әмрәалладан бозылган бер кешенең исемедер. Аларда исеме бозылмаган, кушаматы булмаган кеше бөтенләй юк. Хәтта шулкадәре бозалар ки, чын исеме ничек идеген дә белеп булмый. Хәтта кайберләре үзләре дә чын исемнәрен белми. Мин берәүнең исемен сораганда, «Сабитин», дия җавап бирде. Мин моңа артык гаҗәбемнән ачуга тоташып: «Мин синнән чын исемең ничек? — дип сорадым», — дидем. Мишәр дә: «Ничек булсын, Сабитин, мулла кушкан ат», — диде. Соңрак белдем: ул Сәйфетдин, имеш. «Амый» сүзе берберенә эндәшкәндә аларда бик мактаулы булган бер сүздер. Моның асылы «гами» (тупас, дорфа, кара кеше) булырга охшый[2].

Мишәрләрнең асыл сөйләшләре шулкадәр кызыктыр ки: читтән тыңлап торган кеше гадирәк сүзләрдән дә бер мәзәк сөйлиләр, дип уйлар. Ике мишәрнең гадәти сүзләрен генә тыңлап торганда да көлми калу мөмкин түгелдер.

Мишәргә әйтүе иң кыен булган хәрефләр «х, гъ, къ, w» хәрефләре. Берничә еллар мәдрәсәдә гомер уздырган (үзләренчә «ыйлем[ле]») кешеләр дә бу хәрефләрне әйтә алмый. Моннан башка хәрефләрне тәмам җиренә җиткереп сөйлиләр вә укыйлар.

Мишәрләр үз сүзләрен күбрәк кыскартып сөйләү өстенә дингә мөнәсәбәтле булган мөкатдәс гарәби сүзләрне дә гаятъ ялгыш вә куркынычлы кыскартып сөйлиләр. Мәсәлән: «Иншә Аллаһ»ны «Ишә Аллаһ», «Аллаһы Тәгалә»не «Ала тәләсе» диләр. Әгәр әйтә алмаган мәзкүр дүрт хәрефтән бере дә очраса, бетте инде анда. Мәсәлән, «Күл һүә Алла»ны (Әлгыяз би Алла) «Кәлү Аллаһ» дия укучы мишәрләр миңа бик еш очрый.

Мишәрләр муллаларының иң динче мөридләреннән саналадыр. Мәҗлесләрдә җәдидче вә мәгариф пи-

[2] «Гамый» диюме икән? («Шура»). Амый — ам сүзеннән дә булуы мөмкин (*Р.З. — Ркаил Зәйдулла*).

рурларга (дәрвишлек юлына чыккан кеше), кыямәт куркынычы рәвешендә кикерә-бакыра кәфер пичаты басканда «Хәзрәтнеке дөрес! Яшьләр динне бетерделәр!» дип, муллаларга дини ярдәмдә булучылар менә шушы әфәнделәрдер. Мишәр муллалары Алладан курыкмый бу наданнарга «динче галим» исемнәрен биргәнче, дини эшләрдә югарыдагы мәзкүр җөмләләрен генә төзәтсәләр дә, югалып бетәргә якынлашкан ана телебезне бетермәскә тырышып, дөнья вә ахирәттә бәхетле булырлар иде. Ләкин һәйһат! Корсак моны йебәрми.

Мин боларны мишәр кардәшләремне бәгърем җанып аявымнан чыдаша алмый яздым. Укучым, ихтимал гафу итәрсез, дип уйлыйм.

4. МАКТАНУ ВӘ БЕРНӘРСӘНЕ АРТЫК БИРЕЛЕП ЯРАТУЛАРЫ

Бар милләт өчен иң хәтәрле булган нәрсә — эшсез вә гамәлсез мактану вә бер нәрсәне артык бирелеп яратулары-дыр. Болар күбрәк вакытта ияләшкән милләтне начар гадәтләр белән каплап алып, Тәгалә вә тәрәккый юлыннан адаштыра вә ераклаштырадыр. Моңа мисал итеп, фарсы милләтен истә тоту да җитәдер. Мәсәлән, бер фарсының тора торган өенә керсәң, иң әүвәл күзгә күренгән нәрсәләрдән диварындагы зиннәтле картина вә рәсемнәр буладыр. Мәсәлән, хәзрәти Гали бер дию белән сугышкан вакытта гайрәт белән кылычын чапкан да, кылыч диюне үтеп җирне дә кисеп төшкән. Хәтта җирне күтәргән Маймүнә үгезне дә кисеп һәлак итәчәк икән дә, тиз генә хәзрәти Җәбраил килеп кылычны тоткан. Һәм дә үткен вә гайрәтле бер атка менгән Мозафир шаһның зур бер җылан белән сугышу рәсемнәре кебиләр. Болар рәсемдә генә түгел, игътикадларында (инану) вә телләрендә дә шулай ук. Әгәр бер картрак фикерле фарсы белән утырышырга тугры килсә, ул туктаусыз хәзрәти Галине сагына, аның белән мактана. Ләкин аңарда булган сыйфатлар белән түгел, бәлки хыялда булган ялгыш сыйфатлар белән. Ә үзе шулай булырга тырышмый. Шушы хыял белән вакытын уздыра вә милләтен фәкать шуның аркасында гына өстен итәргә тели. Кызык түгелмени, фарсылар үзләрен хәзрәти Галигә нисбәт белән күкрәк киерәләр!

Бу гадәтләр фарсыларны гына түгел, без мишәрләрне дә бик нык басып алгандыр. Кайда гына бер мишәр янына барып дин-ислам хакында сүз башлама, ул Али батыр (хәзрәти Гали) хикәясен сөйләп китәдер. Шуның белән горурланыр вә үз дөньясын шуның белән бөек күрсәтергә тырышыр. Дөньяны гына түгел, хәтта мишәрләргә нәсел җәһәтендә һич мөнәсәбәте булмаган хәзрәти Галигә бәйләп, гүя элек

Казан татарлары эшсез вакытларын, ял итү кичләрен күбрәк ресторан вә пивахәнәләрдә динне тәрәккый һәвәсе илә бутылка бушатмак белән үткәрдекләре хәлдә, мишәрләр бәйрәм вә ял итү кичләрен булдыра алган кадәрле китап уку белән уздыралар.

мишәрләрдән шундый кешеләр булган кеби, үзенең мишәрлеген мактар. Гомумән диярлек һәр мишәрнең кулында вә өйләрендә хәзрәти Галинең «кан кальга (ныгытма), «җәнадил (кыя буендагы) кальга»ларында диюләр белән сугыш вакыйгаларын язган кыйссалар була. Үзе укый белмәсә, кешедән укытып тетри-тетри тыңлап утыра. Хәлбуки бу кальгаларының ни тарих,

[3] Кире кайтаруы мөмкин булмаган бер нәрсә өчен өзгәләнгәндә әйтелә торган ымлык.
[4] Әле дә ярый кылычны хәзрәт Җәбраил тотып өлгергән, юкса, җир җимерелеп дөнья һәлак булачак икән.

ни җәгърафия сәхифәләрендә һич күренгәне юк вә бар дип игътибарлырак авыздан ишетелгәне дә юк. Ләкин мишәрләр моны Ташкент шәһәре элек «Җәнадил кальгасы» булган, имеш, дип аңлаталар.

Мишәрләр арасына фән вә әдәбият җәдидә китапларының таралмавы да ошбу кыйссаларның артык роль казануларыннандыр. Кышкар вә Мәчкәрә шәкертләре Казан арты китапчыларына «мишәрләр сәхабәсе» дип исем бирмешләр иде. Моның сәбәбе аларның мишәрләргә шундый яңа хорафат (юкбарга ышану) биргән хыялый кыйссалар таратулары өчендер. Казанның берничә китапчыларын алтыннарга күмгән нәрсә дә мишәрләрләрнең ошбу игътикадка буялуларыдыр.

Сүз арасында үтенеч буларак шуны да әйтеп китәргә телим: мишәрләргә заман таләбенә мөнәсәбәтле язылган рисалә вә китапларны тарату өчен иң кулай юл-мәзкүр кыйссаларны таратучы китапчыларның моңа игътибар вә һиммәт итүләредер. Чөнки мишәрләр бу китапчылар нәшер иткән китапларга шул кадәр иялəшкән, гадәттә башкалар нәшриятен алудан гаҗәб дәрәҗәдә саклана иделәр. Бу көндә мәзкүр китапчыларның әз-мәз нәшер иткән яңа рисаләләре тулаем сурәттә мишәрләрдә бардыр. Алар нәшер иткән рисаләләрнең һәрбере мишәрләр каршында хакдыр. Мәзкүр китапчы берәдарән Кәримовлар белән Хөсәения фирмалары булып, алар кайгыртучанлык күрсәтсәләр, мишәр кардәшләренең телләрен ачкан вә аларны начар инанулардан паклы иткән булырлар иде.

Казан татарлары эшсез вакытларын, ял итү кичләрен күбрәк ресторан вә пиваханәләрдә динне тәрәккый һәвәсе илә бутылка бушатмак белән үткәрдекләре хәлдә, мишәрләр бәйрәм вә ял итү кичләрен булдыра алган кадәрле китап уку белән уздыралар. Аларны да укый белүче аз булдыкда берсе укыганны 5-6сы ихлас белән тыңлап утыра. Мин берничә шәһәрдә күтәреп сәүдә итеп йөрүче мишәрләрнең арып-талып кайту өстенә һәр кичне уку белән булышуларын күреп гаҗәпләнә идем. Фәкать боларның укый торган китаплары Али батыр (хәзрәти Гали), Камыр батыр, Чилбәр батырның җиде башлы диюләр белән сугышкан, Әбүгалисина хәлен тасвир иткән ялган кыйссалардан узмаганга, бөтен зиһенләре вә миләре юк хыял вә юрган асты фикерләре белән чуалып беткән буладыр. Бу хыялларының гакыл вә тән сәламәтлеге өчен дә бик күп зарары бардыр. Шуның өчен дә мишәрләр арасында гакылдан язган кешеләр бик күп очрый. Мин ошбу рәвештә гакылдан язган берничә мишәрне күрдем. Кулларында гел шундый китаплар, шуны укый да: «Ах! Менә шулай булса иде», — дип озын хыялга чума. Бу тугрыда пәйгамбәрлек дәгвасына дучар булган мәгълүм «Мирай»ны истә тотсак та җитәр. (Бу кеше Саратов мишәре булып вә агасы берничә урыс вә татар газеталарына да язылмыш иде.)

Бу урында: «Бу милләтләр шушы хыяллар белән саташып та үзләре шундый диюләр белән сугышучылар кеби булырга гамәл белән тырышалармы соң?» — дигән бер сорау килә. Бик тырышырлар иде дә, дию-җыланнар белән сугышуы мөмкин түгел бит!

Мишәрләр тырыш, булдыклы вә егет табигатьле бер халык булулары өстенә, гаят дәрәҗәдә аңлы, зиһенле вә үткен булдыкларыннан бераз җүн уңайларына ятылса, бу хәлләрдән котылуы да бик тиз булыр төсле күренә. Менә мин бу арада әлеге кадерле муллаларына — яңа китапларны нәфрәт күзе белән караган вә кулларына тотарга җирәнгән берничә мишәргә «нәшрият Кәримия»нең берничәсен укып вә аңламаганнарын аңлату белән мәшгульмен. Вә вакыт бетерүгә: «Менә бу китаплар бигрәк яхшылар икән. Никадәрле халыкның тормыш вә рәвешен белдерә, әлегә кадәр безгә ник болар килмәгән соң?»

Чувашиядәге Кыр Бикшиге авылы мәктәбе укучылары. Уртада – мөгаллимә, Ленин ордены кавалеры Гөршидә Фәсхетдинова (күренекле драматург Фәтхи Бурнашның апасы). 1936 ел. Нәкыйп Каштанов архивыннан.

— дип шат булуларын белдерәләр вә һәркайсы: «Фәләнем сәүдәдән кайткач, аңа да укытыр идем», — дип сатуымны телиләр.

5. ТӘКЪЛИД (ИЯРҮ, ОШАТЫП ЭШЛӘҮ), ТӘКӘЛЛЕФ (ЯСАЛМАЛЫК, КЫЛАНУ, ТАРТЫНУ) ВӘ БӘЙРӘМНӘРЕ

Мишәрләрдә иң бөек урын казанган нәрсә дә — гайбәт вә тәкълиддер. Араларыннан бере бер нәрсә кылса вә эшләсә, башкалары да ул нәрсәнең асылын вә әһәмиятен, нәтиҗә вә зарарын һич уйламыйча, барлык мал вә вакытларын сарыф кылыр. Берберсеннән калышмас өчен актык чиккә кадәр тырышалар. Бу бигрәк тә дини булган нәрсәләрдә куәт алмыштыр. Мәсәлән бер авылда өч мәсҗид булса башка авылларда мөмкин кадәрле өч ясарга, хәтта мәхәллә тутыра алсалар, арттырырга да тырышалар. Бер бай мәсҗид салдырса, икенчесе дә аннан-моннан җыеп мәхәллә тутыра да мәсҗид сала. Шуның өчен дә Русиянең кирәк кай гына тарафында булган бер мишәр авылына карама, 5-6 йөз иманалы булган булса да 3тән ким мәсҗиде булмас. Мишәрләрнең иң ярлылары да Чистай мишәрләре булып, анда да һәр авылда өчәр вә дүртәр мәсҗид буладыр. Бу хакта «татар баеса хатын алыр, мишәр баеса мәсҗид салыр» дигән бер мәкаль дә үзләре арасында сөйләнәдер. Мәсҗидләренең эченә кереп караганда, түгел биш вакытта, бәлки җомга намазларында да яртысыннан артыгы буш күрелдегеннән беленәдер ки: бу хәл бары дингә булган мәхәббәт вә ихласларын тыштан белгертер өчен бер-беренә ярыш итешү икән.

Мондый тәкълидләр исә гади халыкта гына булмыйча, бәлки муллаларында да көч алмыштыр. Мәсәлән, бер мишәр мулласы теле белән асыл

җәдидәне вә Йарупа мәдәниятен сүгә, фигыле белән аларга каршы сугыш ача, шуңардан ук: «Хәзрәт балагыз кайда укый?» — дип соралса, бер ысул җәдидә мәктәбендә яки бер урыс мәктәбендә укытканы беленә.

Шул муллалар ук хәзерендә бер-берсеннән калышмас өчен бик камил булмаса да, тырышып-тырмашып, мәсҗиде янына бер ысулы җәдидә мәктәбе торгызган вә мөгаллим дә китергән булалар. Димәк, бер авылда өч мәсҗид булса, өч мәктәп вә өч мөгаллим дә була. Менә боларның һәммәсен түземле милли мишәрләр һич сыкранмый тәрбия кылалар. Бер мишәр мулласы ысулы җәдидә мәктәбе ачкан да, шуңа ачынып: «Бәгъзе бер авылда җәдидче байлар читтән кайтып муллаларына ысулы җәдидә мәктәбе ачып бирделәр дә, ул муллаларның шундый мәктәпләре булгач, без дә салмый булдыра алмадык. Менә шулай итеп, һәр мәхәлләне шул басты. Әле дә йетмәсә яратмасаң да үз мөгаллимеңне мәҗлес саен мактап йөрергә туры килә. Чөнки башкалар үзләренекен мактый», — дип зарлана. Болай булганда мишәрләрнең тәкълид вә гайбәтләреннән яхшы гына өметләр дә котәргә урын бар.

Бу тәкәллефле булган гади халык бигрәк тә зур исрафларга чумадыр. Мәсәлән, уртача гына мәгыйшәтле булган бер мишәрләрнең бәйрәм тәкәллефләрен санап карыйк. Ул, бичара, игенен җыеп бетергәч, истирахәт (ял итү) алды бәйрәмен зур чыгымнар белән үткәреп, озак та үтми, ураза, авыз ачтыру вә рамазан бәйрәмен үткәрүгә чыгымнар тота. Ярлы булса да байлардан калышмый. Боларны үткәреп йебәрү онытылганчы, корбан бәйрәменең эше сизелә башлый. Менә күрегез, шушы әфәнденең Корбан бәйрәмендә генә тоткан чыгымнарын! Гарәфә көн (моңа мишәрләр «үрә/өйрә көне» диләр) муллаларга коймаклар пешереп илтә. Шул көндә үк хәзрәт тә йорт саен Коръән укып йөри, аңарга аз булганда 20-30 тиен сәдака бирә. Гаеттә мулла, мөәзин, хәлфә, мәхдүм, хаҗи вә соры кортларга аз булганда 5-6 сум сәдака өләшә. Дүрт-биш сумлык сарык чала. Мөмкин кадәрле байлардан калышмый, 20-30 сумнар акча тотып, аның мәҗлесен уздыра, анда 2-3 сум корбан сәдакасы өләшә. Бер-ике көн үткәч «Корбан хәтеме» исемендә тагын да бер мәҗлес ясый. Шул көенчә уртача гына бер мишәрнең корбан бәйрәме генә дә 70-80 сумнан аша.

Корбан бәйрәме артыннан гашура (мөхәррәм аеның унынчы көне) килеп җитә. Хасил, дини бәйрәмнәр берсе артыннан берсе куа тора. Мишәрләр боларның һәрберсен зур-зур чыгымнар белән каршы алалар вә үз итәләр. Һәрберен, үзләренчә тантаналы вә тәкәллефле рәвештә икешәр вә өчәр көн ясыйлар. Һәрберендә муллалар йорт саен Коръән укып йөри. Элегрәк кызыл йомырка бәйрәмнәрендә дә Коръән укып, йомыркалар пешертеп йөргәннәр. Хәзер бу юк. Моны чуашлар вә гаҗәмнәр[5] хәзерендә дә ясыйлар. Моңа чуашлар «Монкун», гаҗәмнәр «Нәүрүз бәйрәме» диләр. Гаҗәмнәрнең бу бәйрәмне «хәзрәт Хөсәеннең Йезед белән сугышкан көне» дип урамнарда ат өстендә күгәрчен уйнатып вә пычак, тимерләр белән үз-үзләрен кыйнап, үзләренчә хәзрәт Хөсәенгә охшап йөрдекләре кеби, чуашларның да «Олы көн» исемен биргән бу бәйрәмнәрендә сахрада йомыркалар алып, атлар чаптырып йөрүләре «хәзрәт Хөсәенгә охшау» гадәтеннән калган булса да гаҗәп түгелдер[6].

Моннан 25-30 еллар элек мишәрләрнең бәйрәмнәрендә иң сөекле гадәтләре дә аю биетеп йөрү булган.

[5] Гаҗәмнәр — фарсылар.

[6] Чуашлар пасханы монкун (олы көн) дип атый *(Р.З.)*.

[7] Аю биетү һөнәре патша указы белән бетерелә *(Р.З.)*.

Нинди бер иҗтиһад сәясендәдер аны бетергәннәр[7].

Ул беткәч, мишәрләргә күңелсез булганлыктан, гакылсызрак кешеләрне аю ясап, чылбырлап, биетеп йөргәннәр. Мишәр карчыклары моны авыз сулаларын корытып сөйлиләр вә сагыналар. ***Фәкать шуны гына хупларга була: аларда бәйрәм көннәрен күңел ачып исереп, урам буйларында бугаз киереп акырып-кычкырып йөрү бөтенләй диярлек юктыр.*** Казан татарлары дини бәйрәмнәрнең ике гаеттән башкасын тотмый вә хәтта искә дә алмый. «Симек», «Куш капка» исемнәрендә булган эчке бәйрәмнәрен «чымыткый» белән каршы алып, «ачтыкый» белән озатып, дин вә әдәпкә сыймаган җыен кабахәт вә фәхеш эшләр белән пычрандыклары хәлдә, мишәрләр андый бәйрәмнәрнең исемнәрен дә белми вә ишетми. Дини бәйрәмнәрне генә тотып, мөмкин кадәрле эчке вә фәхеш эшләр белән буялмаска, яхшы эшләр белән үткәрергә вә бәйрәмне ихтирамларга тырышалар. Бер-беренә мәхәббәтләрен арттырырга, туган вә дусларының хәтерен табарга бәйрәмне оста итәләр. Тик бары фәкыйрьләре чиктән тыш исрафлардан тыелып, байлары корбан мәҗлесләренә түккән йөз сумнарын бигрәк тә гыйлем вә мәгариф юлына, ятим вә фәкыйрьләрне тәрбия эшенә тотып, мәҗлесләрен гадирәк үткәрсәләр, тагын да яхшырак булыр иде.

Мишәр халкы гомумият илә читтә йөрдекләреннән төрле халыкны күрә вә аралаша, шуның өчен дә Йаурупа гадәтләренә тәкълид итүләре дә аз түгелдер. Мәсәлән, асылда мишәрләрнең өйләре урдыклы (сәке) булып, аш ашаганда, шәрык ысулынча, идәндә вә сәкедә тезләнеп яки болганып утыру гадәте булса да, хәзерендә һәр өйдә Йаурупа ысулынча өстәл вә урындыклардыр. Өй әсбаплары вә мәҗлес әдәпләре дә шулай ук киемнәре дә күбесенчә йаурупача. Мәсәлән, бер мишәр авылына барып керсәң, биш билле казаки, тездән чалбар, кунычын көядән ашаткан читекләрне бик аз күрергә мөмкин булыр. Һәркайсы диярлек пинжак вә тужурка, брюка вә шиблит, озын вә тар бүрек, катырма яка белән йөри. Моңа муллалардан башка картлары хәтта һич каршы төшми, вә яшьрәк муллалары да шушы киемнәр белән иректе йөри ала. Шулай ук боларда чәч, сакал вә мыек кеби җон бәхәсләре дә бик аз булып сирәк, юк дәрәҗәсенә кертәргә ярарлыктыр.

Фәкать мишәрләр моның әһәмиятен, кирәклеген аңлаганнан яхуд ачык фикерле вә мәгарифле саналганнан, киемнәренең дингә катнашы юклыгын белгәннән түгел, бәлки дә бер-берсеннән күреп вә ияреп кенә эшлиләр. Шушындый Йарупуча тормышлы вә киемле мишәрләр арасында ук иске фикерле вә хәзрәтләр догасына баш иеп әбҗад вә иҗекнең хасиятләренә яман китерүчеләр дә бик күптер. Шуңа да шулардан ук: «Карт хәзрәтләр дингә сыймый, диләр дә диюен, нишләмәк кирәк, кеше кигәнгә киябез инде шунда», — дип җавап алачагыңны көт тә тор.

Кыскасы, мишәрләрнең бу илә тәкълидчелекләре аркасында хәзерге гадәт вә тормышлары гаять дәрәҗәдә буталчыктыр. Шулай ук табигать вә фикерләре дә, төрле урында төрлечә булып, бер-береннән тәмам аермалыдыр. ***Шуның өчен дә аларда йаурупача булган берничә гадәтләрен күреп «мишәрләр яңалашканлар икән», дип яхуд иске гадәтләрне күреп тә «боларга әле дә тәрәккый исе кермәгән икән», дип хөкем кылып булмыйдыр. Аларның, асыл хәлләрен белер өчен дә картраклары тирәсендә әйләнү вә аларны сөйләтү тиештер.***

Текстны басмага **Салават Галимов,**
искәрмәләрне **Ркаил Зәйдулла** *әзерләде.*

Дәвамы бар ■

ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕ ЗИРАТЫНЫҢ ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЕ

Ильяс хәзрәт Җиһаншин

Казанның Яңа Татар бистәсе зираты – XVIII гасырның урталарында бистә белән бер үк вакытта барлыкка килгән. Язулары гарәп, латин һәм кирилл әлифбалары белән башкарылган мөселман кабер ташлары, мәчете һәм капкасы белән берлектә, зират Казанның тарихи һәм истәлекле урыны булып тора.

Күп еллар дәвамында зират Казан мөселманнарының төп каберлеге булып торган. Бүгенге көндә, анда урыннар булмау сәбәпле, яңа каберләр казылмый, кеше күмүләр исә бары тик туганнар каберлекләрендә башкарыла.

Бу зиратта күренекле имамнарыбыз, татар мәдәниятенең мәшһүр эшлеклеләре җирләнгән. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Галимҗан Баруди, Фатих Әмирхан, Салихҗан Галиев һ.б. бар.

Зират администрациясе карамагында «Әл-кайюм» мөселман мәхәлләсе эшли. Зиярәт кылырга килгән халык өчен, намаз укуны истә тотып, мәчет төзелгән. Мәчетнең имамы — Мөнир хәзрәт Вәлитов. Яңа Татар бистәсе зиратының җитәкчесе — Роберт хаҗи Вәлиев.

Гадәттә, татар зиратына килеп керү белән, теге яки бу имамның, галим, язучы-шагыйрь, яисә сәнгать эшлеклесенең каберен табу — гаять четерекле эш. Аеруча, елына бер килеп китүчеләргә, башкалабыз туристларына кирәкле каберне эзләп табар өчен сәгатьләр буе зиратны аркылыга-буйга йөрергә кирәк. Ә шушы юл күрсәткече каберләрне зиярәт итәргә килүчеләргә, туристларга бер ярдәмлек булыр, дип уйлыйбыз.

Моннан ун ел элек безнең тарафтан татар җәмәгатьчелеге өчен бер күркәм гадәт гамәлгә кертелде. Ел саен, 2 май көнне имамнар, шәкертләр, зыялылар Яңа Татар бистәсендәге зиратта булып, остазларны искә алалар. Чарага берничә көн кала, мөгаллимнәр шәкертләр белән каберстанга барып, мәрхүмнәрнең кабер өсләрен чистартып кайталар. Соңгы елларда, Бөтендөнья Татар конгрессының Казан бүлеге җитәкчесе Фәрит Мифтахов булышлыгы белән үткәрелә торган бу чарага Казаннан, Русиянең төрле төбәкләреннән дин әһелләре, татар җәмәгатьчелегенең

ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕНДӘГЕ ТАТАР ЗИРАТЫНДА ҖИРЛӘНГӘН ШӘХЕСЛӘР - МӨСЕЛМАН РУХАНИЛАРЫНЫҢ ҺӘМ МИЛЛИ РУХТАГЫ ЗЫЯЛЫЛАРЫНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

1. Апанаев Мөхәммәтвәли Мөхәммәтҗан улы (1889-1922) – җәмәгать эшлеклесе, имам.
2. Апанаев Габдулла Габделкәрим улы – Печән базары мәчете имамы.
3. Алтынбаев Мөхәммәттаиб Шиһабетдин улы – Печән базары мәчете имамы.
4. Әмирхан Мөхәммәтзариф Хөсәен улы (1853-1921) – Иске таш мәчет имамы, җәмәгать эшлеклесе.
5. Әмирхан Хөсәен (1816-1893) – Иске таш мәчете имамы, тарихчы-галим.
6. Әхмәров Шиһабетдин Шәрәфетдин улы (1882-1966) – мәгърифәтче.
7. Вәширов Таҗетдин (1831-1879) – Апанай мәчете имамы.
8. Габдуллин Сафиулла (1856-1926) – «Мәрҗани» мәчете имамы.
9. Галиев (Баруди) Галимҗан Мөхәммәтҗан улы (1857-1921) – Галиев мәчете имамы, педагог, дин галиме.
10. Галиев Габдрахман Мөхәммәтҗан улы (1872-1919) – Галиев мәчете имамы, педагог.
11. Галиев Салихҗан Мөхәммәтҗан улы (1862-1932) – 10 нчы мәчет имамы, педагог, дин белгече.
12. Галикәев Габдрахман Мөхәммәтсафа улы (1854-1927) – сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе.
13. Галикәев Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы (1847-1919) – сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе.
14. Галиев Мөхәммәтҗан Ибнеәмин улы (1832-1909) – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештыручы.
15. Габделгафаров Габделвәли (1891 елда үлгән) – Әҗем мәчете имамы.
16. Габделгафаров Хисаметдин Габделвәли улы (1849-1923) – Әҗем мәчете имамы.
17. Закиров Шамил Зиннур улы (1945-2012) – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының директоры, җәмәгать эшлеклесе.
18. Каюмов Габделхак Габделкаюм улы (1921-1999) – «Мәрҗани» мәчете имамы.
19. Максуди Әхмәтһади Низаметдин улы (1808-1941) – журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе.
20. Мәрҗани Шиһабетдин Баһаветдин улы (1818-1889) – дин эшлеклесе, тарихчы-галим, мәгърифәтче.
21. Мөхәммәтборһанетдин Мәрҗани (1856-1916) – «Мәрҗани» мәчете имамы.
22. Мөштәриев Исмәгыйль Мингали улы – «Мәрҗани» мәчете имамы.
23. Минвәлиев Зәкәрия Минвәли улы (1936-2013) – имам.
24. Миңнуллин Туфан Габдулла улы (1935-2012) – күренекле татар драматургы, язучы, җәмәгать эшлеклесе.
25. Насыйри Габделкаюм Габделнасыйр улы (1825-1902) – мәгърифәтче.
26. Рахмәнколов Гиясетдин Хәбибулла улы (1897 елда үлгән) – «Зәңгәр» мәчете имамы.
27. Рахматуллин Исмәгыйль – «Мәрҗани» мәчете имамы.
28. Сагитов Габделгани (1813-1871) – Печән базары мәчете имамы.
29. Салихов Мөхәммәткасыйм Габделгалләм улы (1871-1934) – Апанаев мәчете имамы, дин галиме.
30. Салихов Габделгалләм (1832-1899) – Апанай мәчете имамы.
31. Салихов Мөхәммәтгариф Мөхәммәт улы (1870-1921) – Солтан мәчете имамы.
32. Салихов Гарифулла Мөхәммәт улы (1861-1915) – Солтан мәчете имамы.
33. Садыйков Габделхак Мөхәммәтсадыйк улы (1995-1990) – имам.
34. Саматов Габделхак Әбелгата улы (1930-2009) – имам, Татарстаннның баш казые.
35. Сафиуллин Әхмәтзәки (1898-1995) – «Мәрҗани» мәчете имамы.
36. Сәетов Мөхәммәтшакир Хөснетдин улы (1843-1904) – 11 нче мәчет имамы.
37. Сәгыйтов Исхак (1838 елда үлгән) – Апанай мәчете имамы.
38. Сәгыйтов Сәләхетдин (1875 елда үлгән) – Апанай мәчете имамы.
39. Сәгыйтов Әхмәт (1793-1867) – Галиев мәчете имамы.
40. Сәгыйтов Мөхәммәтйосыф Габдесаттар улы (1830-1909) – Галиев мәчете имамы.
41. Тукай Габдулла Мөхәммәтгариф улы (1886-1913) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе.
42. Яруллин Габделхәбир Ярулла улы (1915-1994) – «Мәрҗәни» мәчете имамы.
43. Хафизов Габделхак хәзрәт (1915-1974) – имам.
44. Хайруллин Гарифулла хәзрәт – имам.
45. Халидов Хаммад (1864 елда үлгән) – «Зәңгәр» мәчет имамы.
46. Халитов Мөхәммәтзакир Хаммад улы (1893 елда үлгән) – «Зәңгәр» мәчет имамы.
47. Халидов Әнәс Бакый улы (1929-2001) – филология фәннәре докторы, профессор, дөньякүләм танылган гарәп теле белегече.
48. Урманче Бакый Идрис улы (1897-1990) – сынчы.
49. Габдулла Карый хаҗи.
50. Гайнуллин Гарифулла хәзрәт (1894-1984) – күренекле имам, ишан.
51. Әмирханов Мөхәммәднәҗиб Хөсәен улы (1857-1921).

Бибисара мулла Мөхәммәтшакир хәзрәт кызына куелган кабер ташы. 1912 ел

төрле буын вәкилләре бик теләп җыела. Гадәттә, искә алырга килүчеләр, зиярәт итүне Габделхак Саматов кабереннән башлый. Икенче булып тукталган Габделхак хәзрәт Каюмов исә, совет хакимияте елларында, теләгәннәргә дин нигезләрен, гарәп язуын өйрәткән хәлфә бабай иде. Аннан совет хакимияте елларында курыкмыйча дин гыйлемен өйрәткән Габделхак Садыйков белән Габделхак Хафизовны искә алалар. Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан һәм Салихҗан Барудилар, Габделхәбир хәзрәт Яруллин, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрнең дә баш очларында Коръән аятьләре укып, дога кылып, мәшһүр бабаларыбызның рухларын сөендерәләр. Шулай итеп, юл күрсәткече әлеге чараны оештырганда да төп кулланма булып хезмәт итәр, дигән өметтә калабыз.

Шунысын да искәртик, юл күрсәткече тулы, анда барлык шәхесләребезнең дә кабер ташлары күрсәтелгән, дип әйтеп булмый. Мәгълүм булганча, шактый зыялыларыбызның кабер ташлары яңа каберләр барлыкка килү белән юкка чыккан, ә кайберләренеке эчтә, куе чытырманлык яисә башка кабер ташлары арасында яшеренеп ята. Шунлыктан, бу өлкәдә эзләнү, тикшерү эше дәвам итә. Юл күрсәткечен, әдәбият-сәнгать әһелләренең дә каберләре урынын күрсәтеп, тулыландырасы бар.

Үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен белик, җәмәгать!

Редакциядән: *Ал мәчет, татар зиратындагы зыялыларыбыз кабер ташлары һәм Ильяс хәзрәт Җиһаншин сөйләгәннәр белән www.beznenmiras.ru сайтында таныша аласыз.* ■

Бигеевлар гаиләсе. 1927 ел, Ленинград

ХӨРМӘТКӘ ЛАЕК ИСЕМ

Альмира Таһирҗанова

«Безнең мирас» журналының быелгы 7 нче санында Хәмзә Бәдретдиновның күренекле дин галиме һәм публицист Муса Бигеевка багышланган «Милләтне кайгыртучы килен» исемле язмасы дөнья күргән иде.

Муса Бигеев шәхесенә һәм аның гаиләсенә күрсәткән игътибарлары өчен авторга һәм журнал редакциясенә рәхмәтләремне җиткерәм. Әмма дә, әлеге язмада кайбер төгәлсезлекләр китүе сәбәпле, Муса Бигеев тарафыннан татарчага тәрҗемә кылынган Коръәнне нәшер итү тарихын һәм дә аның төгәл-анык биографиясен шәхсән үзем дә шәрехләргә ниятләдем.

Үзгәртеп кору еллары башларында Казандагы тарихчылар бик күп онытылган, һәм дә оныттырылган шәхесләрнең исемнәрен яңадан кайтару эшенә керештеләр. Шул исәптән, Муса Бигеевның эшчәнлеге хакында да газета-журнал битләрендә язмалар күренә башлады. Авторларның һәммәсе дә диярлек Коръәни Кәрим тәрҗемәсенең югалуы хакында язып чыкты. Әмма дә ләкин, Казан каласыннан килеп, Муса Бигеевның кече кызы, каенанам Фатыйма Таһирҗановага мөрәҗәгать итеп, Коръән тәрҗемәсенең язмышы белән беркем дә кызыксынмады. Каенанам әтисенең исеме кайта башлавына ихлас күңелдән куана иде. Фамилиясен дөрес язмауларына да әллә ни исе китми иде аның. Аның өчен иң мөһиме — әтисенең исеме, онытылу вә оныттырылу томанын кичеп, илгә, милләтенә кайта! Ул фәкать әнисенең, иренең, кыз һәм ир туганнарының бу көннәрне күрә алмыйча китүләренә генә үкенә иде. Әтисенең биографиясен бозып язган, уйлап чыгарылган язмаларны укыгач, күңеле төшә иде аның. Мондый халәттә ул, гадәттә, өч көн урын өстендә ята, дәшми-сөйләшми, шуннан соң гына, бик тә әкренләп, элеккеге хәленә кайта…

2002 елның көзендә Санкт-Петербург этнография һәм антропология институты директорының фәнни эшләр буенча урынбасары, профессор Ефим Резван редакцияләвендә «Татары в Санкт-Петербурге. 300 лет истории» дип аталган китап дөнья күрде. Бу җыентыкта

Фатыйма Таһирҗанованың да «Об отце» дип аталган язмасы урын алды. Мәгълүм ки, Муса Бигеев төрки әдәби телдә язган һәм тәхәллүсен «Муса Җаруллаһ» дип куя торган булган. Пенза татарларындагы гадәт буенча, аның фамилиясе Биги булып йөри.

Каенанам әтисенең исеме кайта башлавына ихлас күңелдән куана иде. Фамилиясен дөрес язмауларына да әллә ни исе китми иде аның. Аның өчен иң мөһиме – әтисенең исеме, онытылу вә оныттырылу томанын кичеп, илгә, милләтенә кайта!

***

2003 елның августында каенанам истәлекләр язды һәм минем үтенечемне тыңлап, әнисенең көндәлекләрен дә гарәп имлясыннан хәзерге язуга күчерде. Берникадәр вакыттан соң ул үзенең туганы, тарих фәннәре докторы Равил Әмирханга хат юллады. Анда

ул Коръәннең әтисе тарафыннан татарчага тәрҗемә ителгән кульъязмасын китап итеп дөньяга чыгару мәсьәләсен күтәрә.

Муса Бигеевның биографиясен һәм Коръән тәрҗемәсен ике томлы китап итеп чыгару фикерен исә миңа Ефим Резван әйтте. Ул, моңа кадәр дөнья күргән мәкаләләремне укып чыккач та, болай диде: «Мәкаләләр белән генә чикләнмәгез, китап языгыз, сез аны булдырачаксыз!».

Ул төньяк мөселманнары хакында документаль фильмнар сериясе төшерде. Шул фильмнарның берсе Муса Бигеевка багышланган иде. Ни кызганыч, әлеге гаҗәеп әчтәлекле вә мәгънәле фильмны каенанам (ул анда үзе дә сурәтләнгән иде) күреп өлгерә алмады. 2006 елның 3 августында, 88 яшендә вафат булды...

***

2007 елның мартында мин, Коръән тәрҗемәсе һәм Муса Бигеевның үзем әзерләгән кульъязма биографиясе хакында бәян итеп, Татарстан Президенты аппаратының тышкы элемтәләр департаменты җитәкчесе Тимур Акуловка хат юлладым. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән сөйләшеп килешенгәч, без Тимур Акулов белән республиканың Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллегендә очраштык. Мең данә тираж белән ике томлык һәдия (бүләк) китабы нәшер итү хакындагы килешүгә кул куйдык. Китап чыгаруның матди ягын «ТАИФ» ААҖ (генераль директоры — Альберт Шиһабетдинов) күтәрде.

2010 елның 8 ноябрендә Татарстан Фәннәр академиясендә әлеге ике китапны тәкъдир итү кичәсе булды.

«Книга о Мусе-эфэнди, его времени и современниках» («Муса әфәнде, ул яшәгән чор һәм аның замандашлары турында китап». — ***Ред.***) хезмәтендә гаилә фотоархивы, каенанам хатирәләре, әнисенең көндәлегеннән өзекләр, Габдрахман Таһирҗанов автобиографиясе, Муса Бигеев һәм аның балалары хакындагы мәгълүматлар, галим һәм мәгърифәтченең үз хезмәтләре дә туплап бирелде. Ул хезмәтләрне рус теленә Айдар Хәйретдинов тәрҗемә итте. Әлеге китап чыгу белән, Муса әфәнденең дөрес әйтелешле фамилиясе, төгәл туган көне һәм туган урыны фәнни әйләнешкә кертеп җибәрелде.

Муса Ярулла улы Бигеев 1873 елның 25 декабрендә (иске стиль белән) Пенза губернасының Чембар өязе Мочали волостеның Кикин авылында (хәзер — Пенза өлкәсенең Каменский районы) дөньяга килә. Ярулла Бигеев, Оренбург мөфтие тәкъдиме белән, Дондагы Ростов (русчасы — Ростов-на-Дону) каласына ахун итеп билгеләнә һәм, Муса тугач та күп үтми, гаилә Кикин авылыннан әлеге калага күченә. Инкыйлабка кадәрге татар гадәтләре буенча, Муса әфәнде дә анкеталар тутырганда үзенең туган елын, туган авылын төгәл күрсәтүгә әллә ни илтифат итмәгән. Архивлар белән эш итүче тарихчылар беләдер, Муса әфәнде үз фамилиясен фәкать Бигеев дип кенә язган. Рус телендәге газета-журналларда исә төрлесендә-төрлечә: Бигеев та бар, Бикеев та, Бигиев та...

1989 елның җәендә ирем тәүге тапкыр бабасы хакында сөйләгәннәрен «Азатлык» радиосыннан ишетеп ала. Ул елларда Муса Бигеев фәкать төрек телендә чыгучы бер-ике басмада гына телгә алына иде.

***

...Тамырларымның пенза татарларыннан икәнен мин бала чагымнан ук белеп үстем. Әти-әни ягыннан да бабаларым — Пенза губернасы Саранск өязенә (хәзер — Мордовиянең Лямбер

Фатыйма Таһирҗанова Муса Бигеевның хезмәтләрен өйрәнүче һәм тәрҗемә итүче галим Айдар Хәйретдинов белән. Казан. 1999 ел, декабрь

Альмира Таһирҗанова

районы) караган Чирмеш авылыннан. Әти белән әни Ленинградта таныша, кавыша. 1963 елда әни ягыннан әбибабай, мине — алты яшьлек сабыйны да алып, туган якларына кайтып килде.

Төп-төгәл илле елдан соң миңа янә бу якларда булырга туры килде. Пенза өлкәсенең Каменка шәһәрендә 2013 елның 21 декабрендә Муса Бигеевның тууына 140 ел тулу уңаеннан оештырылган конференциядән соң кайттым. Авылдагы мәктәп Муса Бигеев исемен йөртә, мәктәп белән мәчет янындагы скверга да аның исеме бирелгән. Кикин урта мәктәбе диварына күренекле авылдашларының, шул исәптән бертуган Бигеевлар — Мөхәммәдзакир һәм Мусаның да исемнәре язылган истәлек тактасы куелган.

Мин һәрдаим тарих белән кызыксындым. Үзем яшәгән Ленинград — Петербург тарихы гаиләмнең, газиз халкымның үткәннәре, кичергәннәре миндә гаять зур кызыксындыру уята иде. Әбиемнең һәм бүтән өлкән кешеләрнең узган заманнар хакында сөйләгәннәрен тыңлап үстем. 2004 елда, «Петербург университеты» дип аталган өстәмә югары белем бирү уку йортын тәмамлаганда, «О чём поведали архивы. Несколько фрагментов темы». Татары в Петербурге» дип аталган баш астында рус телендә диплом эше яздым. Шулай итеп, бала чактан халкым тарихы белән кызыксынуларым тулаем бер уртак максатка әверелде.

1987 елда мин Муса Бигеевның оныгы, физик Мөхәммәд Таһирҗановка кияүгә чыктым. Ул чакта аның әтисе профессор Габдрахман Таһирҗановның вафатына да дүрт ел тулган иде. 1989 елның җәендә ирем тәүге тапкыр бабасы хакында сөйләгәннәрен «Азатлык» радиосыннан ишетеп ала. Ул елларда Муса Бигеев фәкать төрек телендә чыгучы бер-ике басмада гына телгә алына иде. Инде, Аллага шөкер, күренекле дин галиме, мәгърифәтче Муса Ярулла улы Бигеевның онытылган, оныттырылган исеме вә хезмәтләре иленә әйләнеп кайтты. Киләчәктә онытмасын иде аны халкым!

Русчадан **Марат Закир** *тәрҗемәсе.*

ӘХЛАК

К.Бикколый, Г.Госмани

4. ХӨСЕТ [КӨНЧЕЛЕК]

Адәмнәрнең кулында булган мал вә нигъмәткә яки дәрәҗә вә мәртәбәгә көнчелек итеп, ул мәртәбәнең аңарда булуын күпсенү — хөсет вә көнчелектер. Бу исә шәригать буенча бик гөнаһлы вә гакыл буенча бик бозык күрелгән вә яман холыклардандыр. Бәндәләргә дәүләт вә нигъмәт Аллаһы Тәгаләнең бүлеп (тәкъсим итеп) бирүе илә хасил буладыр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре үз нигъмәтләрен үз колларының теләсә кайсына теләсә ничек итеп бирер, анда һичкемнең эше юктыр. Шулай булгач, берәүгә Аллаһы Тәгалә биргән дәүләткә көнчелек итү, Аллаһы Тәгаләнең тәкъсименә (бүлеп бирүенә) риза булмау — Аллага каршылык итүдер. Бу исә бик кабих вә бик зур гөнаһлы яман сыйфаттыр.

Кайбер кешеләр берәүнең бай булуына яки дәрәҗә вә мәртәбәсе югары булуына, хәтта аның галим булуына да көнчелек итеп, ул дәрәҗәнең аңардан китүен теләрләр. Болар исә бик олуг чиргә дучар булган авыру кешеләрдер. Бу шундый авырудыр, моңардан дару табылмас. Теге кеше үлми яки аңардан ул дәүләт китми торып, сәламәтләнә алмас.

Балалар, сез моннан бик саклангыз, көнчелек илә һич файда итә алмассыз, сез көнләгән илә Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәте дә бетмәс, кимемәс, бәлки ул кешенең янә ахирәттә мәртәбәсе артыр. Пәйгамбәребез: «Көнче кеше Аллаһның нигъмәтенә дошман булган кешедер — аннан сакланыгыз», — диде. Гакыллы кеше Тәңресенең нигъмәтенә дошман булырмы? ***Көнче кеше һичвакыт шат булмый, даими кайгыда булыр.*** Һәм көнче кеше шундый мәшәкатьтә булыр ки, ул мәшәкать өчен әҗер бирелмәс һәм ул шундый хурлыкны муенына йөкләр. Аның өчен һич яхшы сүзләр әйтмәсләр, бәлки хурларлар гына. ***Көнчелек — иң явыз холыклардан вә иң яман сыйфатлардандыр.*** Аллаһы Тәгалә явыз шайтаннардан үзенә сыгынырга кушкан җирдә көнчеләрдән дә үзенә сыгынырга кушкандыр. Ул нәрсәдән Аллаһка сыгынабаз.

5. ТӘВАЗЫГ (ТӘВАЗЫЙГ) [ТҮБӘНЧЕЛЕК, ТЫЙНАКЛЫК, ӘДӘПЛЕЛЕК]

Тыйнаклылык дип әйтүебез алчаклык* булып, үзен башкалардан түбән дәрәҗәдә күреп, кече күңелле булудыр. Һәркемгә мәртәбәсенә күрә түбәнчелек күрсәтү — пәйгамбәребез вә изгеләр, галимнәр холкыннан булып, Аллаһы Тәгалә каршында кабул булган сыйфаттыр. Кешенең югары дәрәҗә вә мәртәбәләргә ирешүенә беренче сәбәп булыр. Әмма үзебезгә һәрвакыт яхшы фикердә булып, үзебез белән башкаларны чагыштырып, нәфесебезне башкалардан артык булуын сөябез, яратабыз. Бездә кешене һәртөрле хурлау моннан киләдер. Бу исә гакылсызлык, тәкәбберлек һәм дә горурлык галәмәтедер.

Кешене хурлау — ул кеше үзебездән өстен, зур булсын, ким вә кечкенә булсын яки үзебез илә бердәй булсын — һич дөрес түгел. Чөнки бу хурлау кеби начар сыйфатны үзебез илә бер булган тыңдаучыларга дөрес күрмәк гакылсызлыктыр. Шуның өчен тыйнак, тәрбияле, инсаниятле булып, һәркем илә күркәмлек белән эш күрмәк — иң тиешле бер гамәл булып, дөнья вә ахирәт сәгадәтенә ирешергә сәбәптер.

Әмма кешенең тышкы кыяфәтенә карап хөкем итмәкнең соңы — үкенмәктер. Чөнки күп вакытлар адәм, күргән кешесенең кигән киеменә ка-

---

*Алчаклык — акык йөзлелек, кече күңеллелек.

рап, әдәплелек күрсәтеп хөрмәт итәр яки хурлар. Зиннәтле, яхшы киемнәр эчендә гакылсыз, инсаниятсез бер адәм булмасмы? Яхшы холыклылык, кәмаләт гадәте простой киемнәр илә уратылган булмасмы? Гакыллы адәмне киеменнән түгел, эш вә хәрәкәтеннән танырлар. Шуның өчен, һәркемгә йомшаклык, түбәнчелек илә эш итмәктә бер зарар булмаган кеби, мең төрле файда булыр.

Әмма үз-үзен зур күреп, тәкәбберлек иткән кешенең, әлбәттә, хурлык, рисвайлыкка төшмәке шиксездер. Кыскасы, инсанга үзеннән өстен вә ким, түбән булганнарның барчасына тыйнаклык вә түбәнчелек илә үзен алардан ким тотып, түбән дәрәҗәдә дип белмәк кирәктер. ***«Адәмнең үз кимчелеген белмәктән артык гыйлем вә мәгърифәт булмас»,*** — дигән мәкальне хәтердән чыгармаска кирәк.

6. ТӘКӘББЕРЛЕК — ОЛУГЛАНМАК

Адәм баласының үзен олуг күреп, башка кешене түбән вә ким дәрәҗәдә күрүе — тәкәбберлектер. Бу исә бик яман вә чирканыч сыйфаттыр. Каты күңелле, усал кешеләрнең әхлакыннандыр. Мөселман кешегә тәкәбберләнү бөтенләй дөрес булмас. Пәйгамбәребез: «Берәүнең күңелендә тузан кадәр генә тәкәбберлек булса да, оҗмахка кермәс», — димештер. ***Адәм никадәр олугланса да күккә җитә алмас, олуглану — шайтан фигылеьдер.***

Тәкәббер кеше адәмнәр арасында кадерсез булыр, көлке вә мәсхәрәлеккә калыр. Ул күңелен күтәргән саен аны Аллаһы Тәгалә түбән төшерер. Аллаһы Тәгалә түбән төшерсә, бәндәләр арасында кадере вә хөрмәте калмас, хурлык вә түбән дәрәҗәгә төшәр.

Пәйгамбәрләрнең, олуг галимнәрнең һич үзләрен зур күрми, бик түбән дәрәҗәдәге кешеләр илә тиңсенүен сөйләрләр, алар белән мәҗлестәш булырлар. Вә бик вак нәрсәләрне дә үзләре эшлиләр иде. Әмма моңа карап алар ким дәрәҗәдә булмадылар. Бәлки кечекләнгән саен, Аллаһы Тәгалә югары күтәрде. Алар кыяматкә кадәр олуг исем илә зикер ителәләр. Балалар, сез дә тәкәбберлектән бик саклана күрегез.

7. ГАЙБӘТ

Бер мөселманга кардәшенең ярамый торган эшен кешегә сөйләү — гайбәттер. Гайбәт дигән нәрсә — шәригатебездә бик зур гөнаһлы хәрәм вә кабих фигыльләрдәндер. Пәйгамбәребез гайбәт сөйләүчеләрне адәм ите ашаучылар, димештер. Гакылы бар кеше, әлбәттә, үз карендәше булган адәмнең итен ашауны мәкруһ күреп, аннан сакланыр.

Гайбәт сөйләүченең ахирәттә хәле бик мөшкел булган кеби, дөньяда да адәмнәр арасында иң кадерсез, иң ышанычсыз яман кешеләрдән саналыр. Берәүнең хәтере өчен икенче берәүдәге юк гаепләрне бар итеп сөйләр, соңра бу сүзләр ул кешегә ишетелсә, йөзе кызарыр, оятлы булыр. Шулай итеп, халык арасында ышанычсыз булып калыр. Халык аңардан сакланыр, аның алдында сүз дә сөйләмәс.

Гайбәт сөйләп йөрүченең һичбер сүзенә ышанырга ярамас, чөнки ул ышанычлы яхшы кешеләрдән булса, үз карендәшенең гаебен сөйләп, яман атын сатып йөрмәс. Бәлки карендәшендә яман сыйфатлар булса, аны кешегә белдертмәскә, халык алдында аны оятлы итмәскә тырышып, ул гаепле эшне карендәшенең үзенә генә әйтеп, гүзәл нәсыйхәт илә аннан тыярга тырышыр иде. Берәүнең гаебен сөйләү — ул кешенең гаурәтен ачудыр. Яхшы кеше кайчан кешенең гаурәтен ачсын? Әлбәттә, ачмас. Сез, балалар, мондый яман холыклы булудан бик саклана күрегез! ***Гайбәт сөйләүченең авызы сасы, күңеле кара, йөзе нурсыз, сүзе ышанычсыз, үзе кадерсез булыр.***

Дәвамы бар

Текстны басмага
Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

БАБАЙЛАРЫБЫЗНЫҢ КАБЕРЛӘРЕ КАЙДА – 2

Ләбиб ЛЕРОН

Бабам Әүһади Шәйхразый улы Шәйхразиевнең (әниемнең әтисе) Новгород өлкәсендәге Парфин районы Борки авылы зиратында, төгәлрәк әйтсәк, шул зиратның туганнар каберлегендә җирләнгәне хакында «Безнең мирас» та бер язып чыккан идем инде (№ 5, 2014 ел).

Быел август аенда әлеге туганнар каберлегендә янә булырга туры килде. Бу юлы гаиләләребез белән бардык (энекәшем Фирдәвис (әниемнең энесе Рөстәмнең улы), аның хатыны Гөлнур, уллары Данил һәм мин, хатыным Фидания, улым Бәхтияр).

Кукмарадагы танышларыбыз Рәзилә һәм Фәрит Ганиевларга рәхмәт: аларның турыдан-туры ярдәме белән «Ритуал хезмәт» оешмасында (Кукмара, Ворошилов урамы, 23/54) бабабыз Әүһадинең исем-фамилиясе язылган мәрмәр такта (ике тимер «аяк» куеп, безнең өчен тиз вакыт эчендә махсус ясап бирделәр) ясаткан идек. Шуны алып бардык. Цементкомнан измә ясап, ташбилгене үзебезгә ошаган урынга, дөресрәге, «ш» хәрефе белән башланган фамилияләр язылган таш ягына кадап-батырып куйдык. Әүвәлге язмамда әйтеп үткәнемчә, Боркидагы туганнар каберлегендә бабамнан тыш тагын егерме кардәшебезнең (Татарстаннан) җәсәде җирләнгән. Халык телендә генерал-майор С.Г.Штыков каберлеге дип йөртелгән ошбу зиратта 1002 сугышчы күмелгән, шуларның якынча кырыгы — мөселман өммәтеннән, керәшен кардәшләребез дә шактый булуы ихтимал.

Язмам басылгач, журналдан укыпмы, әллә радиодан ишетепме, егерме кардәшебезнең икесе белән, аерым алганда, тумышы белән Сикертәннән (Мөхәммәт Мәһдиев укыган мәктәп, Арча районы) булган **Хазлеев** (Хазиев) **Муллахмат** (Мулахмет) һәм Будённый (хәзерге Буа) егете **Габаев** (Губаев) **Ахметзян Шарифзянович**

(Вольный Стан авылыннан) белән кызыксынучылар булды. Бәлки калган милләттәшләребез белән дә кызыксынучылар табылыр, дип исемлекне кабат тулысынча биререргә булдым (барысы да дөрес һәм анык аңлашылсын өчен һәлак булган яисә ярадан вафат булган сугышчылар турындагы мәгълүматлар русча, исем-фамилияләр дә кабер ташларында язылганча бирелә):

1. **Шайхразиев Аухади Шайхразиевич,** 1909 г.р., место рождения с.Улиманово Актанышского (Калининского) района, мобилизован Актанышским (Калининским) РВК, красноармеец, 107 стрелковый полк, погиб в декабре 1943 года *(дөресе: алган ярасыннан 1942 елның 9 сентябрендә үлә, Херенка авылында җирләнә. — Л.Л.)*, похоронен в Новгородской обл., Парфинском районе, д. Борки, братская могила (могила Штыкова). Будет занесен в 29 том Книги Памяти, без места захоронения есть в 2 томе Книги Памяти, стр.559;

2. **Аменев Нурмахмед** (Нуриахмет) **Закирович,** 1917 г.р., родился в Казани, моб. Свердловским РВК Казани, старшина, 151 стрелковая бригада, 55 стрелковая дивизия, умер от ран 24.07.1942 в 67 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Старорусский район (хәзер Парфин районы. — *Л.Л.*), д. Херенка. Книга Памяти, 11 том, стр.59;

3. **Ахмедзянов Заки Ахунович** (Гафурович), 1906 г.р., родился в с. Куш. Елга, мобилизован Заинским РВК, красноармеец, 228 стрелковый полк, 55 стрелковая дивизия, умер от ран 24.09.1942 в 67 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Херенка. Книги Памяти, 10 том, стр.32;

4. **Бурганов Мингазидин** (Мингазетдин) **Хаеткутдинович** (Хуснутдинович), 1905 г.р., г.Менделеевск, мобилизован Бондюжским РВК, гв.Старшина, 9 МСБ (ОУЧБ), 28 гвардейская стрелковая дивизия, умер от ран 15.08.1942 в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, территория Поплавского с/с. Книга Памяти, том 16, стр.295;

5. **Габаев** (Губаев) **Ахметзян Шарифзянович,** 1916 г.р., Будёновский район, с.Вольный Стан, мобилизован Дмитровским РВК Московской обл., красноармеец, 62 стрелковый полк, 10 стрелковая дивизия, погиб 08.08.1942, захоронен Ленинградская (хәзер Новгородская) обл., д. Кутилиха. Книга Памяти, том 23-1, стр.249;

6. **Гарифуллин Унус** (Юнус), 1902 (1912) г. р., совхоз им. Вахитова, мобилизован Мамадышским РВК, красноармеец, 65 гвардейский стрелковы полк, 22 гвардейская стрелковая дивизия, умер от ран 19.08.1942, захоронен Новгородская обл., Старорусский район *(хәзер Парфин районы. — Л.Л.)*, д.Замошка. Книга Памяти, 16 том, стр.68;

7. **Гильматов** (Гильманов) **Фатак** *(Фаттах, Фатых. — Л.Л.)*, родился в с. Камаево *(шагыйрь Дифгать Сирай белән Вафирә Гыйззәтуллинаның туган авылы. — Л.Л.)*, мобилизован Бондюжским РВК, красноармеец, умер от ран 24.07.1942 в 405 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородской обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр.310;

8. **Идиятуллин Рахим** (Рахимзян) **Хафиятович** (Гафиевич), 1921 г.р., с.Нижние Тиганы, мобилизован Алексеевским РВК, гв. мл. сержант, отдельный учебный батальон, 28 гвардейская дивизия, умер от ран 02.10.1942 в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр.108;

9. **Иштуков Абдулла Валеевич,** 1918 (1919) г.р., с.Куштово, мобилизован Апастовским РВК, сержант, 1318 стрелковый полк, погиб 23.02.1942, захоронен Новгородская обл,, Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти, 4 том, стр.336;

10. **Музагитов Акрам Музагитович,** 1920, Тукаевский район, д. Кугашево, мобилизован Ворошиловским РВК, гвардии лейтенант, командир строевой роты, служил 28 гвардейская химическая дивизия, 89 гвардейский стрелко-

вый полк, умер 07.07.1942 (07.08.1942) в 35 медико-санитарном батальоне, захоронен Новгородская обл., Парфинский район, д.Борки. Книга Памяти 12 том, стр.353 не все данные, войдет в 29 том;

11. **Вофин** (Вафин) **Хариз** (Харис), 1907 г.р., из г.Казани, красноармеец, пом. командира взвода, служил в 52 отдельной стрелковой бригаде, убит и похоронен 25.02.1942 в Новгородской обл., Парфинский район, д.Борки. В Книге Памяти не было данных на него, будет занесен в 29 том;

12. **Заляв** (Заляев) **Нури** (Нурияздан) **Заляевич** (Габбасович), 1905 г.р., родился в Арском районе, призывался Арским РВК, служил 107 полк, 55 стрелковая дивизия, умер 05.06.1942, похоронен 03.12.1942. *(Биредә ике кеше хакында сүз бара булса кирәк. — Л.Л.)*. Похоронен у Дома инвалидов. Книга Памяти, 5 том, стр.230;

13. **Хазлеев** (Хазиев) **Муллахмат** (Мулахмет), 1923 г.р., родился Арском районе, д.Сикертан, призывался Арским РВК, красноармеец, автоматчик, служил в 1274 стрелковым полку, 384 стрелковая дивизия, убит 17.08.1942 г., похоронен 28.08.1942 в д. Ярцево. Книга Памяти, 5 том, стр.521;

14. **Хайруллин Минихай** (Минах), 1910 г.р., родился Кукморском районе, д.Янцыбино, служил в 717 стрелковом полку, 170 стрелковая дивизия, рядовой, убит и похоронен 05.11.1942 в д.Херенка. Книга Памяти, 14 том, стр.524;

15. **Валитов Файзурахман** (Файзрахман) **Ахмедов** (Ахмедович), 1908 г. р., родился в Казани, мобилизован Верхне-Муллинским РВК Пермской обл., служил в 1276 стрелковом полку, штаб 384 стрелковой дивизии, умер от ран в 469 медико-санитарном батальоне, похоронен 03.11.1942 в д.Борки. Книга Памяти не было на него данных, будет внесен в 29 том;

16. **Шакиров Нургалей** (Нургали) **Шакирович,** 1905 г.р., родился Верхне-Услонском районе, п.Идель, служил 42 ЗАП, 52 отдельная стрелковая бригада, номерной, красноармеец, убит и похоронен 03.02.1942 в д.Борки. Книга Памяти. 8 том, стр.199;

17. **Шакирзянов** (Закиров Сабирзян Р.), 1915 г.р., г.Казань, стрелок, красноармеец, служил 52 отдельная бригада, убит и похоронен 12.02.1943 в д.Дубки (д. Борки). Книга Памяти, 11 том, стр.472;

18. **Хасанов Нури Хасанович,** родился в д. Б.Березн, мобилизован Арским РВК, красноармеец, разведчик, служил 52 отдельная стрелковая бригада, погиб 13.02.1942 и похоронен в д.Борки. Книга Памяти, 5 том, стр.557;

19. **Абдрахманов** (Габдрахманов) **Фабзраман** (Файзрахман), 1923 г.р., с.Тихие Горы, мобилизован Бондюжским РВК, красноармеец, 496 стрелковый полк, 370 стрелковая дивизия, умер от ран, похоронен 06.04.1942 в д.Борки. Книга Памяти, 16 том, стр.301;

20. **Сибгатуллин Набиулла,** 1904 г.р., мобилизован Лаишевским РВК, красноармеец, 1230 стрелковый полк. 370 стрелковая дивизия, умер от ран 05.12.1942 в 462 медико-санитарном батальоне, похоронен в д.Борки. Книга Памяти, 15 том, стр.253;

21. **Гилязов Файзрахман Гилязович,** 1905 г.р., с.Дубъязы, Высокогорский район, мобилизован Кировским РВК, красноармеец, 52 отдельная стрелковая бригада, погиб и похоронен 13.02.1942 в д.Борки. В Книге Памяти в 26 томе на стр.184 не все данные, войдёт в 28 том.

Әлеге сугышчыларның бәлки туганнары исәндер. Алар бабаларының кайда җирләнгәнен дә белми торганнардыр. Исемлектән үз бабаларын яисә туганнарын табучылар булса, зинһар, миңа яки «Безнең мирас» журналына хәбәр итсәләр иде.

...Баргач-килгәч, дип, Парфин районы хакимиятенә дә сугылып чыктык. Сәгать кичке бишләр булуга да карамастан, хакимият башлыгы Н.В.Хатунцев үзе дә, беренче урынбасары О.В.Гордеев та эш кабинетларында иде. Хакимият башлыгына чират иде, без беренче урынбасарга кердек.

Ике онык – бабалары кабере янында

Олег Гордеев, Валерий Брюсов һәм Ләбиб Лерон

Әлеге сугышчыларның бәлки туганнары исәндер. Алар бабаларының кайда җирләнгәнен дә белми торганнардыр. Исемлектән үз бабаларын яисә туганнарын табучылар булса, зинһар, миңа яки «Безнең мирас» журналына хәбәр итсәләр иде.

Олег Владимирович, безнең белән танышуга, шундук элекке танышыбыз, «Долг» отряды командиры Валерий Викторович Брюсовны кабинетына чакыртты. Җылы гына сөйләшү булды. Штыков каберлеген яңарту турында да сүз чыкты. «Бездә мондый каберлекләр бик күп, һичьюгында Штыков каберлеген төзекләндерүдә Татарстан хөкүмәте ярдәм итмәс микән, дигән теләген җиткерде беренче урынбасар. Кем әйтмешли, ә бәлки барысы да без көткәннән дә яхшырак булыр, барысы да вакыты белән уңай хәл ителер. Бер Парфин районы зиратларында гына да 30 меңләп сугышчы җирләнгән. Алар арасында милләттәшләребез күпмедер, бер Ходай гына белә! ■

ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР ХАТЛАРЫ

ВАТАН ӨЧЕН СУГЫШКА

Утыралар: Фәтхулла Килдеев, Касыйм Вахит. Аягүрә: Хәсән Хәйри, Гомәр Разин (Бәширов) һәм Афзал Шамов. 1939 ел.

Гомәр Бәширов Бөек Ватан сугышы елларында «Совет әдәбияты» журналының җаваплы сәркатибе (1941 елның 7-11, 1942 елның 1-6 саннарын чыгара), аннары Татарстан радиокомитетының баш мөхәррире һәм рәис урынбасары вазифаларын үти. 1942 елның август ахырында партиянең Өлкә Комитеты командировкасы белән Төньяк-Көнбатыш фронтның «Ватан өчен» исемле хәрби газета редакциясенә ике айга килә. Анда редакциянең эшен җайга салуда булыша, совет солдатларының батырлыклары турында очерклар яза, фронт тормышыннан бай материал җыя.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең утырышы протоколыннан (1942 ел, 17 октябрь): «Ватан өчен» газетасының мөхәррир урынбасары Гани Гыйльмановның чыгышыннан: «Гомәр Разин дүрт мәртәбә фронт сызыгына командировкага барып килде».

ТР МА. Р-7083 фонд. 1 тасвирлама. 139 эш. 21 бит. Төп нөсхә.

ГОМӘР БӘШИРОВ ХАТЛАРЫ

«ВАТАН ӨЧЕН» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕННӘН ӨЙГӘ ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

Барыгызга да күп сәлам. Менә тагы бер төн узды. Икенче поездга утырып кичә чыгып киткән идек, бүген иртә белән урман арасына килеп төштек. Моннан соң автомашина белән китәчәкбез. Гел урман арасы. Тегендә дә шулай булачак ди. Урман да күл, күл дә урман.

Килгәндә бик тыныч булды. Әйберләр генә бераз авыррак... Тегендә барып җиткәч тә хат язармын. Иптәш әйтә, бүген кичкә кайтып җитәбез, ди. Мин китәр алдыннан безнең кибеттә акны биргәннәр. Онытмыйча син дә алып төш әле. Утын алу өчен иң ышанычлы нәрсә шул бит инде. Ярый, исән булыгыз. Лилия[1] белән Зөфәргә[2] бик күп сәлам. Зөфәр мине бик әйбәт озатты.

[1] Лилия — Гомәр Бәшировның кызы.
[2] Зөфәр — Гомәр Бәшировның улы.

Лилия бик тиз күренмәс булды.

Хушыгыз.

Гомәр.
23/УШ-42. 9 сәгать.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 4 бит. Төп нөсхә.

Бу хат-открытка. Шундый адрес белән язылган: г. Казань, ул. Аккум асты, дом 9, кв.8. Разиной К.

Кире кайту адресы: Бологое, вокзал, проездом. Г.Разин.

Штемпеле буенча. Бологое, вокзал, Ленингр. обл. 24.08.42.

Казан штемпелләре: 18.09.42 һәм 19.09.42.

Һәммәгезгә дә күп сәлам.

Без Хатип белән исән-сау килеп җиттек. 3 тәүлек тулганда монда, киләсе урынга җитеп урнаштык. Бер иптәш белән икебезгә бер бүлмә бирделәр. Зурлап каршы алдылар. Яхшы ашаталар. Йокларга да бик тыныч. Бу төнне әле тегенди-мондый кош-кортлар йөри торган җир түгел. Тынычсызрак урыны бераз алдарак, диләр. Хәер, миңа анда барып кына кайтырга туры киләчәк, минем һәрвакыт тору урыным монда буласы. Тегендә барып, шул бер-ике көн генә йөреп кайтасы. Барып кайткач, тагын хат язармын әле. Киткәндә мин сиңа барын да аңлатып бетерә алмадым. Хәзер менә монда күренәрәк төшә инде. Миңа монда бертөрле дә куркыныч булачак түгел. Мине бит сугышырга дип җибәрмәделәр, ә икенче бер эш кушып, шуны эшләп кайтырга куштылар. Минем эшем шул. Менә шуңа күрә сез минем өчен борчылып тормагыз. Шул кушкан эшне яхшылап эшләп җиткергәннән соң мин һәйбәт кенә кайтып китәрмен. Мин кайтуга анда тагын әллә ничә кеше килергә чират көтеп тора.

Зөфәргә, Лилиягә бик күп сәлам. Лилия аерым хат язарсыз, дигән иде дә, әле хәзергә вакыт сыйдырмый. Берраздан язармын. Я, акыллы булыгыз.

Сагынып, этиегез.

Гомәр.
24/УШ-42 ел.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 5,5 әйл. бит. Төп нөсхә.

6 сент.

Кәримәгә[3], Бибикәгә, Лилиягә, Зөфәргә һәм бөтен туганнарга бик күп сәлам.

Әллә кайчаннан бирле җыенып йөрсәм дә озын хатны һаман язып булмый әле, эшләр күбәеп китте.

Үзем исән-сау[4]. Һаман шул иске эшемдә. Әле өйдә, ягъни төп эшли торган урында. Берәр көннән тагы әйләнеп кайтырга исәп. Машина белән йөрибез. Һавалар яхшы, ул яктан яхшы. Аннан соң ялгыз гына йөрмим, иптәшләр белән чыгам. Монда эшләү күңелле, минем өчен бер куркыныч та юк. Эшли торгач, менә 15 көне узып та китте. Тагын берике тапкыр чыгып керсәм, шуның белән кайтыр вакыт та җитәр.

Сездә ниләр бар? Хат көтеп караган идем, язарга ирендегез ахырсы, әле һаман да күренми.

Лилия мәктәпкә йөри башлагандыр инде. Ничегрәк укый икән, иптәшләренә ияләштеме икән, дәреслекләре бардырмы. Үзем киткәнче берсен дә караштырып китә алмадым. Иртә белән Зөфәрне илтеп куярга туры килә торгандыр. Менә шулай итеп бала-чагаларың булгач әллә кайларда булсаң да кайгырырга туры килә.

Ярый, җитешмәгән якларын кайткач көйләрбез инде.

Абыйның адресын сорап җибәр әле, авылдан язып җибәрсеннәр, анда бардыр.

Ярый, хәзергә башка нәрсә язып тормыйм. Бүтән бер хатта язармын, я кайткач сөйләрмен.

Исән булыгыз. Туганнарга, сораганнарга сәлам әйтегез.

Әтиегез Гомәр.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 6 бит. Төп нөсхә.

[3] Кәримә — Гомәр Бәшировның хәләл җефете.
[4] Өйдә — редакциядә.

Лилия!

Сабак укыйсыңмы? Мин кайтканчы хат язарга өйрән. Син инде рәсемнәр дә ясый башлагансың, китаплар да укый торгансың. Әниең белән апаң өйдә югында өй эшләрен син карап торгансың инде.

Мин монда бик кызык нәрсәләр күрдем, кайткач үзегезгә генә сөйләрмен әле, тик акыллы гына бул, әниең сүзен тыңла, бөтен эшне әниең әйтмичә үк эшләп куй. Син биргән көзгене өстәл өстендә онытып калдырганмын. Монда шундый кирәк булды. Хәзер күл өстенә карап кырынам.

Бик күп сәлам. Әтиең.
6/1X.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 8,8 әйл. бит. Төп нөсхә.

Зөфәр дус!

Мин хәзер комиссар булдым. Пилоткага кызыл йолдыз тактылар, сумкам бар, каешлар тактылар. Менә кайтып кергәч, әтиеңне танымый торырсың әле.

Монда бик әйбәт. Мин батыр кызылармеец абыйларның фашистларны ничек үтергәннәрен сөйләрмен. Аннан соң ничек килгәнне, ниләр күргәнне сөйләрмен. Мин кайтканчы син дәү үсә тор, бик акыллы бул.

Хәзер син бакчага да үзең генә бара торгансың инде. Я сау бул, бүтән сүзләрем дә күп иде, аларны кайткач сөйләрмен.

Әтиең.
6/1X.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 9,9 әйл. бит. Төп нөсхә.

Һәммәгезгә дә күп сәлам!

Хат язмаганга ун көннән үк артык китте бугай. Сез борчылмасын дип менә кайтып керүгә үк язарга тотындым.

Бу арада ике атнага якын командировкада йөреп кайттым. Монысы башкаларына караганда бөтенләй икенче төрле булды. Бик күп җирләр йөрдем, күп вакыйгалар күрдем. Хатка язып бетерерлек түгел, аларны кайткач сөйләрмен. Болай үзем исән-сау, бераз туңарга, чыланырга гына туры килде. Башка яклары белән чагыштырганда, монысы бик кечкенә әйбер.

Бу арада сездән хат килми. Командировкадан кайтканда хат килгәндер дип кайткан идем, язмагансыз икән. Әх сезне, ялкаулар. Менә алай булса, үзем дә язмам инде, бераз көтеп карагыз әле.

Иптәшләргә хат килә. Сездә анда килгәләп киткәннәр имеш, дип ишеттем. Кайбер кешеләр бөтенләй шүрли калганнар. Алай аһ-ваһ килерлек берни дә юк һәм булмас та, бер дә исегез китмәсен.

Малайларны сагына башладым. Зөфәр дус ни эшләр бетерә икән, Лилия туташ сабакка йөри микән? Сездә дә салкыннар була башлагандыр инде. Монда хәзер бик сизелә. Хәер, бу тирәдә саз һәм урман, һәрвакыт юеш, томан. Утын кайгырта алмагансыз инде. Әле Фатих Хөснидән[5] хат алган идем, алар утын кисәргә баралар икән. Соң булмаса, мин кайткач барырмын инде. Гумеров[6] хатында берни дә язмаган, күрәсең, теге әйберләрне ала алмагандыр. Ярый, хәерле булсын.

Үзем искечә шулай эшли бирәм. Ятутору яклары да әүвәлгечә. Килгәнгә менә бер ай да узып та китте, тагын нибары 15 көнләп вакыт калып бара. Ә эшләп бетерәсе эшләр бик күп әле. Белмим, шул 15 көн эченә сыеп булырмы, әллә бераз соңгарак калырга туры килерме.

Ә, бер яңалык бар икән. Бу чыгуда кайбер шундыйрак хәлләргә очрап, тәмәке тартырга өйрәнә башладым. Тартмыйча һич мөмкин булмады. Инде өйгә кайтканчы онытырга тырышырга кирәк.

Ярар, башка язар әйбер юк шикелле, Лилия белән Зөфәргә күп сәлам. Үзләре хат язмасалар да, мин языйм әле.

Кардәш-ыруларга, күршеләргә — һәммәсенә дә миннән сәлам.

Гомәр.

[5] Фатих Хөсни (1908-1996) — язучы.
[6] Гумеров — Абдулла Гомәр (1906-1974), Татиздатның матур әдәбият редакциясе мөдире.

Бибикамал!

Син абыйга хат язып сал әле. Минем кая киткәнне яз. Кайткач та синең яныңа барырмын, дип язган диген.

22/1X. 1942 ел.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 7,7 әйл. бит. Төп нөсхә.

Әниегезгә, Бибикәгә, Лилия белән Зөфәргә бик күп сәлам!

Кәримә абыстай, синең хатыңны алдым, шушы арада Шириязданнан да хат килде. Ул бездән шактый ерак, Мәскәүдән сулдарак икән. Исән-сау йөрим, хәзер тынычлык, кухняда эшлим дигән, синең хатны да алган.

Үзем акрын гына эшләп ятам. Әйткән вакытка кайтып булмас шикелле. Бер килгән көе тагын бераз торыйм дидем. Монда хәтле килгәч, үземнең дә күбрәк йөреп, күбрәк йөреп кайтасы килә.

Иртәгә алгы сызыкка таба чыгып китәм. Анда бер 10-15 көн йөреп кайтсам, аннан соң инде өйгә кайтырга гына җыенасы кала. Бу командировкадан 20ләре тирәсенә кайтып җитәрмен, дип уйлыйм, хәер, бәлки элегрәк тә кайтырмын. Аннан соң монда бер 10 көнләп узар. Шулай итеп, кайтышлы 1-2 көнгә Мәскәүгә дә туктасам, бәйрәмгә, я аннан бераз иртәрәк кайтып җитәрмен. Ничек тә күп түгел инде.

Монда хәзергә көннәр бик яхшы. Яңгырлар башланмады әле. Тагы бер 15 көнгә түзсә, гаҗәп яхшы булыр. Моңа кадәр бик җылы да булды. Туңарга туры килмәде. Моннан соң да шәт туңмам. К-кага[7] чыкканда өскә шинель бирәләр. Ә монда «төп йортта» торганда болай, мин киенгән киемнәр белән дә салкын түгел.

Утыннар турында теге хатта язган идем, монысында кабатлап тормыйм.

Сез хәзер бәрәңгеләр алып йөри торгансыз инде. Үзебезнең бәрәңгене алырга үзем барырмын дип йөргән идем, булмады ахрысы, кайтып җитә алмадым.

Моннан бер иптәш, шушы газетаның редакторы Казанга кайтып килмәкче була. Бәлки ул, өйдә туры китерсә, сезнең янга да кереп чыгар. Фамилиясе Гыйльманов, Кайбыч ягыныкы. Керә калса, бары белән кунак итеп чыгарыгыз. Хәер, бәлки керә дә алмас, аның вакыты бик кыска. Алай. Бәйрәмгә бик шәпләп хәзерләнәбез. Мин дә кайтып җитеп насыйп иткән булса, бер бик шәпләп бәйрәм итеп алырбыз. Шкафтагы шешәләр дә шуңа хәтле исән торсын.

Акчага бик мохтаҗ булсагыз, минем эшли торган җирдән хезмәт хакын барып алыгыз. Бераздан барсагыз, Гумеров та алып бирә алыр, «С.Ә.»[8] ннан аласы гонорар булырга тиеш.

Теге утын лапасы ясыйсы урынны кешегә бирмәскә иде. Аны Фатихка әйтеп куй. Кайткач, мин аны үзем рәтләп куярмын.

Лилия һәм Зөфәр мин китәр алдыннан хат язарбыз, дип калган булганнар иде. Ялкауландылар ахрысы, язмадылар. Шулай да Лилия яхшы укый икән. Аны ишеткәч, күңелле булып китте. Зөфәр дә бик шәп йөри икән. Мин кайтканчы алар шигырьләр дә ятлап куярлар әле. Мин кайтканчы әзерләнеп торыгыз, сез миңа шигырь, җыр җырларсыз, ә мин сезгә сугыш турында сөйләрмен. Ярыймы?

Ярар, бик озын яздым бугай, җитәр инде.

Галия апага, Саниягә, Хәбибулла абзыйларның барысына да күп итеп сәлам әйтегез.

Хәзергә җитеп торыр. Командировкадан кайткач, тагы язармын әле. Анысында кайчан юлга чыгасын да ачык итеп әйтеп булыр.

Хушыгыз.

Әтиегез Гомәр.
4/X.1942.
ТР МА: Р-6529 фонд. 1 тасвирлама.
67 эш. 10,10 әйл., 11,11 әйл. бит.
Төп нөсхә.

*Хатларны һәм искәрмәләрне басмага **Әлфия Шамова** әзерләде.*

[7] Командировкага.
[8] «С.Ә.» — «Совет әдәбияты» журналы.

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Равил Фәйзуллин

«Бу фоторәсемнәрнең «яшьләре» шактый өлкән инде. Беренчесе моннан 50 ел элек Казан университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы бүлмәсендә төшерелгән. 60 нчы еллар буынының әдәбиятка ныклап аяк басып килә торган чоры бу. Халыкның әдәби китапларны «егылып» укыган, шигъриятнең зур залларга, мәйданнарга ташкын булып чыккан чоры... Университетның әдәби берләшмәсенә йөрүче бер төркем студентлар шагыйрь Хәсән Туфан белән яңа заман шигыре турында бәхәсләшә. Сулдан уңга – Хатыйп Миңнегулов, Фирая Зыятдинова (1945-2006), ..., Равил Фәйзуллин (берләшмә җитәкчесе), Хәсән Туфан (1900-1981), Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим), Шәйхи Садретдинов (1936-1996). 28 апрель, 1964 ел».

«Икенче фото да моннан 30 ел чамасы элек төшерелгән. Бөек Ватан сугышында җиңүнең 40 еллыгына багышланган халыкара конференциядә катнашкан язучылар Пискарёв каберлеге янында. Игътибар белән карасаң, бу зур төркемдә совет һәм чит ил әдәбиятларының күп кенә күренекле вәкилләрен күрергә мөмкин. Беренче рәтне генә алыйк: сулдан-уңга — Ленинград язучылар оешмасы җитәкчесе Анатолий Чепуров, «Литературная газета»ның баш редакторы Александр Чаковский, СССР Язучылар союзы председателе Георгий Марков, СССР Язучылар союзы секретаре Юрий Суровцев, сигезенче (уртада) татар шагыйре Равил Фәйзуллин. Ленинград, октябрь, 1985 ел». ■

КАЗАН ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫННАН БЕР КИСӘК

Ибраһим Бикколов*

Хәзерге көндә безнең милли теләкләребез илә тормышыбыз бергә оешмаган төсле баралар. Без, бер яктан, яңарырга тырышабыз, һәрбер нәрсәләребезне иң кечкенәсеннән алып, иң зурысына кадәр яңартырга телибез. Яңартканда да ничек яңарту тагын? Әлбәттә, үзебез яңартыйк, һәрбер яңа эшне үзебез эшлик, һәрбер үз эшебезне үзебезнекеләр эшләсен, дибез.

* Ибраһим Җамалетдин улы Бикколов (1884-1938) – мөгаллим, мәшһүр журналист, публицист. Сембер губернасы Буа өязе Яңа Тинчәле авылында мулла гаиләсендә туа. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Мәкаләләрен «Шура», «Сөембикә», «Мәктәп», «Аң» журналларында, «Казан мөхбире», «Ил», «Бәянелхак» газеталарында бастыра. 1914 елда Томски шәһәреннән кайтып, «Кояш» газетасы редакциясендә эшли башлый. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкалә дә шушы газетаның 1914 елгы 2 декабрь санында дөнья күргән. 1917 елда исә журналист Сембердә «Җөмһүрият» исемле газета чыгара. Шунысын да искәртик, Ибраһим Бикколов сез журнал сәхифәләрендә таныша башлаган «Әхлак» әсәренең авторы Касыйм Бикколыйның (Бикколов) (1868-1937) бертуган энесе. Алар икесе дә шәхес культы корбаны.

Шуның өчен үзебездә милли газеталар, милли әдәбият, милли театр, милли музыка, милли доктор вә адвокатлар вөҗүдкә[1] китерергә тырышабыз. Миллилекне мондый фәнни, нәфис вә гали эшләрдә генә түгел, хәтта иң түбән эшләрдә дә ригая итәргә[2] телибез. Мисал: тегүчеләребез дә, итекчеләребез дә, хәтта казылыкчыларыбыз да милли булсын, дибез. Аларны да үз кешеләребездән итәсебез килә. Бер шәһәрдә бер татар кондитерский яки нинди дә бер һөнәрханә (мастерской) ачса, аңар киңәнәбез, шуның белән милләтне әллә никадәр алга киткән кебек хис итәбез. Бервакытлар Казанда «Сарай» исемендә аруырак номерлар ачылгач, Казан яшьләре вә шәкертләренең никадәр шатланганлыкларын, шуның илә милләтне әллә ничә милләр[3] алга киткән итеп хис иткәнлекләрен бер Аллаһ үзе генә

[1] Вөҗүдкә — барлыкка.
[2] Ригая итәргә — кайгыртырга.
[3] Мил — озынлык үлчәү берәмлеге,1 мил = 1,61 км.

Печән базары. Фото А.Дубин архивыннан

беләдер. Мине моны искә төшерүем бу эшләрнең вә бу шатлыкларның мәгънәсез бернәрсә икәнлекләрен әйтү максуд булмыйча, бары үзебездә милли тойгының никадәр куәтле булганлыгын, миллилегебез вә милләтебезгә ни дәрәҗәдә әһәмият биргәнлегебезне күрсәтер өчен генәдер. Милләтебезгә бу кадәр зур әһәмият биреп, милли тәзаһератебездән[4] иң кечкенәләренә кадәр бу кадәр бер бөек дикъкать берлә игътибар итүебез, аңар шатлануыбыз — бер дә шиксез куанырлык вә киләчәктә якты өмидләр бирерлек эшләр генәдер.

Ләкин шулар илә бергә, безгә, икенче яктан, шушы милли яңаруны, шушы миллилекне хәятебез күтәрә алмаган кебек күренәдер. ***Гүя без күңелебездән һәрбер милли күркәм эшне телибез вә аның зоһурына[5] киңәнәбез, әмма шул эшнең үз арабызда ныгыуына вә тамыр җәюенә тырышмыйбыз.*** Тырышмыйбыз гына да түгел, хәттә шул ук үзебезнең яңару исемле хәрәкәтләребез илә шушы милли эшләребезгә, явлениеләребезгә каршы төшәбез. Менә бер яктан яңара барып һәрбер фәнни, гыйльми, нәфис эшләрне дә, шулай ук һәрбер тормыш зарурриятләрен дә үзебез эшләргә вә үзебездән шуларның әһелләрен җитештерергә тырышуыбыз никадәр күркәм вә шатлыклы эш булса, әнә шул вөҗүдкә килгәннәрен вә булганнарын үз арабызга сыйдыра алмавыбыз, аларны үз арабызда ныгытырга тырышмавыбыз шулкадәр тәэссефле[6] эштер. Мин шушы, ягъни яңаруыбызны хәятебез күтәрә алмый, хәятебез үзенә аны сыйдыра алмый, дигән сүземен мисаллар берлә ачыграк әйтеп үтим әле.

Бер тәрәккый пәрвәр әфәндегә: «Сез татар әдәбиятыннан кемнәрнең әсәрләрен ярата төшәсез?» — дисәк, «Мин татар китапларын укып вакыт үткәрмим, Андреев, Толстойларны гына укыйм», — ди. Хәлбуки[7], ул әфәнде инде ярым-йорты русча өйрәнгәләп, берничә брошюра укыган вә шуның берлә татарның җанынннан да кадерле яңа әдәбиятына түбән карый башлаган буладыр.

Әгәр татар баена: «Сез ник татар

[4] Тәзаһер — тышкы кыяфәт.

[5] Зоһур — мәйданга чыгу.

[6] Тәәссеф — кайгыга төшү.

[7] Хәлбуки — шулай булуга карамастан.

театрына йөрмисез?» — дисәк, ул сиңа бик белгән булып: «Безнең уйный ала торган артистларыбыз вә кеше карарлык пьесаларыбыз бармы?» — дип, хәтта синең андый сөаль бирүеңә гаҗәпсенеп карыйдыр. Җитмәсә, «Шәрык» клубының бинасы кечкенә вә начар булганлыкны да бөек бер истиһза[8] берлә генә әйтеп куя, шул арада шәһәр театрында уйнаучы берничә артисткаларның исемнәрен зикер итеп аладыр. Әгәр үз артистларыбызның рус артистларыннан ким уйнамауларын исбат итә башласак, аның театрдан бернинди дә мәгълүматы булмаганлыгы күренә башлыйдыр.

Татарның русча белгәнрәгенә: «Сез кайсы татар газетасын вә кайсы журналын укыйсыз?» — дисәк, ул: «Кит аннан, кеше соң шушы несчастный листочекларны укыймы? Хәбәр дисәң, хәбәр юк, мөндәриҗат[9] дисәң, мөндәриҗат юк. Безнең татардан берни дә чыкмый инде, мин менә «Р[усское] С[лово]» илә «Нива»ны укыйм, менә по крайней мере газета вә журнал!» — дип кенә җибәрә. Хәлбуки русчаны бик зәгыйфь аңлый, татарчаны бөтен тәне вә каны илә аңлый. Бу сәбәптән татар матбугаты аның өчен файдалырак була. Моның өстенә дә юрган кадәр рус газетасында, гомуми хәбәр вә гомуми сәясәткә тәгаллекъле[10] нәрсәләрне исәпкә алмаганда, татарга кирәкле нәрсәләргә бик аз очрала. Әмма татарга иң кирәкле, татарның рухын тәрбия итә торган, татарның җан азыгы беләң кечкенә генә татар листочкаларының һәр номеры тулы була.

Татар бае мөселман докторына барса яки аны өенә алдырса, аны үз хезмәтчесе шикелле итеп, теләгәнчә аңардан үзен карата, аның әллә никадәр вакытын аладыр. Соңыннан, я чәй эчерә яисә илле тиен бирәдер. Әгәр доктор бу азрак бит, дисә, күп биргәч, мин фәлән докторга да (күп вакытны яһүди була) барам, ди. Ягъни ул акча күбрәк бирергә кызганганлыктан гына үз докторын чакырткан була.

Татар хатыннары да, шулай ук, мөселман доктор ханымы катына әллә нинди яхшы коляскаларда килеп, кыйммәтле киемнәрдән керәләр дә үзләрен караталар, рәхәтләнеп бербересен аңлаша вә шуның аркасында доктордан көткәннән артыграк файда күрәләр. Ниһаять, шул бай татар хатыны 50 тиен бирә. «Безнең докторский 1 сум иде! — дигәч, «Абау! Бер сум булгач мин П...кийгә барадыр идем, монда үз кешебез арзанрак булыр, диеп килгән идем», — ди. Янә 50 тиен җибәрергә вәгъдә итеп китәдер. Соңыннан: «Я, үзе соратмады инде, кирәк булса килеп тә алыр әле», — диеп ул илле тиенне дә җибәрми. Шул ук мөгамәлә безнең адвокатларыбыз илә дә. Алар берлә мөгамәлә иткәндә безнең үз кешебез, ди. Шуның өчен аның хакын түләп бетерми. «Әгәр түләп бетерергә булса, ул кадәр биргәч, мин фәләнгә барам», — ди.

Баласына мөгаллим алырга теләгәндә дә шулай ук. Татар шәкерте вә студенты булса, аена 5 сум бирә, башкага булганда 10-15, хәтта 20 не дә бирәдер. Монда да ул шул ук сүзне, ягъни ун сум биргәч, татар булмаганы да табыладыр, ди.

Татар хатыны кондитер нәрсәләре алганда да, үзенә киемлек алганда да читтән ала. Киемен тектергәндә дә читтән тектерәдер. Бик шык йөри торган бай бәтчә яки бай кызы вә хатыны татар тегүчесеннән эшләтми инде ул. Татар бозадыр, ди. Хәлбуки, ялгышып татар тегүчсенә китерсә, читкә бирәчәк бәһанең өчтән берен генә бирә, күбрәк сораса, Хаим Хаимовичкә дә барам, ди. Соңыннан, шул ук тегүчене киемемне бозды диеп, үпкәләп, сүгеп йөридер.

Менә шулай, безнең һәммә эшебез дә шул. Үзебезнеке булса, арзан булсын, ләкин яхшы булсын. Кыйммәт биргәч, читтән дә эшләтеп була.

Менә шушындый мөгамәләләрдән

[8] Исиһза — көлү, мыскыл итү, хурлау.
[9] Мөндәриҗ — эчтәлек.
[10] Тәгаллекъ — бәйләнеш.

соң, безнең матбугат вә әдәбиятыбыз, театр вә сәнаиге нәфисәбез[11] алга китми, зыялыларыбыз арабызда тормыйлар, һөнәрмәнд вә сәүдәгәрләребезнең эшләре алга ашмыйдыр. Чөнки татар доктор вә врачлары татар эчендә бөтенләй тора алмыйбыз вә торырга мөмкин түгел, диләр. Чынлап та, аена 30-40 сум доход илә ничек торырга кирәк? Шуның өчен аларның 90 %ы әллә нинди сирриятьле[12] авырулар берлә мөбтәля[13] булган кан карендәшләрен ташлап китеп, яки казённый хезмәткә керергә, яисә кая да булса рус арасына китәргә мәҗбүр булалар. Менә шушы 2-3 ел эчендә генә татар арасыннан 3 мөселман докторы китте инде. Тагын калганнары да казан татарлары арасында яши алачакларына ышанмыйлар.

Татар матбугаты: «Безне дә «Р[усское] С[лово]», «Нива» шикелле әллә ничә йөз мең халык укыса, безгә дә елына 3 сум түгел, 15 сум түләсәләр, без дә зур вә бай чыгар идек», — диләр. ***Татар мөхәррирләренең дә әгәр язган әсәрләре читтәрәк сатылып, аларның мәгыйшәтьләре тәэмин ителсә иде, берсеннән-берсе нәфис әсәрләр биреп торырлар, вак-төяк эшләр илә шөгыльләнеп талантларын әрәм итмәс иделәр.*** Шәрык клубының да әгъзалары күбрәк булып, театрларына халык күберәк йөрсә, доходы күп булыр иде. Доходы күп булгач, бинасын да яхшылатыр, яхшы пьесалар да куярга тырышыр, артистларга вазифа күбрәк биреп, яхшы артистлар да тотар иде.

Шулай ук татар мастерскойлары да, әгәр аларның заказчылары күп булып, тиешле бәһасе түләнеп торса, алар да Хаим Хаимич тоткан маһир хадимнәрне[14] тотып, заказны яхшы эшләр иделәр.

Гомуми эшләр вакытында һәрвакыт зыялыларга мохтаҗ булабыз. Ләкин арабызда зыялыларыбыз тормыйлар шул инде. Алар мөселман арасында тормыйча, рус арасында торуны яраталар, дип аларга ачуланабыз. Матбугатыбызда бер кимчелек күрсәк: «Шул инде, безнең татарның рәте булмас», — дибез дә, шул ук матбугат әһелен орышабыз. Хәлбуки без газеталарыбызны газетачы ятим балалардан прокатка алып кына укыганыбызны, бик һиммәт иткәндә үзебезнең урамда газета алганда бер газетага өч тиен түләмәс өчен, күрше илә компания булып кушылып, сатучы ятим бала илә ярты сәгать сатулашканнан соң, икесен 5 тиенгә алырга тырышканлыгыбызны, шушы авызын катырып, ялангач көенчә көненә ун тиен файда итәргә тырышкан бер бичараның ярты тиенен кысып, һәр көнне ярты тиен файда итүебезне егетлеккә санадыгыбызны белмибез.

Менә хәзер инде үзебездә һәммәсе бар. Үз матбугатыбыз, үз театрыбыз, үз әдәбиятыбыз, үз доктор вә адвокатыбыз, үз җәмәгать хадимнәребез, үз артистларыбыз. Ләкин без һәркайсыбыз шушыларны чын күңелебез илә теләдегебез вә шуларны булуын дүрт күз илә көттекебез хәлдә, хәзер без аларга тамыр җәеп үсеп китәргә почва була алмыйбыз. Алар безнең арада ныгый вә үсә алмыйлар, я зәгыйфьләнеп бетәләр яисә икенче почва эзлиләр. Хәзер безгә шушы күңелсез эшнең чарасын күрергә вакыт бик җиткән. ***Без моннан соң, арабызда барлыкка килгән һәрбер мәдәни чәчәкнең тамыр җәеп ныгып китүенә тырышырга, үзебездә яхшы почва ясарга иҗтиһад итәргә тиешбез.*** Минемчә, хәзерге көндә, безнең кичектерүе тиеш булмаган эшләрнең берсе дә шушы. Табигый, бу да матбугат вә әдәбият аркылы булганда тизрәк эшләнә торган эшләрнең берсе.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[11] Сәнаиге нәфисә — нәфис сәнгать.
[12] Сирриять — яшерен.
[13] Мөбтәля — дучар.
[14] Маһир хадим — оста хезмәтче.

Радионы, телевизорны кабызасыңмы, урамга чыгып, афишаларга күз саласыңмы – һәркайда җыр, җыр, җыр... Җаның теләгәне, теләмәгәне, артистлары да – үзебезнеке, үзәктән килгәне, хәтта чит илләрнеке.
Сайлыйм дисәң, чыннан да, баш әйләнерлек.

«ҖЫРЛАР ЧӘЧТЕМ БАКЧАГА...»

Фәйрүзә Мөслимова

Шулай да адәм баласының күңеле һәрвакыт җыр, моң сорап тора. Ә җырларның, бүген тыңлап, иртәгә онытылачаклары да, елларны, гасырларны (!) кичеп, юлларын киләчәккә таба дәвам итәчәкләре дә бар. Менә шушы — икенчеләре турында сөйләшкәндә, күз алдына Татарстан Республикасының фольклор музыкасы дәүләт ансамбле килеп баса. Оешуына әле 15 ел гына булса да, зәвыклы тамашачы аны яратып өлгерде инде. Алай гына да түгел, ансамбль халкыбызның борын-борыннан сакланып килгән, үзләренең башкаруында һаман да камилләштерә барган фольклор музыкасы сәнгатен байтак кына чит илләрдә дә танытып кайтты.

Нәрсә соң ул фольклор? Гади генә итеп, үзебезчә — татарча әйткәндә, без аны халык авыз иҗаты дип атыйбыз, әлбәттә. Әкиятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, җырлар... Әмма аның белән генә дә чикләнергә ярамый, ул сәнгатьнең башка төрләрен — кулларыннан гөлләр коя торган осталарның күпкырлы гамәли хезмәтләрен дә үз эченә сыйдыра бит әле. Фольклор ансамбле чыгышларын караганда, боларның барысы белән дә берьюлы танышасың — тыңлыйсың, күрәсең, онытылганнарны исеңә төшерәсең, гасырлар буе сакланып килгән милли сәнгатебезнең бүгенге чагылышына сокланып, горурланасың.

Тамашачыга инде мәгълүм «Сорнай» халык музыка уен кораллары ансамбле нигезендә, аның белән беркадәр аваздаш булып, 1999 елда оешкан бу ансамбль дә башта шул ук «Сорнай»ның җитәкчесе Ринат Гыйләҗев кул астында эшли. Өч елдан соң аңа җитәкче итеп Айдар Фәйзрахмановны чакыралар. Дөресрәге, ансамбльне оештыруда турыдан-туры катнашкан олуг җырчыбыз Илһам Шакиров үзе димли аны. Моңа кадәр Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында һәм шулай ук эстрадада җырчы буларак танылган Айдар Фәйзрахманов каушап кала, беренче фикере — бу җаваплылыктан баш тарту булса да, Илһам абыйның сүзен аяк астына салырга базмый: бер елга контракт төзеп, эшкә тотына, булдыра алмасам, китәрмен, ди.

Зур суга керү шикләндерсә дә, бер чирканчык алгач, аннан тиз генә чыгармын, димә. Айдарны да шулай үзенә бөтереп ала бу дәрья. Әйе, халык иҗаты дәрьяларга тиң, аны өйрәнергә, үзләштерергә, яңа бизәкләр өстәп, халыкның үзенә кайтарырга кирәк. Яңа бизәкләр дигәннән, кул астындагы гадәти әйберне дә — хәтта кырлы бәләк, камчы, җәя ишене дә — халкыбыз заманында уен коралы иткән. Аларның тавышын зур залларга алып чыгу өчен, «иптәшкә» скрипка, гармун, саз һ.б.ш. уен коралларын да кушып җибәрмичә булмый. Үзе бер оркестр! Ләкин ансамбль өчен аерым оркестр, аерым биючеләр, аерым җырчылар тоту отышлы түгел. Коллективның үзенчәлеге дә шунда: биредәге егет-кызлар теләсә кайсы уен коралында уйный, җырлый һәм бии дә. Кыскасы — универсаллар.

Ансамбльгә килдең икән, син инде барысына да өйрән! 16 кешелек коллектив, сәхнәне бер минут та буш тотмыйча, тамашачы күңелен тоташ биләп алырга тиеш. Айдар килгәндә дә 16 булган алар, хәзер дә шул ук санда. Әмма... беренче елларыннан бирле 38 кеше алышынырга да өлгергән икән. Иң беренчеләрдән өчәү генә калган: баянчы Айдар Хәким, Татарстанның атказанган артистлары Әлфия Мөхәммәдиева һәм Алсу Җантимерова. Сәбәбе:

беренчедән, сәхнә яшьләрнеке, ни дисәң дә, артистларның да яше бара, икенчедән, җитәкче бик таләпчән.

— Мин башта ук катгый дисциплина куйдым, эш сәгатьләре белән исәпләшүне таләп иттем, кызмача килүләрне, тәмәке тартуны чикләдем. Ике тапкыр кисәтү ясарга мөмкин әле, ә өченчесе инде булмый, хушлашырга туры килә, — дип сөйли Айдар үзе.

Тамашачыга тәкъдим ителгән концертлар — ул бит айсбергның өске ягы гына, аны әзерләү өчен күпме тырышлык, хезмәт сорала! Репертуарны да һәрвакыт яңартып, баетып торырга кирәк. Көн саен барган 6-7шәр сәгать репитицияләрне тамашачы күрми. Репертуарны да әзерләп тоттырмыйлар. Эзләнәсе, табасы — дөнья буйлап сибелгән татарларда нинди генә көй-моңнар сакланмаган! Фольклор экспедицияләре тарафыннан еллар буе җыелган хәзинәнең дә зур өлеше Татарстан Фәннәр Академиясе архивларында шулай ук еллар буе үзен үзләштергәнне көтеп яткан.

Ансамбль репертуарында хәзер кайсы гына төбәк татарларының җырбиюләре юк! Урал буе татарларының «Ак чатырлар»ы, Нижгар мишәрләренең «Кузырлыкай»ы, Свердовск өлкәсендә табылган «Зимагурлар», Себер татарларының «Ямщикәй», Казахстан татарлары җыры «Без барабыз Аскындин», Пермь өлкәсеннән «Рамбар күлләре»... Болар ансамбль хәзинәсенең кечкенә бер өлеше генә әле.

Хәзер — интернет заманы, җыр эзләүдә дә аннан файдаланып, көтелмәгән табышларга юлыгырга мөмкинсең. Әле менә Айдарның кабарда-балкар, гагауз халыклары язмаларыннан татар җырларын табып, сөенеп йөргән көннәре. Әнә, гагаузлар саф татар халык көенә татарча «Җырлар чәчтем бакчага...» дип җырлап тора. «Сез бит яшьләр, интернетны җиңел үзләштерәсез, ачыгыз, эзләнегез», — ди ул коллективтагы артистларга да.

Беренче бөтендөнья сугышында Германиягә әсир төшкән татарларның Лейпциг архивында сакланган җыр тасмалары көтелмәгән зур табыш була. Бу хакта соңгы «яңалыклар» әле күптән түгел генә халкыбызга ачыла башлады. Юкса, әлеге җырларның берничәсе кайбер журналистлар кулыннан фольклор ансамбленә иртәрәк тә алып кайтып тапшырылган инде.

Җырларда — халык язмышы, җырларда — тарих. «Герман җире — кара үлән, әллә кайтам, әллә үләм», — дип җырлап сугышка киткән күпме иргегет чит җир туфрагында ятып калган. Ансамбльнең «Ах син, заман» җырына төшергән клибында да аермачык күренә ул — Белоруссия җирләрендәге татар исемнәре язылган кабер ташлары, йөз ел элек булып узган дәһшәтле сугыш кадрлары...

Тик бу олы эшне фольклор ансамбле үз коллективында кайнату өчен генә алып бармый лабаса! Халыктан табылган бу энҗе бөртекләрен эшкәртеп, бизәп, ялтыратып, кабат халыкның үзенә кайтару — максат әнә шунда. Без яшәгән совет заманнарында иҗат оешмаларының халык арасында лекторийлар уздыру традициясе бар иде. Ул концерт-әңгәмәләрдә җырчылар, язучылар, композиторлар, журналистлар катнаша, тамашачыларны югары сәнгать үрнәкләре белән таныштыра, аларның зәвыгын тәрбияли, рухын баетырга омтыла иде. Фольклор ансамбле әлеге эшне дә фидакарьләрчә дәвам итә, дип уйлыйм. Миңа аларның Казанда да, шулай ук районда да (мәсәлән, Чүпрәледә) куйган концертларын карарга туры килгәне бар. Ансамбльнең районнарда укучы балалар өчен аерым концерт күрсәтү традициясе саклана. Концертларда халкыбызның күңел байлыклары турында мәгълүмат бирелә, сәхнәгә чыгарылган җыр-

биюләрнең тарихы искә төшерелә. Югары сәнгать үрнәкләренә баланы яшьтән үк күнектерүдән дә хәерлерәк эш булырмы? Сәнгать җитәкчесен (һәм аны гына да түгел!) бик борчый торган мәсьәлә бу. Язмамның шушы урынында Айдар Фәйзрахмановның да фикерләрен түкми-чәчми җиткерү кирәктер, мөгаен.

Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең сәнгать җитәкчесе:

— Мин хәзерге вакытта эстрада, җыр сәнгатенең торышы турында бик борчылам. Анда хәзер тулы баш-

«Онытырга мөмкин түгел» — Татарстан Республикасының фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең 15 еллыгына нәнә шундый исемдәге ике томлык китап-альбом дөнья күрде. Анда ноталары белән бергә ансамбль репертуарына кергән җыр текстлары да, гастрольләр географиясе дә, артистлар һәм коллективның башка хезмәткәрләренең фотолары һәм алар турында мәгълүматлар да урнаштырылган. Хәтта DVD һәм Mp3 дисклары да бар: укы, тыңла, кара!

Халкыбызның затлы-зыялы шәхесләре — Татарстан Республикасының мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, халык шагыйре Разил Вәлиев, академик Индус Таһиров, мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров, филармония директоры Кадим Нуруллин әлеге китапларның беренче битләрендә үк ансамбль

баштаклык хөкем сөрә. Әнә шул хәл күңелемне туктаусыз тырнап тора. Җырларыбызда милли аһәң сакланмый, эстраданың йөзе юк. Халыкка нәрсә бирә соң бу? Тузга язмаган юмор барлыкка килде. «Сүз осталары»ның сәхнәгә чыгып сөйләгән мәзәкләрен мин өч егет алдында да сөйләргә оялыр идем. Мин, алтмыш яшьлек ир-егет, аларны тыңлаганда, оялып, залдан ук чыгып китәм. Уйлап кына карагыз, базарда ит сату өчен дә лицензия кирәк. Ә без халыкка бернинди лицензиясез, рөхсәтсез, зәгыйфь рухи азык тәкъдим итәбез. Элек профессиональ сәнгать әһелләреннән торган художество советлары эшли иде, алар халык алдына көе килсә — сүзе килми, сүзе килсә — көе килми торган әсәрләрне чыгармады.

Минем, 27 ел буе опера-балет театрында, шулай ук эстрадада җырлаган (38 ел сәхнәдә — авт.) тәҗрибәле артист буларак та, югары музыкаль һәм педагогик белемгә ия буларак та, бу сүзләрне әйтергә тулы хакым бар. Мин Идел буе федераль университетында да студентларга белем бирәм. Яшьләрнең «Айдар абый Фәйзрахмановта укырга телим» дип язган гаризалары минем өчен — зур горурлык! Сәхнәдәге башбаштаклыкны берүзем җиңә алмыйм икән, минем үз юлым бар. Югары сәнгать таләпләренә туры килгән үз продукциямне киң тамашачыга тәкъдим итәм, дисклар, китаплар чыгарам — көрәш юлым шул гына. Музыка дөньясы — яшәү рәвешем, тәүлегемнең 12 сәгате шуңа багышлана.

Фольклор ансамбле республикабыз тамашачысы белән генә чикләнми. 15 ел эшләү дәверендә ул инде 40 ка якын чит илдә чыгыш ясаган. Артистларыбыз башка халыкларны җыр-биюләре белән генә сокландырып калмый, халкыбызның милли кием үрнәкләре — читек-кәвеш, калфаклары, балаитәкле күлмәкләре, чигүле алъяпкычлары…

белән дә хәйран калдыра. (Болары — оста куллы халкыбызның еллар буе сакланып килгән гамәли сәнгать үрнәкләре.) Балтыйк буе илләреме, Төркия, Монголия булсынмы, Фарсы култыгы ярларында яшәүче гарәп тамашачысымы — һәммәсе дә татар артистларын бишкуллап каршы ала, шулай итеп, дөнья күләмендә безне белүчеләр, дуслар-теләктәшләр арта. Чөнки сәнгатьтә чикләр юк. Һәр очрашу нинди дә булса үзенчәлекле яклары белән истә кала. Төрекманстанга баргач, мәсәлән, андагы телевидениедә бездәге «Җырлыйк әле» рәвешендәге тапшыруда катнашалар, Айдар Фәйзрахманов анда Сәрби исемле төрекмән кызы белән җырлый. Суданга гастрольләре илчелектә эшләүче татар егете Артур Сафуковның чакыруы белән бәйле. Оман Солтанлыгының Маскат шәһәрендәге концертлары атна буе ачык һавада алып барыла. Берсе дә онытылмый.

Әлеге язманы әзерләгәндә дә, ансамбльнең Төркиягә — Истанбул шәһәренә җыенган чагы иде. Шунда ни өчендер «Бриллиантовая рука» фильмындагы Юрий Никулин героен күз алдыма китереп, безнең артистларның да уңайсыз хәлләргә тарыганы юкмы икән, дип уйлап куям. Юк, әлбәттә, чөнки бу коллективка һәрьяктан камил булган, яки шул камиллеккә омтылган егет-кызлар сайланган: универсальлек турында әйттек инде, буй-сын, тышкы кыяфәт, акыл-фигыль, эчке культура да шундый ук әһәмиятле урынга куела. Чит илләргә чыкканчы, үзебездә йөз кат сыналган ич инде алар! Әмма... чит илләргә чыгып гыйбрәт ал, дип юкка гына әйтмиләр. Кадерле кунак булып йөреп кайталар да, «Аллаһы Тәгалә үз илебездән аермасын», — дип телиләр. Үз җиребездә таможня хезмәткәрләренең төксе каршы алуына, бөтен әйберләрен таратып салып, энә күзеннән үткәрүенә дә карамастан... ■

турындагы фикерләре белән уртаклашкан, аңа киләчәктә дә уңышлар теләгән.

«Халкыбызның милли хәзинәсе булган музыкаль фольклоры, гореф-гадәтләре сагында торучы, аны бөтен җиһанга яңгыратучы Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең киләчәге өметле», — дип яза, мәсәлән, Кадим Нуруллин.

Менә, ниһаять, китапларның беренче даналәре басылып чыга. Мондый сөенечне уртаклашырга кирәк ләбаса. Уртаклашкан сөенеч икеләтә арта дип, Айдар Фәйзрахманов аларны Республикабызның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә бүләк итеп җибәрә. Минтимер Шәрип улы да бүләкне игътибарсыз калдырмый, Айдарга бик җылы рәхмәт хаты юллый. Киләчәктә канатланып иҗат итү өчен монысы да зур этәргеч булып тора, әлбәттә.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК*

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Тырышлык илә ир максатка җитә,
Белек бел, уй уйла – эш алга китә.

Иҗтиһатка төрле язуны белсәң,
Язу-сызу белү егәрне өстәр.

Укып, язып, тыңлап галимнәр сүзен,
Егет бер көн белкә итәр үз-үзен.

Барча һөнәрләрне тәгәл белсен ул,
Шулардан йөзенә йөзгә кунсын рухи нур.

Китаплар укысын, белсен күп сүзне,
Шигырьләр сөйләсен һәм язсын үзе.

Нөҗүм[1] гыйльмен белсен, юрый белсен төш,
Аның юрамышы, сүзе килсен туш[2].

Хисапны өйрәнсен һәм һәндәсәне,
Дәрәҗә һәм тамыр, өслек исәбен.

Тагы нәрд һәм шахмат уенын белсен,
Каршыдашлары гел тар-мар ителсен.

Чәкән дә уйнасын, булсын мергән дә,
Лачынчы да булсын ауга йөргәндә.

Телләрне күп белсен – ачылсын теле,
Һәр язу укысын һәм язсын кулы.

Шулай барча кирәк ирдәмгә җитеп,
Ялавач булырга ярашыр егет.

Ялавач белемле, уяу, егәрле
Булса – бийгә терәк, яуны элгәртер.

Ялавач юньсезе – кыпчаклар колы[3],
Бийенең йөз суын түгүче булыр.

Ялавачлыкка бик батыр ир кирәк:
Тәвәккәл эшкә дә ул кылсын җөрьәт.

Бар гыйлемне белсен ялавач ирән,
Шундый булса илче төшмәс кадердән.

Ни хакта сүз чыкса да ул аңласын,
Азрак сөйләсен һәм күбрәк тыңласын.

Ялавач һәрьяктан сәләтле икән,
Абруй килгәй бийгә һәм туган илгә.

Китаплар укысын, белсен күп сүзне,
Шигырьләр сөйләсен һәм язсын үзе.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Нөҗүм: гыйльми-нөҗүм – астрономия; астрология.
[2] Диалекталь туш килү – «дөрес булып чыгу».
[3] Кыпчаклар монда «күчмәчеләр, күчмәннәр» мәгънәсендә булса кирәк.

**Кемсә бүтәннәрдән узса һөнәрдә,
Ирешер хөрмәткә, очар үрләрдә.**

Ни ди, ишет әнә, аксакал белкә
(Моны аңламаса, иргә кул селтә):

«Ирдәме илә тик казаныр ир дан,
Картаерсың дансыз, булмаса ирдәм.

Кемсә бүтәннәрдән узса һөнәрдә,
Ирешер хөрмәткә, очар үрләрдә.

Һөнәр-ирдәм илә эш итсә ирләр,
Биек тау түбәсен, гүя, иярләр».

... Әңгәмәдәш сорап, ул бирсә җавап,
Теге әйтсен: «Һай, – дип, – сүзеңә савап!»

Хәмер ул гыйлемнең, аңның киресе
«Хәмер-җәнҗал, талаш» дисәң, дөрестер.

Үзеңне тота бел, аракы эчмә,
Үзен тоткан ия булыр зур көчкә.

Белеклеләр эчсә, белексез булыр,
Белексезләр эчсә тагын ни кылыр?

Ни белемле, ушлы булса да кеше,
Эчкегә сабышса, бозар үз эшен.

Күп әдәпле, матур, алтын куллылар
Хәмер эчеп, авып, утын булдылар.

Гаҗәп ки, оятны, белемне, ушны
Сатып бер исерткеч алалар, дустым.

Хәмер эчмә, эчсәң, ир коты китәр,
Эчкеченең аты – тилемсә, тинтәк.

Мәй кергәч, авыздан төрле сүз чыга,
Бәла булып кайтыр ул әйтүчегә.

Ни дигән, ишет, бу бер шагыйрь бәйте
(Укысаң, ачылыр эчү хикмәте).

«Әгәр эчтең исә исертә хәмер,
Эчеңдәгең тышка чыгара хәзер.

Белекле исерсә, белексез булыр,
Белексез исерсә, бер юньсез булыр».

Илче теле аек, ачык, саф булсын,
Сүзе акыллы һәм остарак булсын.

Телгә оста кеше ягымлы булыр,
Сүзе үтәр, эшен уңышлы кылыр.

Хәтерле булсын ул, белсен төп-төгәл,
Ни сүз ишетсә дә алсын хәтергә.

Йөзе күркәм булсын, сакалын кырсын,
Буе-сыны белән аерылып торсын.

Үзе кыю булсын һәм дә һиммәтле:
Шулар илә арта илче кыйммәте.

*Сүзе булса йомшак, шикәрдәй татлы,
Сөчек сүзгә йомшар яше һәм карты.*

Ялавачның барча эше сүз белән,
Сүзе әйбәт булса, үтәлер теләк.

**Үзе кыю булсын һәм дә һиммәтле:
Шулар илә арта илче кыйммәте.**

Менә шундый кеше тапсаң, илбигем,
Син миңа ялавач булырсың, диген.

Һәм аны җибәр син ялавачлыкка:
Дус-ишне – якынга, читне – еракка.

*Илбик әйтте: – Оттым, ишетеп моны,
Тагын бер сорау бар, әйтеп бир шуны.*

Акыллы сүзләрең белән кинәндер,
Мәгънәле сүз хакын үтәү миннәндер.

Әйт – бетекче нинди булсын, зирәгем?
Кемгә ышанып хат яздырыр бәге?

ҮГДЕЛМЕШ БЕТЕКЧЕ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕН СӨЙЛИ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Бу эштә кул җае нык булсын, берүк.

Язуны бик яхшы белсә дә һәр бәк,
Бетекче аларга һичшиксез кирәк.

Бетекчегә әйт — ул сүзеңне языр,
Онытудан саклап күбен һәм азын.

Яхшы сүз – агар су булып чыгала,
Арык чәчәкләрне, гүя, сугара.

Бетекче сердәшкә тотнаклык мотлак,
Бетекче иманлы булсын ул чынлап.

Әгәр бетекче сер саклый алмаса,
Бий сере ачылыр, бийне үрт басар.

Бийләр серне ике кешегә сөйләр
(Бүтән барчалардан бик тә нык гизләр):

Берсе – нәкъ бетекче һәм берсе вәзир.
Шуларга илбик сер сөйләргә мәҗбүр.

Бу ике затка һич ачмый булмый сүз,
Әмма, сүз ачтыңмы, кылтыгына[4] түз.

Бу ике кешегә сөйлә ихлас сүз,
Тәнкыйтьләре булса, күтәр ачусыз.

Бу ике кешедән сүз һәрчак була,
Алар сүз тотмаса, эшне бик боза.

Ни шәп әйткән, әнә, Үтәгән[5] бийе:
«Сереңне белгәннең булсын сүз бигe».

«И, бий ышанычы, телеңне гизлә,
Тыелмаган телең муеныңны өзәр».

Авызың, гүяки, өңгер[6] кебек бер –
Бер ачылса, барча ашлык чәчелер.

Җыеп алалмассың – саны юк бөртек,
Һәм каплый алмассың сине өртеп.

Йә бер су, йә бер ут чыга авыздан,
Аның берсе төзи, ә берсе боза.

Янар ут шикелле кирәксез сүзең:
Авыздан чыгарма – көярсең үзең.

Яхшы сүз – агар су булып чыгала,
Арык чәчәкләрне, гүя, сугара.

И, галим аталмыш белекле ирән!
Исән калыр серен каты яшергән.

Ни ди, ошбу бәйтне укы әле бер:
«И, бәгырем, күңел сереңне яшер!

Серләреңне ачып әйтүдән тыел,
Бер минут әйтерсең, үкенерсең ел.

Кызыл тел ул кара башка хас дошман,
Ул дошманны кама – сөйләтмә баштан».

...Бетекче белдекле булу тиешле:
Шәп булсын язуы, имлясы, теле.

Язу булса матур, ачык һәм җиңел,
Укыйсы да килә, шатлана күңел.
Чичәнлеккә тиңдәш булса язуың,
Бигрәк матур булсын изге язма тел.

Ни ди, ишет, әнә Или чичәне:
«Нинди шәп икән бу язма чичәнлек».

Барча изге сүзләр язуда булыр,
Язылган сүз чичән үлгәч тә калыр.

Язу булса матур, ачык һәм җиңел,
Укыйсы да килә, шатлана күңел.

Язмаса язучы – бетекче бетек,
Каян килер иде хикмәтле белек?

Елъязарлар язып бармаса, инде
Үткән хәлләр ничек беленер иде?

Язу теркәмәсә ниләр булганны,
Сөяксез телгә ышанып буламы?

Илдән илгә хәбәр җибәрелгәндә
Язма сүз төплерәк була телдәрдән[7].

Никадәр зур хикмәт язу – бетектә:
Язу белән бийләр идарә итә.

[4] Кылтык – «гаепләү, бәйләнү, сереңне ачам дип куркыту».
[5] Үтәгән – төркиләрнең тәүге Ватаны.
[6] Өңгер – гомумән «елга ярын казып ясалган куышлык, КБ-тә «яшереп, ашлык саклый торган казынты».
[7] Телдәр асылда (фарсыга дилдар) – «мөһим хәбәрне ятлап алып, адресатка җиткерүче». Еш кына кирәге беткәч, хәбәрен җиткергәч ул телдәрләрнең башларын кисқәннәр.

Бий эшенә ярдәм итүче затлар,
И, илбашы, бел ки, өч төрле алар:

Берсе – тәҗрибәле бөкә, белекле,
Икенчесе – телгә оста бетекче,

Өченчесе – батыр, бөркет йөрәкле,
Дошманга — бүрегә каршы көрәшер,

Фәһем, белем, акыл иясе затлар,
Ни дисәң дә, киңәш-уңашка ярар.

Язу белән хаҗип күбрәк эш итә:
Ил керемен язып куя – беркетә.

Ә батырлар кылыч алып кулларга
Дошман мөлкен изә, эштән чыгара.

Бу ике төр кеше бергә эшләсә,
Теләгеңә киртә булмас һичнәрсә,

Болардан ары бар күптөрле катлам.
Тик алар боларның артыннан атлар.

Ил яулауда – алда кылыч һәм әләм,
Идарә эшендә – кулларда каләм.

Белек, аң ил төзү эшен башкара,
Бу өч нәрсә белән дөнья чистара.

Белек илә бийләр сәясәт кылып
Бар эшләрне эшләр акыл-уш куеп.

Кылыч ил чикләрен киңәйтер ныклар[8]
Каләм ил төзер һәм хәзинә туплар.

Кылычтан кан тамса, бие ил ала,
Каләм карасыннан алтын ясала.

Дөнья тотрыгы шул ике нәрсәдә,
Электән дә шулай, киләчәктә дә.

И, бийем, бу ике әһәмияткә
Идарәче диккать итсен, әлбәттә.

Моңа охшаш тагы шундый сүз йөри
(Аны истә калдыр, изге булгыры):

Фәһем, белем, акыл иясе затлар,
Ни дисәң дә, киңәш-уңашка ярар.

Кеше галим булса, бу — изге сыйфат,
Сугышны да белсә, бигрәк тә әйбәт.

Кылыч-корал илә нык тора илләр,
Каләм илә яшәп максатка җитәр.

... Тәмгысыз булсын ул, ачкүз булмасын,
Тугрылыклы булсын, ришвәт алмасын.

Күзе тук әйбер дип комсызлык кылмас,
Бай кешеләр дә хөсетле булмас.

Комсыз кеше әсир була әйбергә,
Күреклем, рәхимле бул син әсиргә.

Комсыз кеше, кирәк шаһ булсын, колдыр.
Җәмгыятькә зыян китергән шулдыр.

Ачкүз бетекчеләр чынлыкны боза,
Ришвәт бирүчеләр ни тели – яза.

Көмеш, алтын күрсә, шуңа күз атар,
Хуҗасының башын да сатып ашар.

Тугрылыклы хадим эшкә үч булыр,
Иртәдән кичкәчә урнында калыр.

Тугрылыкны хадим эш өчен торыр,
Тәнен, җанын, малын да фида кылыр.

... Хәмер эчмәс булсын, ару холыклы
Бозыклыктан азат, матур кылыклы.

Эчкече бетекче белемен җуяр,
Язуларны ялгыш язып та куяр.

Кятип кичә-көндез булсын катында:
Кирәгеңә әзер торсын ул шунда.

Бик тә сайлап куй ике кешеңне
(Алар башкара иң мөһим эшеңне).

Дәвамы бар

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

XI

Бу вакыйга, Садыйкның бу эше — бу егетлеге казармада иптәшләре карашыннан, бик күп сүзләргә, солдатлар арасында бик күп бәхәсләргә, бик күп кычкырышуларга сәбәп булды. Казарма халкы Садыйкның бу эшенә төрле яктан карап, төрлечә мәгънә бирделәр, Садыйкка төрлечә кыйммәт куйдылар. Садыйкның фикердәшләре, иптәшләре, әлбәттә, Садыйкның бу эше өчен Садыйкны «каһарман» (герой) дәрәҗәсенә мендерделәр, Садыйкны һәрвакыт: «Чын солдат!» — дип мактый башладылар.

Башка солдатлар Садыйкның бу эшен ерткычлыкка хисап итеп, Садыйкка бик начар күз белән карый башладылар, алар Садыйк белән сөйләшми башладылар. Сөйләгән вакытларында Садыйк тугры килсә, сүзләрен икенчегә бора башладылар, Садыйк берлә иптәшлек мөнәсәбәтен тәмам кистеләр.

Һәр нә исә, аны кайсы солдатлары бик егеткә санап, кайсылары аны бик кабахәт, ерткычка санап, аны простой солдат арасыннан чыгардылар.

Ул хәзер казарманың герое булды. Әллә ни кадәргә кадәр казарманың низаглары, кычкырышлары Садыйк исеме, Садыйкның эше тирәсендә әйләнде.

Начальство да Садыйкның бу эшен илтифатсыз калдырмады. Ул да Садыйкка егетлеге өчен: «Спасибо!» — диде. Садыйк, әлбәттә, сүздән соң, иптәшләренең күз карашыннан, бу зур дәрәҗәдән соң башын тагын бер карыш күтәрде. Ул хәзер үзен-үзе чынлап та простой солдат түгел, падишаһча, мәмләкәткә хезмәт күрсәткән солдат дип хисап итә башлады. Начальствога тагы яхшы күренер өчен, теге, моның эшен яратмаган солдатларны шымлый башлады. Аларның ни эшләгәннәрен тикшереп, берәм-берәм генә начальствога әйтеп тора башлады.

Аның сүзе берлә, казарманың Садыйкны яратмый торган солдатлары арасыннан өч солдат арестовать ителгәч, Садыйкның үзенә карашы тагы яхшырды. Ул үзенең аяк астындагы йирнең бик нык икәнлеген хис итте. Үзенең бара торган юлын бик тугры дип тәмам ышанды.

Озак үтмәде, шундый демонстрацияләрдә начальство Садыйкны 10-15 солдатка баш итеп йибәрә башлады. Садыйк, әлбәттә, начальствоның сүзен хәрефе-хәрефе белән тутырганга (төгәл үтәгәнгә), тагы «спасибо»лар ала башлады.

Берникадәр рәхмәтләр алганның соңында, Садыйк, егетлеге өчен, батырлыгы өчен, «Крест» (медаль) дә алды. Солдатларның бер төрлесе Садыйкка кызыгып карый башладылар. Садыйк кебек булыр өчен тырышып хезмәт итә башладылар. Садыйкның үзенең дә башы күккә тигән кебек булды.

Ул крестын бик кадерләп кенә тотып, бик мәшәкатьләнеп ялтыратып, шинеленең иң күренә торган урынына гына тегеп куйды. Шуннан соң, шинелен дә кадерләп, элеп кенә тота торган булды. Шул крестка караган саен Садыйкның шатлыгы арта барды. Аның күз алдына, авылы, авылларының егетләре-кызлары күренде. Ул үзен шул егетләр арасында, ялтыраган җиз крест таккан солдат киемендә итеп фараз кылды.

Аңарга, моның бу крестына бөтен авыл егетләре исләре китер, иске солдатлар көнләшерләр, авыл кызлары барысы да шуның тугрысында гына сөйләрләр кебек булды. Ул өенә дә, Гайниҗамалга да бик шәп иттереп үзенең крест алуыннан хат язды. Ул, әтиләреннән угылларының шул зур дәрәҗәсенә шатланып хат килер, Гайниҗамалдан тагын үзенең шундый сөйгәненең шундый зур кеше булуына шатлануын белдертер, дип хат көтә башлады.

Ләкин әтиләреннән, аның урынына, кара сыерның эче китеп үлү хәбәрен, Гайниҗамалдан үзен Фәхри малаена сорау хәбәрен ишетте. Садыйк аларның шундый зур эшкә әһәмият бирмәүләренә, медаль алучыны кечкенәгә санауларына, әлбәттә, кәефе килмәде. Шулай булса да: «Алар мажик шул, алар начальствоны белми шул. Медальне белми шул...», — дип күңелен җуатты.

Шулай итеп, Садыйк, медальле көенчә Лодзьда тора башлады. Аларга аларның полклары сугышка бара алмавы, Лодзьда охрана өчен калдырылуы белдерелде. Садыйк, шулай итеп, еш патрульгә чыгып, демонстрацияләрне таратырга барып, гомерен үткәрә башлады.

Озак үтмәде, сугыш бетү хәбәре килде. Садыйкның да, срогы тулып, кайтырга вакыт җитә башлады. Садыйк хәзер, авылга кайтып, яңа казаки, яңа шинель, ялтыраган итек, крест медаль тагып кайтып, авылының исен китәрүен уйлый башлады.

Озак та үтмәде, вакыйган, Садыйк, әтиләреннән: «Мылтыгым сынды, түләргә 45 сум акча булмаса, тагы ике ел солдатта калдыралар», — дигән хат белән акча алып, яңа шинель, яңа казакилар, ялтыраган итекләр киеп, ялтыраган җиз крестны тагып, өйгә таба юлга чыкты.

XII

Авыл Садыйкка тәмам үзгәргән кебек күренде. Аңа өйләренең тәрәзәләре, ишекләре кечкенәләнгән, урамнары тарайган, атлары, сыерлары, сарыклары вагайган, кешеләре картайган кебек күренде.

Вакыйган да, авыл үзгәргән иде. Баласыз кешеләр балалы булган, сакаллылары — карт булган, яшьтәш егетләре өйләнгән, ата булган, яшьтәш кызлар китеп беткән, бу киткәндә бала гына калган кызлар, кыз булып, тәрәзәләренә кызыл яулыклар корып, кич утыра башлаганнар. Моның алдында борыннан маңкасы аккан малайлар — егет булып җырлап йөри башлаганнар. Әллә нинди күрмәгән-ишетмәгән балалар берлә урамнар да тулган иде. Моңарга башка авылның борынгыдан калган тау астындагы мунчалар янындагы иске мәдрәсәсе дә ватылган. Аның урынына мәсҗед мәйданына кызыл нараттан зур иттереп, тимер белән ябып мәдрәсә салынган иде.

Садыйкларның йорты да үзгәргән иде. Садыйкның энесе Закыйр җуан гына, таза гына бер кызга өйләнгән. Садыйкның атасы тәмам бөкре карт хәлен алган. Анасы — килене берлә бер туктамыенча оршыша торган карчык булган. Садыйкка ул көнне боларның барсы да ят төсле күренде. Аңа бу кечкенә ишектән башыны бәрә-бәрә йөрү, бу сасы тирес исе килә торган мужиклар берлә эш итү авыр булыр төсле тоелды. Ул эченнән генә үзенең казармасын, үзенең иптәшләрен, үзенең начальствосын сагына башлады. Тагы күрешергә килгән карендәш-кабиләнең, дус-ишнең моның күкрәгендәге ялтыраган медаленә илтифат итмәүләре, аны күрмәгән кебек, берсенең дә: «Ни өчен бирделәр?» — дип сорамаулары моның ачуының кабаруына сәбәп булдылар. Ул аларның наданлыгы өчен, аларның хезмәт кадерен белмәүләре өчен кәефе китә башлады.

Авылда үзгәрмәгән нәрсә булса, ул да Гайниҗамал иде. Һаман элеккеге кебек тулы, һаман элеккеге кебек ачык, Садыйкны сөя иде. Шушың өстенә, Гайниҗамал

Садыйкны бик сагынган, аңарга сөйләр өчен, әллә никадәр сүзләр хәзерләп куйган иде. Бу юлы алар бик озак сөйләштеләр, бик озак сөенештеләр. Бер-берсенә ничек гомер үткәрүләрен энәдән җебенә кадәр хисаплаштылар, Садыйк, әлбәттә, үзенең «спасибо» алып медаль алуын бик озын итеп сөйләде. Ләкин Гайниҗамал да аның «спасибо»сына, аның медаленә аз гына да әһәмият бирмәде. Садыйк эченнән генә моңарга да: «Мажик!» — дип куйды. Ул үзенең тиздән, әтиләренә әйтеп, Гайниҗамалны соратачагын сөйләп, Гайниҗамалга алып кайткан бүләкләрен биреп, кайтып китте.

Икенче көнне Садыйк авылны йөрергә чыгарга уйлады. Ул бик яхшы иттереп итеген чистартты. Бик озын иттереп шинельләрен, казакиен йоннан-мамыктан арчыды. Медален ялтыратты. Аның соңында, кәкәшене кәкере генә киеп, көяз-көяз басып, урамга чыгып китте.

Ул урамдагы кешеләр берлә күреште. Күкрәгендәге медален күрсәтер өчен күкрәген киереп кенә сөйләште, сорашты. Ләкин берсе дә медаленә илтифат итмәде. Берсе дә: «Ни өчен алдың?» — дип сорамады. Ул урамнарны йөреп бетергәч, күп кешеләр берлә күрешкәч, кайтырга булды.

Түбән очтан борылып, су аша чыгып, аръяктан кайтмакчы булды. Начар юллардан, карга бата-бата, мондагы юлны Лодзь юлы берлә чагыштырып, мондагы былчырактан көлә-көлә, өенә таба борылды. Шул ара да булмады, арттан русча: «Тукта!» — дигән тавыш ишетте. Әйләнеп караса, бер әллә нинди стражникмы, урядникмы (берәүне) күрде. Стражник, урядник берлә эше юклыгын белгәнгә, Садыйк, башка берәүгә кычкыра торгандыр дип, тагы баруында дәвам итте. Теге тавыш катырак иттереп: «Әй, солдат, тукта!» — дип кычкырды. Садыйк: «Ни бар (икән)?» — дип туктады. Урыс килеп җитеп: «Ник тукта, дигәч туктамыйсың?! Син кем булдың?» — дип сүгенергә тотынды. Шуның өстенә: «Син кем? Кайдан килдең? Кая барасың?» — дип сорарга тотынды.

Садыйк моның үзе берлә шулай илтифатсыз сөйләшүенә бик ачуы килеп: «Син миңа кычкырынма! Мин синнән куркырдай түгел, миндә ни эшең бар!» — дип китә башлады. Теге тагы туктатып: «Син кем?» — дип сорады.

Боларның бу низагларын шунда, капка төбендәге берәү килеп, өзде. Ул урядникка: «Бу безнең авылның солдаты, кичә генә кайтты», — диде. Урядник Садыйкка карап, ачуланган тавыш берлә: «Син бик шәбәймә! Мин сине өйрәтермен!» — диде. Садыйк та, бик ачуы килеп: «Мин синнән куркырдай кеше түгел, мин — медаль алган кеше!» — дип китеп барды.

Урядник: «Юк, юк! Куркарсың! Өйрәтербез!» — дип, книгәсен чыгарып, теге кешедән Садыйкның исемен, атын сорап, юлына юнәлде. Садыйк шул ачуы килүе берлә өенә кайтты. Өйгә кергәч, бик көлеп-көлеп: «Мине куркытмакчы була! Мин — медаль алган...» — дип урядник белән очрашканын сөйләде. Әтисе, куркып китеп: «Каршы сөйләмисе иде. Менә шуның сүзе берлә әле мөгаллимне алып киттеләр, төрмәдә ята. Яңа мулла да, коты очып кына тора. Каршы килгәнне бер дә яратмый», — диде. Садыйк: «Мин аңарга ис китәрдәй түгел, андыйларны күргән!» — дип чыгып китте.

Озак үтмәде, Әхмәди абзый, шатлыктан, муллалар кертте. Муллалар, сөйләмәенчә генә ашап-эчеп мәҗлесне үткәрделәр. Аштан соң чәйгә алып калгач, Садыйк муллага: «Мулла абзый, син элгәре сөйләп утырырга ярата идең, хәзер картайгансың ахры», — диде.

Карт мулла: «Хәзер замана башка. Элгәре ни теләсәң, шуны сөйләргә ярый иде. Әле менә мөгаллимебезне шул юк сүз берлә алып киттеләр бит!» — диде. Садыйк та үзенең урядник белән сөйләшүен һәм дә урядниктан курыкмавын сөйләде. Тагын мөгаллимне ник алып китүләрен сорашты.

Мулла: «Хәзер шундый мода китте: куштаннар барып әйтә дә, «нутренний врак» дип алып китәләр», — диде. Садыйк боларның бәяннарыннан, эченнән генә көлеп: «Монда нутренни врак булмый. Менә безнең тегендә поляк, яврәйләр — нутренний врак», — диде.

Икенче бер кеше: «Менә шул мөгаллим йир тугрысында бик күп сөйләде. Халыкның йире юк, диде. Халыкны йирле ясарга тырышты. Шуны урядникка барып әйттеләр», — диде.

Садыйк: «Йир тугрысында сөйләргә ярамый диме?! Әнә мин, медаль алган кеше булсам да, әйтәм: авыл халкы җирсез ничек торсын?!» — диде. Шундый сүзләр белән чәй үтте. Муллалар таралдылар. Мәҗлестәге урядникның дуслары урядникка моның сүзләрен барысын да илтеп түктеләр. Ул, үз тарафыннан, Садыйкны шымлап йөри башлады. Садыйк хакында донослар яза башлады.

XIII

Садыйк кайтканга атна да үтмәде, Садыйкка Гайниҗамалны килештеләр. Әхмәди абзыйларда, Гайниҗамалларда да туй яраклары карала башлады. Садыйк әтисе берлә шәһәргә барып, Гайниҗамалга әдрәс камзуллык, төлке аягы-эчлек, күлмәклекләр, читек-кәвеш, шәлләр алып кайттылар. Садыйкның әнисе үзенең карындыкка төреп солы эченә тыккан каз түшкәләрен, он эченә күмгән йомыркаларын алып туй ашлары пешерергә хәзерләнә башлады.

Гайниҗамалларда да, машиналы тегүчеләр кертеп, камзуллар тектерә башладылар. Әхмәди абзыйлар да, тегүче кертеп, Садыйкка казаки, камзул, Әхмәди абзыйга тун тышлаттылар. Ике йортның бөтен көче-куәте туйга хәзерләнүгә сарыф кылынды. Кодалар арасында ашка йөрешү, кунакка барышу башланды.

Вәгъдәдән соң атна-ун көн үткәч, Әхмәди абзыйлар кода-кодагыйларны кунакка алдылар. Садыйкның бабасы илә әбисе дүрт кичә кунак булгач, икенче атнаны, дүшәмбе көн, Әхмәди абзый берлә кодагыйны килен күрендерергә чакырып, өйләренә китерделәр. Вәгъдә җиткәч, Әхмәди абзыйлар да кунакка киттеләр. Алар да дүрт кичә кунак булып, Садыйкка бик күп бүләкләр, бирнәләр алып, тагы ике атнадан никахка вәгъдә алып, өйгә кайттылар.

Садыйк бу көннәрдә Гайниҗамал берлә бик еш күрешеп торды. Ул, этиләренә әйтмәенчә генә, Гайниҗамалга йон күлмәк тә алды, кияү бүләкләрен этиләре кушканнан күбрәк алып кайтты. Менә туй якынлашты.

Ике йортта да туй ашлары хәзерләнеп бетте. Садыйкның анасы сумсалар, катламалар, казлар пешереп, сандыкка өеп куйды. Садыйк та, мыекларын төзәтеп, кияү бүләкләрен кечкенә сандыкка төяп, бикләп алды. Муллалардан да дүшәмбе көн өйләдән чыгуга никях мәҗлесенә вәгъдә алынды. Һәр эш тәмам булды.

Садыйк Гайниҗамал берлә кияүле-бикәчле булып йөрүне, аннан соң ирле-хатынлы булып торуны уйлап, ләззәтләнә башлады. Ул бу көнне бер зур бәйрәм итеп көтә башлады. Көннәр аңгарга бик озак үткән кебек була башлады. Шимбә көн, бик озын булса да, үтте. Ул бүген кич берлә Гайниҗамал янына барып бик озак утырып кайтты.

Якшәмбе дә үтте. Ул: «Менә иртәгә туй була, никях укыйлар. Миннән сөенче алырга киләләр. Мылтыклар атып, кыз катына китәм», — диеп уйларга, үзенең шул уйлары берлә ләззәтләнергә, үзенең матур киләчәге өчен шатланырга тотынды. Кияү кергәндә атар өчен мылтык мушкатаны эзләргә китте. Бер аучыдан начар гына мылтык алып кайтты. Энесе Закир: «Эшкә ярамый», — дигәч, тагын чыгып сатучы Фәйзидән порхлары-ниләре берлә мушкатан алып кайтты. Кич булды. Барсы да яттылар. Ул да, бүген Гайниҗамал катына бармаенча, йокларга ятты.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, бик каты ишек дөбердәтүгә Садыйк уянып кит-

те. Ул ара да булмады, түрдә әнисе ут алды. Ишек ачылды. Тыштан әллә никадәрле стражниклар берлә урядник килеп керде. Садыйк, бу ни икәнен аңламаенча, сикереп торып киенергә тотынырга өлгерә алмады, стражниклар аны чорнап алып, янындагы әйберләрне тенти башладылар.

Садыйкның атасы калтырарга тотынды. Әнисе еларга тотынды. Стражниклар кызу-кызу эзләргә тотындылар. Шүрлектән бик күп иске китаплар табып, барсын да алдылар. Сандыкларны ачып, Садыйкның сеңлесенең, киленнәренең сөлгеләрен, салфетларын бутый башладылар.

Садыйк кинәттән булган бу эштән шулкадәре исе китте, ул катып калып, бер сүз әйтә алмады. Ул эчендәге салкынлык, стражниклар берлә тыштан кергән суык берлә, дер-дер калтырый башлады. Менә озакламады ишек башыннан кичә китергән мушкатанны, порхларны таптылар. Сәке астыннан иске аучы мылтыгын өстерәп чыгардылар. Урядник боларны күргәч, әллә ни тапкан кеше кебек булып: «Әһһә, менә нәрсәләр! Менә, медальле солдат ни берлә шөгыльләнә?! — Садыйкка карап, — Әйдә, киен! Тиз бул!» — диде.

Бу сүз карт берлә карчыкка яшен уты кебек тәэсир итте. Карчык кычкырып егларга тотынды. Әхмәди бабай, белер-белмәс русчасы берлә: «Иртәгә туй!» — дип, әлләниләр бутарга тотынды. Урядник, бер сүз әйтмәенчә, Садыйкны: «Тизрәк! Тизрәк!» — дип кызуландырырга тотынды. Озакламады, Садыйкны йилтерәтеп алып чыгып киттеләр.

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Мәсгуд Гайнетдин** әзерләде.* ■

ИКЕ РӘСЕМ ТАРИХЫ

Бу фотосурәтнең төшерелүенә 56 ел булса, фотодагы шәкерткә әле нибары 23 яшь. Әмма аның уйлары бик-бик ерак узганнарда һәм әллә ни озак көтәсе калмаган киләчәктә: ул — студент.

Актёр булырга, дөньяда тирән эз калдырган шәхес образларын, җанландырып, сәхнәдән күрсәтергә җыена — хыяллана.

Хыялсыз студент булмыйдыр. Аеруча, театр әһелләре әзерләүче уку йортларында, студияләрендә.

...Кемдер «Гамлет»та — Гамлетны уйнарга җыенса, кемдер «Галиябану»да Хәлилне уйнап шаккатырмакчы. Ә менә студент Мигульчик (хәлфәләр аңа шулай дәшә иде) игътибарын Ричард-III образы (Шекспирның шул исемдәге трагедиясеннән) җәлеп итә. Ни өченме?

Холкы-фигыле белән бу студент кемнедер кабатларга, кемгәдер охшарга яратмый, күпчелек — «Гамлет» дигәндә, ул — «Ричард-III», ди.

— Ул бит явыз, үзеңә нәфрәт белән карауларын телисеңмени? — диләр аңа сабакташлары.

— Әнә шул Ричардка нәфрәтләнүләрнең чын сәбәбен ачасым килә, — ди Мигульчик һәм Шекспир әсәрләренең язылу-туу тарихын өйрәнә башлый.

Нәтиҗәдә, үзе өчен дә, безнең өчен дә кызыклы булган ачыш ясый ул: баксаң-күрсәң, Англиядә, хәзерге

көннәрдә дә Ричард-III не яклаган-яраткан җәмгыятьләр яши икән! Ягъни, чынбарлыкта, Ричард-III Шекспир тасвирлаганча ук явыз булмаган икән!

Ихтимал, шундый ачышлар торабара бу студент-актёрны драматургиягә китергәндер? Кеше — ачылмаган серләре белән кызыклы.

Шәкерт чак хыялын сәхнәдә күрсәтүгә ирешмәсә дә, Туфан Миңнуллин ярты гасыр сәхнә тотты. Әсәрләре әле бүген дә театрларны гөрләтә. Сан ягыннан Туфан Миңнуллин әсәрләре Шекспирныкылардан күбрәк булуы өстенә, дан ягыннан да ким түгел.

Аның Әлдермештәге Әлмәндәрен белмәгән татар булмаса, Ричардны тарихчылар гына беләдер.

Рәсемдә: грим буенча имтиханда төшерелгән фотода – Туфан Миңнуллин (Ричард-III). Мәскәү, Щепкин исемендәге ВУЗ, 1958 ел

Студент ***Әхтәм Зарипов*** *фотолары,*
режиссёр ***Әхтәм Зарипов*** *тексты.*
2014 ел, июль

XV-XVI гасыр татар поэзиясендә, элекке дәверләрдән аермалы буларак, сугышчы-шагыйрьләр иҗаты пәйда була. Бу осталарның иҗат үрнәкләре Әсән Кайгы (Дәрдемәнд – *М.Ә.*), Чалкйез, Казтуган һәм Дусмәмбәт кебек шагыйрьләр аша Нугай Урдасыннан телдән-телгә күчеп сакланган.

ШАГЫЙРЬ ДУСМӘМБӘТ

(XV гасырның II яртысы-XVI гасырның 20 еллары)

Марсель Әхмәтҗанов

Аларның, әлбәттә, язуга төшерелгән үрнәкләре дә булуында шик юк. Чөнки бу шагыйрьләрнең әсәрләренә дистәләгән гарәп-фарсы алынмалары һәм ислам белән бәйләнешле мәдәни күренешләр дә килеп кергән.

Әлеге шагыйрьләрнең иҗат җимешләре хәзерге заман укучысына берникадәр җиткерелде. Ләкин иҗат үзенчәлегенә, проблемаларына кагылышлы аналитик фәнни хезмәтләр әлегә күренми. XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы нугай һәм казах мәгърифәтчеләре аларның мирасын туплау юлында эшләп, шагыйрьләрнең якынча туган, үлгән елларын ачыклап, игелекле гамәл кылган*. Шуңа нигезләнеп, казах әдәбиятчылары Әсән Кайгы, Чалкийез, Казтуган һәм Дусмәмбәтне үзләренең шагыйрьләре дип саный.

Әмма бу шагыйрьләр урта гасыр татар дәүләтләрендә туган. Аларның иҗатлары да XV-XVII гасырларда оешкан һәм Алтын Урда территориясендә яшәүче күчмә татарларны берләштергән Нугай Урдасы һәм аның күршеләре Казан, Кырым, Әстерхан, Олы Урда ханлыклары әдәбияты белән бәйләнгән. Әдипләрнең әсәрләре татар телендә булып, Кавказ нугайлары телендә сакланган шигырьләре татар теленә бик якын, ләкин инде казах теленә күчерелгәннәре уку өчен кыенрак.

Алтын Урданы Аксак Тимер җимергәннән соң, XV гасыр башында Идегәй нәселе Нугай Урдасы дәүләтен оештыра. Аның әмирләре Казан һәм башка татар ханлыклары белән тыгыз этник, мәдәни, сәяси, икътисади бәйләнешта яшәгән. Башка татар ханлыкларындагы кебек, Казанда да Нугай Урдасының ялланып хезмәт итүче морзалары күп була. Әлеге этник-мәдәни мөнәсәбәтләр татар шәҗәрәләрендә [1], мәкаль-әйтемнәрдә, борынгы этнонимнарда, топонимнарда, антропонимнарда, «Идегәй», «Гайсә улы Амәт», «Чура батыр», «Таһир-Зөһрә», «Кузый Күрпәч белән Бәян Сылу», «Бүз егет», «Сәйфелмөлек» кебек дастаннарда чагыла.

Шул сәбәпле, без нугай, кырым, казах, каракалпак телләрендә борынгыдан сакланып калган истәлекләрне үз мирасыбыз итеп тә санайбыз. Югыйсә бит Алтын Урда татарларының язма әдәби мирасын үзбәк, казах, каракалпак, нугай, кумык, балкар халыклары да, гәрчә аларда борынгы кульязма текстлары сакланмаган булса да, үзләренеке итеп карыйлар.

Дусмәмбәтнең тормыш юлына кагылышлы кайбер мәгълүматлар нугай, казах галимнәре тарафыннан тупланган уникe шигырьдән табыла [2]. Алар түбәндәгедән гыйбарәт:

* Әсән Кайгы, Чалкийез, Казтуган һәм Дусмәмбәт иҗатын өйрәнүгә кумык-нугай мәгърифәтчесе Магомед Османов (1840-1904), тюрколог Василий Радлов (1837-1918), казах мәгърифәтчесе Габдулла Моштак (Гомәр Карашлов), татар мәгърифәтчесе Габдрахман Гомәри (1867-1933) һ.б. укымышлылар, галимнәр өлеш керткән. XV-XVIII гасырларда яшәп иҗат иткән Нугай Урдасы шагыйрьләренең иҗаты Алматыда басылып чыккан «Алдаспан» (Алматы, 1971); «XV-XVIII гасырлардагы казах поэзиясе» (Алматы, 1982); «Бер гасыр җырлайды. Бірінші том» (Алматы, 1984) китапларында басылды. Нугай әдәбиятчыларыннан – А.Җанибәк «Ауыл поэзиясендәге ногай әдебияты» (Мақаш-Қала, 1935) китабы ихтирамга лаек. Татар телендә: Әсән Кайгы, Казтуган җырау, Дусмәмбәт җырау, Чалгйез җырау \\ Татар поэзиясе антологиясе. I китап. – Казан: Татар.китап нәшр., 1992. – Б.131-142.; Габдрахман Гомәри. Фәнни-биографик җыентык. – Казан: «Рухият», 2002. – Б.122-133.

1) Шагыйрь татар шәһәре Азауда (бүгенге Азов) туган һәм яшәгән;

2) Аның өчен Азау Истанбулдан ким түгел, Азау — исламның бер терәге, биредә аның Ишәкәй, Кушай исемле ике улы үсә;

3) Аталары аларны алты елдан Азау каласының хуҗалары булыр дип белдерә;

4) Дусмәмбәт үзен Азауның бер почмагында үскән анар (гранат) агачы җимеше дип горурлана;

5) Дусмәмбәт үзен хан улыннан яки би улыннан да түбән санамый [3].

Олы Урда җимерелгәч, аның зур өлеш халкы Әстерханга кушылып, бу ханлыкны көчәйтеп җибәрә. Ләкин Бүз Урда (Нугай Урдасы) Әстерханның көчәюен үзе өчен куркыныч дип күрә һәм Кырымның аны басып алуына теләктәшлек күрсәтә. Шул фетнәдән соң кырымлылар Әстерханны ташлап Кырымга кайтырга чыгалар. Алар юлга чыгып өч көн үткәч, артларыннан Нугай Урдасы (Бүз Урда) гаскәре кырымлыларны эзәрлекләп килә. 1523 елның июнендә Кырым гаскәрендә, чыгышы белән Азаудан булган «бәк улы Мөхәммәд» Мәскәү кнәзе Василий Ивановичка хат җибәргән [4]. Без бу «бәк улы Мөхәммәд»не шагыйрь Дусмәмбәт белән бер үк кеше булган, дип уйлыйбыз (аның тулы исеме Дуст+Мөхәммәд булырга тиеш). Юкка гына Дусмәмбәт үзен хан улыннан, бәк улыннан ким санамый. Аларны эзәрлекләп килгән Нугай Урдасы гаскәренең башында Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй белән дус булып, Бакчасарайдан Әстерханга килгән, ханга хыянәт иткән Мамай мирза торган. Юкка гына Дусмәмбәт үлем алдыннан язган шигырьләренең берсендә аны искә алмый. Мамай мирза Кырым ханлыгы җирләренә кадәр барып җитеп, анда зур һәлакәт һәм бөлгенлек оештыра.

Июнь аендагы фетнәләр вакытында, Дусмәмбәт, Әстерханнан атта качып барганда, аның артыннан атылган уклар шагыйрьнең умырткасына һәм

Дусмәмбәтнең әсәрендә атлы сугышчының яралангач кичергән авырлыклары тасвирлана. Яралыга беренче ярдәмнең нинди булырга тиешлеге җентекле бәян ителә.

атына килеп кадала. Ярасы үзе язганча:

«Яра бик каты, җан татлы,
Яра авызына кан катты.
Яра табиблары юк микән
Ярама филтә салырга,
Җайсыз, яман калып барамын
Янымда бер туганым югыннан!» [5]

Батыр шагыйрь үлемнең күзенә карап торган һәм:

«Үкенмәстәй булганмын,
Ир Мамайның алдында.
Шәһид кичтем, үкенмәм!...»[6]

Дусмәмбәт, күрәсең, Мамай мирзаның заговорын өнәмәгән һәм үзенең үлемен шәһидләр үлеме белән тиң, дип раслаган.

Дусмәмбәтнең әсәрендә атлы сугышчының яралангач кичергән авырлыклары тасвирлана. Яралыга беренче ярдәмнең нинди булырга тиешлеге җентекле бәян ителә. Сугышчының умыртка җеге арасына ук кадала, ярадан зырлап кан ага. Аны туктатыр өчен җәрәхәткә билдә (филтә) салу кирәк икән. Бу ысул белән җәрәхәттән кан агуны туктату төрекләрдә дә мәгълүм. Билтә\\пилтә\\филтә сүзе төрек телендә дә бар. Рус галимнәре аны рус телендәге төрек алынмасы дип санайлар, татар телендә инде XVI гасыр башында ук бу сүз барлыгын белмиләр [7].

Кан агу туктатылмаса, күп кан югалтудан үлү ихтималлыгы татар сугышчыларына, әлбәттә, мәгълүм булган. Умырткадагы җәрәхәттән аккан канга кеше ялгызы гына үз-үзенә «билтә» сала алмаган. Аңа кан оешып, җәрәхәтнең авызы йомылып кан тук-

таганны күтәргә яки үләргә генә кала. Шуңа да шагыйрь янымда якын туганым да юк, дип офтана. Димәк, Дусмәмбәт дошманнардан качып барганда яраланган. Шигырьдә яраны бәйләүчеләр «җарыкчылар» дип атала. Әмма Дусмәмбәт янында алар да булмаган.

Шагыйрьнең икенче бер шигырендә җайдакка һәрвакыт кирәкле әйбер — затлы итеп эшләнгән үрмә камчы тасвирлана. Телгән тасмалардан камчы үрү өчен өч яшьлек ат тиресеннән ясалган күн каеш кирәк. Камчы сабында кулга киеп тота торган элмәк-болан тиресеннән эшләнгән каеш. Камчы сабы-җиздән, ә аңа чорнап беркетелә торган үрмә алтын белән бизәлгән.

Шагыйрь үзенең хатынын затлы нәселдән — Әли аганың кызы иде, ди. Аның матурлыгын, садәлеген, тыйнаклыгын Сөләйман Бакырганыйның «Ярты алма» поэмасында кулланылган аллегорик сыйфатлар белән мактый [8]:

«Маңгае — көнгә тимәгән,
Җилкә чәчен үрмәгән,
Сирпелеп, адәм битен күрмәгән,
Ничек көне кичте икән?» [9].

Дусмәмбәт, җитлеккән сугышчы булып танылгач, Ак Җаек буйларын, андагы Бүз Урда далаларын (ягъни Мангыт илен, Ак Урданы — Нугай Урдасын) күрәсе килеп ямансулый:

«Әйләнәсең Ак Җаек,
Ат салмый үтәр көн кайда?
Иңсәсе биек Бүз Орда,
Иңене күрер көн кайда?
Кара болан тиресен
Итек кылыр көн кайда?
Бөдерәдән бау тагып,
Кирәүкә кияр көн кайда?
Гөмбер-гөмбер кешнәтеп,
Көрәнне менәр көн кайда?
Тулгамалы ак балта,
Тулгап учлар көн кайда?
Алты колач(лы) ак нәйзә,
Очынып чәнчер көн кайда?» [10]

Шагыйрьнең бу юллары борынгы татар дастанының бер фрагменты белән авазлаш:

«Кара болыт башымнан
Китәр көне булырмы?
Карагайлы кара урман
Үтәр көнем булырмы?
Кайгыларның башымнан
Китәр көне булырмы?» [11]

Ихтимал, шагыйрьнең яшьлеге Бүз Урдада узгандыр. Ул вакытта аны көбә күлмәк, кара болан тиресеннән тегелгән итекләр, алты колачлы озын сөңгеләр, садак тулы уклар, укларның очу куәтен арттыручы «башаклар» кызыктыргандыр. Шигырьдә коралны тоту, куллануны аңлаткан терминнар да бар.

Яугир Ак Җаекның әйләнәсен атыннан төшмичә генә әйләнеп чыгу турында хыяллана. Татар халкы урта гасырларда ук инде гүзәл Җаек елгасы буйларының бөтен үзенчәлекләрен чагылдыра торган атамалар хәзинәсе булдырып, аннан үзләренә ориентир өчен практик эштә кулланыла торган белем (ягъни топонимик атамалар) алган.

Безнең эра башларына ук Җаекның төркичә исеме антик дәвер географы Птоломей (II гасыр) хезмәтенә дә кереп калган [12]. Җаек елгасы буендагы татарлар турындагы хәбәрләр XIII гасыр вакыйгаларына бәйле булган татар шәҗәрәләрендә дә күренә [13].

Кыскасы, бу шигырьдә Дусмәмбәтнең тирән белемгә ия булган һәм татар язма әдәбияты белән яхшы ук

Безнең эра башларына ук Җаекның төркичә исеме антик дәвер географы Птоломей (II гасыр) хезмәтенә дә кереп калган. Җаек елгасы буендагы татарлар турындагы хәбәрләр XIII гасыр вакыйгаларына бәйле булган татар шәҗәрәләрендә дә күренә.

таныш булган кеше икәнлеге ачыла.

Шагыйрьнең «Тугай, тугай, тугай су» дип аталган шигыре дә яугир ирнең актив тормыш шаукымы белән яшәүче шәхес икәнен сиздерә. Бу шигырьдә дә яугирнең җәясе, аннан ничек атуы, һ.б. гамәлләре тасвирлана:

«Тубырчыгына биек җәя салып,
Дошман аттым, үкенмәм.
Туганал (иярле – *М.Ә.*) *сыртлы нар* (дөя – *М.Ә.*) *җигеп,*
Күч төзедем, үкенәм.
Ту (байрак – *М.Ә.*) *койрыгы бер тотам,*
Тулпар мендем, үкенмәм,
Туган айдан нурланып,
Дулыгы (шлем – *М.Ә.*) *кидем, үкенмәм.»* [14]

Батыр үзенең төнге сәгатьләрен дә образлы итеп яза:

«Зәрле (бизәкле – *М.Ә.*) *урындык өстендә,*
Ал чыбылдык эчендә,
Толымчыгын таратып,
Ару сөйдем, үкенмәм,
Бүген соңдыр, үкенмәм,
Үкенмәстәй булганмын...» [15]

Әлеге шигырьдә шул дәвер кешесенең йокы бүлмәсен тасвирлаган сурәтләр күренә. Димәк, татарлар XV-XVI гасырларда чыбылдык эчендә йоклаган. Йокы урыны «урындык» дип аталган ятак мәгънәсендәге бизәкле мебельдән гыйбарәт.

Дусмәмбәт алдагы бер әсәрендә каты яраланып, авыр сыкраулар белән язылган юллары, шагыйрь хәленең үтә фаҗигале булуын сурәтли. Ул анда ватанына исән килеш кайтып җитәргә өмете калмаганын һәм юлдашларына әманәт итеп тапшырылырга тиешле сүзләрен әйткән:

«Узучылар, узмагыз,
Узсагыз, безнең биткә карамагыз,
Безнең биткә карасагыз,
Ишәкәй, Кушай – ике ул
Алдыгызга җир кочаклап,
Җылап чыксалар, ни әйтерсез?
Аларга әйтерсез, шул булсын:
Җимешеннән кош артып (аерылып – *М.Ә.*),
Җарага мамык түшәтеп,
Килеп ятыр, дигәйсез!
Аны әйткәнгә тимәмче –
Борынгылар төшкән, барган җул
Борылып, йөрәгенә төште,
дигәйсез!» [16]

Бу юлларда үзен авыр хәлдә ташлап калдырган юлдашларына үпкә сүзләре бар. Ул аларга үз язмышы турында гаиләсенә, балаларына җиткерүне үтенә. *«Минем ике улым җылап сезнең каршыгызга чыксалар, ятимнәргә сез нәрсә дип җавап бирерсез?»* – ди. Ул балаларына: *«Әтиегез юлда җәрәхәтләрен бәйләп калды, «җан кошы»ның җимешеннән чыгуын әйтерсез»,* – дип үтенә. Бу мотив Төрки каганат ташбилгеләрендә үк бар. Үлгән каган каберләре өстенә куелган таш сыннарда очып киткән кош сурәтен тасвир итү дә үлемнең, җан бирүнең бер символы. Төркиләр үлемне җанның кош булып очып китүе белән чагыштырган [17].

XVI гасырдагы татар кабер ташындагы шигырьдә бер егетнең җаны кош булып очып чыгу түбәндәгечә тасвирлана:

«Безем куанычымыз китте,
Мәгәр шонкар булып очты.
Табылмас эстәгәнемез
Аһ-зарларымыз берлә
Өмүтләребезне өзүб киттичидер».
[18]

Җанның кош булып тәннән очып китүе Габдулла Тукайның «Өзелгән өмид» шигырендә дә бар:

«Очты дөнья читлегеннән,
Тарсынып күңлем кошы...» [19]

Дусмәмбәтнең иҗат пафосы Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклын-

дагы «Кошчык» шигыренә дә килеп керә:

«Оч син, кошчык,
Көчле җырым булып,
Шушы сиңа соңгы теләгем.
Тәнем калсын монда,
(Нәрсә ул тән?)
Барсын илгә минем йөрәгем!» [20]

Дусмәмбәтнең шигырьләре XX йөзнең беренче чирегендә Әстерхан татарларында, нугайларда, Нугай Урдасы менталитеты югалып бетмәгән Җаек елгасы буе казахларында сакланган. Дусмәмбәт иҗаты — яугирлек поэзиясенең бер үрнәге, борынгы төрки һәм татар әдәбиятындагы традицион образлар системасының кыйммәтле мирасы. Аның әсәрләрендә көрәш мәйданын сагынып торуы күренә. Әлеге шигырьләр фәкать Нугай Урдасы дәверендәге чәчәк аткан каһарманлык дастаннары мохитендә генә туа алган. Озак гасырлар кичкән мондый әсәрләр күп булсалар да, кульъязма нөсхәләренең Урта Идел киңлекләрендә сакланып калуына шартлар булмаган. Әмма Дусмәмбәт рухы татар шигъриятендә, аеруча Габдулла Тукай, Муса Җәлилләр иҗатында дәвам итә.

1. Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. — Казан: «Мәгариф», 2002. — 343 б.; Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. — 351 б.
2. Доспамбет жырау // Алдаспан. — Алматы: «Жазушы» баспасы, 1971. — Б.66-72.
3. Алдаспан. — Б.68, 69.
4. Зайцев И.В. Астраханское ханство. — М.: Изд. Фирма «Восточная литература» РАН, 2004. — С.93.
5. Алдаспан. — Алматы: «Жазушы» баспасы, 1971. — Б.69-70.
6. Шунда ук. — 72 б.
7. Краткий этимологический словарь русского языка. — М.: Гос.учебно-пед.изд-во Министр. прос. РСФСР, 1961. — С.356
8. Сөләйман Бакыргани. Ярты алма китабы // Бакырган китабы. — Казан: Тат.кит.нәшр., 2000. — 196 б.
9. Доспамбет жырау // Алдаспан. — Алматы: «Жазумы» баспасы, 1971. — 70 б.
10. Шунда ук. — Б.70-71.
11. Авторның шәхси архивыннан.
12. Гарипова Ф. Татарская гидронимия. Книга первая. — Казань, 1998. — 244 б.
13. Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. — Казан: Татар.китап нәшр., 1995. — Б.12-16, 18-23.
14. Алдаспан... — Б.71.
15. Шунда ук. — Б.72.
16. Шунда ук. — Б.72.
17. Айдаров Г. Язык орхонских памятников древнетюркской письменности VIII века. — Алма-Ата, 1971. — С.295
18. Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. — М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. — Таблица № 61
19. Өзелгән өмид \\ Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. Т.II. — Казан: Татар.кит. нәшр., 985. — Б.150.
20. Кошчык \\ Муса Җәлил. Әсәрләр. Биш томда. Т.II. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. — Б.80. ■

Байназар Әлменов рәсеме

Кемдер калыр барыбер сагынып...

Нәсим Акмал*

Каташ-Каран авылы Минзәлә елгасының Каран инеше дип аталучы уң кушылдыгы буенда, район үзәгеннән 8 чакрым ераклыкта урнашкан. 2002 елда халык санын 402 кеше (татарлар) тәшкил иткән. Халкы игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак кәсепчелек белән шөгыльләнә. Бездә тугызъеллык мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, фельдшер-акушерлык пункты, өч кибет эшли.

* Нәсим Акмал — журналист, Татарстан радиосының әдәби-нәфис тапшырулар шеф-редакторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

1920 елга кадәр авылыбыз Уфа губернасы, Минзәлә өязе, Әлмәт-Мулла волосте составында тора. 1920 елдан ТАССРның Минзәлә, 1922 елдан — Чаллы кантонында була. 1930 елның 10 августыннан — Сарман районы составында.

1971 елның җәендә әткәй яңа йорт җиткерде. Осталар килгәнчегә кадәр, искесен сүтеп, яңа нигезгә урын әзерләргә кирәк иде. Нияз абый сабакташ дусларын чакырды да, бер көтү егет, өмә ясап, без үскән агач өйне күз ачып йомган арада сүтеп-чәчеп, җир белән тигезләп тә куйдылар. Нәкъ шул елда Нияз абый, Сарман урта мәктәбен тәмамлап, документларын Казан университетының журналистика бүлегенә тапшырып кайтты. Әнкәйләрдән ишетеп белүемчә, аңа, райкомга чакырып, Мәскәүнең халыкара мөнәсәбәтләр институтына барырга тәкъдим иткәннәр. Ул елда безнең районга нindидер бер квота эләккән булган, һәм бу мөмкинлекне мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлаган, спортта да, җәмәгать эшләрендә дә активлык күрсәткән егеткә бирергә булганнар, күрәсең. Ләкин Нияз абый мәктәптә укыган чагында ук шагыйрь булып танылган, күңелендә милли хисләр дөрләп торган, ныклы бер кыйбла тапкан егет иде. «Мин үз халкыма хезмәт итәргә тиеш!» — дип әйткән ул шулчакта әнкәйгә. Әнкәй моңа сөенгән инде, әлбәттә, Мәскәү бик ерак булып тоела иде бит ул заманда. Һәм абый Казанга юл тотты.

Иске өйне сүтеп ташлагач, аңа керү имтиханнарына әзерләнерлек урын калмады. Хәер, күршебездәге мәктәптә урын җитәрлек анысы, әткәй дә, әнкәй дә шунда эшли, мәктәп безнең өчен туган йорт кебек иде. Ләкин абый, нишләптер, безнең бәрәңге бакчасына кыйгач кына урнашкан зиратка барып укып утырды. Зиратның безгә караган башында 1920 елларда ачлыктан, тифтан үлгән кешеләрне гомуми каберлек ясап җирләгән булганнар. Ул каберләр инде иңеп беткән, тигез чирәмлек хасил булган. Менә шул чирәмлекнең бер читендә карт кушкаен үсә иде. Абый шул каенның каерылган чатына сикереп менеп утыра да, китапка чума. Әйе, ул Казан университетына керергә зиратта әзерләнде, шул зираттан олы юлга чыкты һәм... тагын 36 елдан, 2007нең 13 август көнендә, шагыйрь Нияз Акмалның гәүдәсе шушы зиратка — мәңгелек йортына кайтып керде.

Бу зиратта тагын әле әткәебез Әхмәтрәшит Әкмәлетдин улы һәм әбекәй Бибимәчтүрә Гайфулла кызы да җирләнгән. Ә инде башка әбибабайларыбызның асыл сөякләре аръяк урамы зиратында җиргә иңдерелгән.

Тик менә исеме безнең фамилиягә әверелгән Әкмәлетдин Афзалетдин улының (1884-1919) кабере билгесез. 1919 елда аны гражданнар сугышына алып китәләр. Әбекәебез Бибимәчтүрә Гайфулла кызы аны биш баласын куенына кысып озатып кала. Бу вакытта аларның иң олы кызлары Кәнделбанатка 8 яшь, ә төпчекләре Әхмәтрәшиткә нибары 6 ай була. Әткәй 1950 нче еллар башында атасының язмышына беркадәр ачыклык кертүгә ирешә. Авылның Нурәхмәт исемле аксакал карты озак еллар күңелендә саклап йөрткән серен сөйли аңа. Ул Әкмәлетдин бабай белән бергә хезмәт иткән. Бервакыт солдатлар арасында тиф авыруы котырына. Ике авылдаш Самарадагы лазаретка эләгәләр. Нурәхмәтнең хәле җиңелрәк булган, күрәсең, ул Әкмәлетдин яткан палатага кереп йөри. Бабайның хәле авырайганнан авырая бара. Соңгы керүендә аның урыны инде буш була. Монда өметсез дип табылган каты авыруларны дәвалап азапланмыйлар, лазарет янындагы чокырга чыгарып ташлыйлар икән. Нурәхмәт авылдашын эзләп, шул чокырлар тирәсендә йөри, җан биреп ыңгырашып яткан кешеләрне күрә, әмма Әкмәлетдинне таба алмый. Ничәмә-ничә буын мулла нәселенең бер

асыл вәкиле булган гыйлем зат, биш бала атасы, ниндидер бер пычрак чокыр төбендә җан биргән. Безнең нәсел кешеләре, менә шушы җинаять өчен генә дә, боларга гомерләре буе ләгънәт укырга бурычлыдыр…

Безнең нәсел Каташ-Каран авылына XIX гасырның икенче яртысында килеп төпләнә. Халкының байтак өлешен башкорт сословиесендәге җирбиләүчеләр тәшкил иткән авыл шактый ук баеп киткән, һәм балаларына гыйлем-тәрбия бирү өчен укымышлы дин әһеле таләп ителгән, дип уйларга кирәк: күршедәге Бикмәт авылыннан бабабыз Афзалетдин Хәбибулла улын (1852-1897) мулла итеп чакырып китерәләр. Аның белән бергә бирегә энесе Гыйльфан да күченеп утыра (хәзерге вакытта Галиәсгар Камал исемендәге театр актрисасы Фәридә Сафинаның әбисе ягыннан нәсел тамырлары менә шул Гыйльфан бабайның Таҗетдин исемле улына барып тоташа).

Афзалетдин хәзрәт карамагындагы мәдрәсә шактый ук абруйлы уку йорты буларак танылa. Нәкъ шул елларда биредә атаклы шагыйрь Гали Чокрыйның да хәлфәлек иткәнлеге мәгълүм. Бу вакыйга Нияз Акмалның «Үзем турында үзем» дигән мәкаләсендә болай чагылыш таба:

«Дамир абый Гарифуллинның китапларын укучылар беләләрдер: авыллар тарихын, аерым шәхесләрнең шәҗәрәләрен өйрәнүдә соңгы елларда аннан да күп эшләүче юк.

Менә шушы Дамир абый Гарифуллин, берникадәр вакыт үткәч, миңа хәбәр итә:

— Беләсеңме, мин Гали Чокрыйның эзенә төштем бит, — ди.

— Ничек? Чыннан да, безнең якларда мөгаллимлек иткәнмени?! — дим мин, гаҗәпләнеп.

— Әйе, атаклы шагыйребез Гали Чокрый синең туган авылың Каташ-Каранда, синең Әкмәлетдин бабаңның атасы Афзалетдин мулла мәдрәсәсендә укыткан, — ди Дамир абый. Соңыннан ул моны, документлар белән раслап, матбугатта язып та чыкты.

Менә шундый хәлләр. Димәк, минем әткәмнең атасының атасы әдәбиятка бер дә битараф кеше булмаган, үз янына Гали Чокрый кебек зур шагыйрьләрне чакырган…»

Афзалетдин бабабызның җәмәгате Зөһрә әби дә зур гыйлемле остабикә буларак танылa, халыкның рәхмәтен һәм ихтирамын казанып яши. Шунысы да кызыклы: Әкмәлетдиннең энесе Әхмәтсәлим Афзалетдин улы күрше Азалак авылыннан нәкъ менә Зөһрә исемле кызга өйләнә. Әхмәтсәлим абзый гомеренең соңгы көннәренә кадәр авылда мулла булып торды, Зөһрәтти абыстай вазифасын башкарды. 1990 еллар башында салынган яңа мәчеткә, дини хисләр изелгән Совет заманында авылда иман нурын саклап калган шушы батыр йөрәкле хатын-кызның рухына багышлап, аның исеме бирелде. Бу инде аның каенанасы Зөһрә остабикәнең якты исемен дә мәңгеләштерү иде.

Сүз уңаенда әйтеп китим: Нияз Акмалның «Күгәрчен сөте» повестенда нәкъ менә шушы гаилә игътибар үзәгенә алынган. Мулла Әхмәтсәлим абзый һәм аның улы — колхозның партия оешмасы секретаре Әсгать Сәлимов бер йорт эчендә дуслыкта-татулыкта гомер иттеләр. Уникаль күренеш иде бу. Шушы хәл үз вакытында күп кенә шикаятьләргә дә сәбәпче булды. Әмма Әсгать абый, бернигә карап тормастан, «перспективасыз» дип табылган авылны саклап калу, үстерү өчен тырышты һәм морадына иреште. Аңа партия билеты шуның өчен генә кирәк булгандыр да әле. Заманалар үзгәргәч, ул, уллары Әхсән һәм Тәлгать белән бергәләп, мәчет салуда башлап йөрде, мәхәллә җитәкчеләренең берсе булды.

Шунысы да кызыклы: Афзалетдин бабайның мәгърифәтчелек эшен Совет елларында аның оныгы — безнең әткәебез Әхмәтрәшит Әкмәлетдин улы (1919-1984) дәвам иттерде. Ул

хезмәт юлын 1939 елда Сарман урта мәктәбендә математика укытып башлый, 1940 елда армиягә алына, сугыштан кайткач, Кәүҗәк, Янурыс авыллары мәктәпләрендә директор булып эшли, 1960 еллар башында үзебезнең авылга кайта, Кала таудан чыгарылган таштан зур мәктәп салдыра. Әткәй озак еллар дәвамында шушы мәктәптә җитәкчелек итте. Ә инде 1990 елларда биредә аның улы — безнең олы абыебыз Әхмәтнәҗип Әхмәтрәшит улы (1948) директор булып эшләде.

Инде авылыбызның тарихына тукталыйк. «Татар энциклопедиясе»ндә, авылга XVII йөздә нигез салынган, дип мәгълүмат бирелә. Ләкин бу ышандырмый. Чөнки мәкаләнең авторы авылның үзен барып карамаган, бәлки архивтан табылган иң әүвәлге документка гына



Нияз Акмал туган нигездә атасы Әхмәтрәшит Әкмәлетдин улы һәм анасы Хәлимә Шиһабетдин кызы белән. 1980 ел

нигезләнеп фикер йөрткән, күрәсең. Ә бит иң беренче эш итеп, авыл янындагы географик атамаларга игътибар итәргә кирәк иде. Каташ-Каран авылы Кала тау дигән биек калкулык итәгендә урнашкан. Бу тау якын-тирәдәге 30-40 чакрымда доминанта булып тора. Без бәләкәй чакларда Әхмәтсәлим абзыйның: «Элек һава чиста иде, якты-аяз көннәрдә Кала тау башыннан Чаллы элеваторын шәйләп була иде», — дип сөйләгәне хәтердә. Ә Чаллыга бездән кош юлы белән 50 километр чамасы. Чик буйларыннан үзәккә хәбәр бирү өчен кулланылучы Кала таулар системасы Идел буе Болгар дәүләте чорында ук барлыкка килә ләбаса. Ә инде хәбәр бирү тавы бар икән, димәк, аның итәгендә хәбәр бирүчеләрнең торак пункты да урнашкан булган. Кем белә, XIII гасырда монгол чирүенең якынлашуы турындагы дәһшәтле хәбәрне Болгарга безнең бабайлар җиткергәндер.

Аннары безнең авылның урыны, ландшафты да торак пункт салу өчен махсус ясап куелган шикелле бит: янәшәдә генә балыкка бай Минзәлә елгасы, болынында билдән печән үсә, әрәмәләр киек кош-корт белән тулган. Кырларда уңдырышлы кара туфрак. Биек басулардан ике инеш йөгереп төшеп, авылның нәкъ уртасында кушыла, һәм юлын Минзәлә елгасына таба дәвам иттерә. Шул инешләрнең ярларына яраклашып, ике төз зур урам, Урта урам, Чүкеч урам барлыкка килгән. Менә шушы мантыйкка нигезләнеп фикер йөртсәк, авылның күпкә алданрак, Болгар дәүләте чорыннан ук яшәп килүе күзаллана.

Авылның атамасына килсәк, ул нәсел-ыру исменә бәйле, дип фаразланыла (борынгы җанисәп материалларында бу атама «Каран при реке Каташ» дип күрсәтелә). Каран исеме белән аталучы берничә авыл мәгълүм. Аларның беренчесе әүвәлге заманнарда хәзерге Арча районы территориясендә булган, хәзерге Сарман районында Каташ-Каран һәм Яхшы Каран дигән атамалы авыллар бар, Башкортстан җирендәге Җилем Каран авылында татар әдибе Мәҗит Гафури туып үскән. Кыскасы, бу авылларның тарихын өйрәнеп, бер нәсел-ыруның үткән юлын күзаллап булыр иде. Ләкин монысы аерым тикшеренүне таләп итә торган мәсьәлә.

XX гасыр башында Каран тирәюньдә иң тернәкле авылларның берсе була, аны халык телендә «Байлар авылы» дип тә йөртәләр. Халкы игенчелек һәм терлек үрчетү белән шөгыльләнә. Авылда мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч, 3 ашлык киптергеч була. Бу вакытта авылның җир биләмәсе 2315,6 дес. тәшкил итә. Каранны Сәхау, Ахун, Гали байлар тотып тора. Алардан калган зур таш амбарлар озак еллар колхоз складлары буларак файдаланылды. Гали байның милли архитектура үрнәге итеп бәяләнерлек утары 1990 еллар башында сүтелде. Аның беренче каты таштан, икенче каты агачтан төзелеп, тәрәзә йөзлекләре, кәрнизләре, яңгыр колашалары, хәтта калай морҗаларына кадәр милли орнаментлар белән бизәкләнгән иде. Бу бинаның бер өлешенә бригада йорты, калган бүлмәләренә медпункт, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты урнашкан иде. Гали байның таш амбарлары, ат абзарлары да колхоз милке булып торды. Авылның борынгы мәчете 1930 елларда сүтелә. Аның манарасын Җәзекәү (Языково) авылыннан килгән кешеләр кискән, дип ишеткәнем булды. Элек кантон үзәге булып торган бу рус авылы хәзер таркалып беткән инде. Мәчет материалларын идарә йорты, аннары мәктәп интернаты төзегәндә кулланганнар. Бу бина әле дә исән, ул безгә күрше генә урнашкан мәктәп ишегалдында буш тора.

Совет чорында авылда оештырылган колхозга, ни өчендер, «Марс» дигән исем биргәннәр. Сугыштан соңгы елларда хуҗалык киндер орлыгы сатып, республикада беренчеләрдән булып миллионер колхозлар исемлегенә

керә. Киндер суктыру комбайнын күрше Янурыс авылындагы һәвәскәр уйлап табучы Гарифетдин Шиһапов ясый. 1950 еллар ахырында «Марс» колхозы әнә шул янурыслылар белән берләшеп, Серго исемендәге зур хуҗалык барлыкка килә.

Шагыйрь һәм прозаик Нияз Акмал — менә шундый тирән тарихлы авылга килеп төпләнгән дин әһелләре нәселенең затлы бер вәкиле. Без язучының әсәрләрендә авылның үткәнендәге вакыйгаларны, аның үзенчәлекле характерлы кешеләрен танып алабыз. Мәктәп елларында ук ул район газетасында «Ярлар һәм яралар», «Такташка җавап» исемле поэмалар белән беррәттән, «Сугыш тавы» дигән күләмле шигъри әсәрен дә бастырып чыгарды. Биредә Янурыс авылы белән Каран халкы арасында барган низаг сурәтләнә. Шушы ике авыл арасында кайсыдыр бер заманда Минзәлә болыннары өчен тартыш барган, кайбер елларда бу бәхәс йодрыклап сугышуга чаклы барып җиткән. Караннар җиңеп чыккан, әлбәттә. Шушы сугыш булган калкулыкны әле бүген дә «Сугыш тавы» дип атап йөриләр. Әсәрдә әлеге ике авыл халкының Совет чорында бер колхоз булып, дуслыкта-татулыкта яшәве сурәтләнә. Нияз абый, зур шагыйрь булып киткәч, бу поэмасын беркайчан да кешегә күрсәтмәде, кемгәдер сөйләгәнен дә хәтерләмим, ләкин әсәрнең күп кенә детальләрен без аның «Сарман җыры» поэмасында очратабыз. Шагыйрьнең «Гармунчы Әүхәт», «Нәҗибә апа», «Зиратта» кебек шигырьләрендәге, «Серле кайтаваз», «Кол» повестьларындагы портретлар туган авылының конкрет кешеләренә нигезләнеп тудырылган.

...Нияз Акмал Каташ-Каран авылы зиратында мәңгелек йокыга талган. Аның кабер ташына үзенең шигыреннән «Кемдер калыр барыбер сагынып...» дигән сүзләр уеп язылган. Туган туфрак, үзеннән ялралган баласын, читләргә җибәрмичә, куенына алды. Әби-бабайларыбызның маңгай тире тамган, дин өчен, дәүләт өчен барган аяусыз яуларда каны коелган, никадәр тарихның шаһиты булган изге, мәрхәмәтле туфрак! Шагыйрьнең шушы туфрактагы гүре нурлы, җылы булса иде, дип дога кылыйк.

Чыганак:
Башкорт әдәбияты тарихы. Т.2. — Уфа, 1990. 186.
ЦГИА РБ. Ф.172, Оп.1, Д.104, Л.35.
РГАДА. Ф.350, Д. 3801 (команда старшины Суюндука Тукбаева).
ЦГИА РБ. Ф.138, Оп.2, Д.292; Ф.172. Оп.1, Д.150.
Населенные пункты Башкортостана. Ч.1. Уфимская губерния. — С.302; ЦГИА РБ. Ф.138, Оп.2, Д.755, Л.767. ■

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Нифакъ[22] выставкасында күп медаль алганымыз бардыр.

● Закон белгән юрист юк бездә, дип уйлау хата хәтта, печән, шалкан базарында закон сатканымыз бардыр.

● Чабатаң берлә, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?

● Бер якка кит! И печән өстендә өргән һәм талашып яткан эт!

● Халкыбыздан зарлану өчен, Тәңрегә киттегезме?

● Юкмыдыр һич тә хәдәсханә[23]? Ни өчен бу бәдбәхетләр матбага өстендә эш рәтли?

● Кире кайтыр — төкермә җилгә каршы... Кире төште угы башына, Нәмруд атып баккан иде Җәбраилгә каршы.

● Усаллык хәзинәсе бик зур ул — күпме алсаң да бетми.

● Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа, әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа.

● Сүземә карагыз — юллар ачармын, үземә бакмагыз — үзем начармын.

● Әгәр шатлык, бәхет килсә — хәзерләрсез бүләргә сез; әгәр ямьсез вакыт килсә — хәзер миннән көләргә сез.

● Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк; ни сәбәптән Җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!

● Кара карга вә «бөлгән бай» юып асла бәяз[24] булмый.

● Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар, былбыл урынына оя торткач башында каргалар.

● «Шайтан аздырган», имеш! «Юлдан яздырган», имеш! Кире татар, иң элек вөҗданың берлән килеш!

● «Әгузе», дип кенә төшмәс, муенга шайтан атланган.

● Әгәр рухыңны ислах итми үлсәң, барыбер син газапта... Газап китми кабердә тән черүдән.

● Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим.

● Синең тик сурәтең китте җиһаннан, һаман да калды рухың яки мәгънәң.

● Үз рухының матур ягын вә идеалының изге иканен халык күзгесеннән үз күзенә күрсәткән чакта күңеле тулмаган кеше таш йөрәкле булырга тиештер.

● Авызы кыйшык кешенең авызын туры күрсәтмәгән өчен көзгене атып бәрмәсен.

● Рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын.

Дәвамы. Башы журналның 9 нчы санында.

***

● Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап; җан сатабыз әллә нинди вак «тиен»нәргә карап.

● Акчалар уйнарга дәртне кузгатадыр шалтырап.

● Һәр ялтыраган алтын түгел.

● Йөз сумны урлап килгүче угъры кеби, күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без. Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга, гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

● Акча барда бар да дуст шул, бар да яр; акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!

● Әгәр бер карак, урлаган әйберен култык астына гына тыккан булып, үзе кулларын болгап сугышса вә хәрәкәт итсә, аның әйбере һәрвакыт җиргә төшеп, үзеннән аерыладыр.

● Кешеләр үзләрен анчак сөярләр, бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр.

● Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә: син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә!

● Килсә теләнче капкаңа, каты сүзләр берлә инсаниятен таптама... Булса — бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын.

● Бер теләнче керсә йортка, син бирә алсаң бер телем — әй була җанга хозур! Шатлыктан әйләнми телең.

● Мескин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә, ямьсез якны уйлап куя эчтән генә.

● Җиһан шатлык белән хәсрәтне бер җиргә җыйган.

● Ачлык, салкын, ялангачлык — өчесе берьюлы һөҗүм иткәч, адәм түгел, дию дә чыдамас.

● Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята, «Торып нәрсә бар?» — ди.

● Сахрадагы ялгыз, ярдәмсез кешегә бүре авызына керү дә, ачлыктан үлү дә фәрекъсездер.

● Михнәт үтсен генә, адәм баласы тиз оныта аны.

● Әүкатлене[25] тешли алмый салкын, суык.

● Мөсриф[26] кеше белән мөкътәсыйд[27] арасында аерма шул гына: берсе — хәзерге минутның яхшы үтүен тели, икенчесе — киләчәк көннәрнең матур булуын көтә.

● Кулда — бильярд, карталары, эчеп сыра, тарта бары: бетерү җиңел ата малы.

● Мәкаль бардыр: «Урыс баеса — сала авылында дәү чиркәү; татар баеса — хатын асрый, була хатыны өчәүдүртәү».

● Татар бае гәзит сөйми.

● Бер көн килер дә өйрәтер, әлбәттә, ләхет, миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс... Анда адвокат та юктыр — акчага ялланмыйлар.

● Онытма: бер заман гүргә керер ялгыз башың; һичберәү булмас яныңда: иптәшең һәм кардәшең.

● Ул — уянмас бер йокыдыр, аһ, аның исеме — әҗәл!

● Урам — дию кеби. Һәркөн үзенә бер-ике корбан алмый калмый.

● Байлар авырый башлагач та, каберен казып куялар; фәкыйрьләрне үлгәч тә өч көн ишетмиләр.

● Байлар үлсә, оҗмахлы икәнен хәерчеләр дә белә, фәкыйрьләрнекен ишаннар да белмиләр.

● Кирәк черсен, кирәк торсын — ни ул тән? Чыдамсыз бер кием ул җанны өрткән!

● Больница хадимнәре миңа: «Ник алданрак больницага кермәдеңез?» — диләр. Мин аларга: «Без больницаны үлемнең әүвәлге стансасы дип беләмез. Аз булса да дөньяда торып калыйм дип әйттем», — дидем.

● «Үлемгә каршы дәва юк», — дигән булалар, вәхаләнки[28] терек тору үлемгә каршы иң яхшы дәва.

***

● Дөнья яратылганнан бирле ялганнар күбесенчә тотылмый калган.

● Хаклык үзенә ярүчене һәрхәлдә кире какмас; ялганны ялганга чыгарыр.

● Хаклык зәгыйфь дип куркып, юлыгыздан чыктыгызмы? Тоткан юлны ташлау сезне, әлбәттә, бәхетле итмәс.

● Булса ялган, тик кәгазьләрдән ясалган бер чәчәк — билгеле, үз өстенә яңгыр явардан куркачак.

● И Җир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы. Хаклык астка күмелгән шул, өсттә түгел, шуның өчен астка табан тарта күңел.

● Бүген кыямәт: дөреслек кояшы тотылды.

● Тугъры әйтергә яраганда, киная-ләргә сыгыну нәрсәгә?

● Татар болай һич аңламас, төртеп күрсәтмәсәң күзенә.

● Китмәсен хак сүзгә һич кәефең синең.

● Китмәсен кәефең... денсез дисә-ләр дә, син аларга бал биргәндә сиңа агу бирсәләр дә... Һәр заман хак-ны сөючеләр сездәй каһәрләнгән бу-лыр; килер бер көн: милләтең сиңа шәфкатен күрсәтер.

● Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдан белик, мескин үлеп аңлатмагач?!

● Милләтемез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өсткә калка шул.

***

● Бу тәдавел ширбәтен[29] халыкка эчергән дөньядыр.

● Бераз вакыт шатлык таба исерек кенә, үз-үзенә ачы агу эчереп кенә; «Әмма дөнья нинди кызык, нинди хо-зур, бу дөньяда кемнәр бар, — дип, — миннән дә зур!»

● Үз ролендә булмаган кеше кәмит соң!

● Әгәр күрсәң кызарган йөз аларда, бер дә алданма: «Оялгандыр», — димә яңлыш, «Җибәргәндер», — дисәң — әүлия[30]!

● *Җөрмә монда, кайт илеңә,*
Илеңдә иген игәрсең;
Стаканыңны ат итеп,
Бутылкаңны җигәрсең...

Чынлап та, сукасын, сабанын, әве-нен, хатын, бала-чагасын онытып эчеп утырган бер сала мужигына, шулай итеп, каладан китәргә киңәш бирмичә, ни дип әйтергә кирәк?!

● Бәхете барлар кырда җәйли.

● Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт! Яшә, тугъ-ры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!

● Гакылым берлә... кул талаша.

● Безнең бәйрәм итәргә хакымыз юк.

● Моны яздым, киңәш бирдем, юат-тым һәм тыйдым, куштым; шулай бул-мыйча хәл юк, инде калган мин генә дустың!

***

● Дуслык булмау сәбәпле, милләт шушы хәлгә килде — гыйбрәт ал, и Мөхәммәд өммәте! Алла гыйшкы ха-кына.

● Без дә бер кешедәй дус булыйк Алла гыйшкы хакына.

● Тәнемез аерым булса да, бер җан булыйк.

● Бүлик без бер алманы биш кисәк-кә... Җыйналып мәҗлес ясыйк, бер-беремездән качмыйк.

● Юк шул безләрдә берләшмәк; юк бергә-бергә гөрләшмәк, бер җан, бер тән булып, һәр нечкә серне бергә серләшмәк.

● Бар мөселман була алса иде бер гәүдә.

● Кеше ата берлек белән туган түгел, бәлки фикер һәм тоткан юлы белән кардәш була.

Сүзлекчә

[22] Нифакъ — икейөзлелек;
[23] Хәдәсханә — бәдрәф;
[24] Бәяз — ак;
[25] Әүкатле — бай кеше;
[26] Мөсриф — малны урынсызга туздыручы;
[27] Мөкътәсыйд — малны саклап тотучы;
[28] Вәхаләнки — чынлыкта;
[29] Тәдавел ширбәте — үзгәртә, бүтән халәткә алмаштыра торган эчемлек;
[30] Әүлия — дөресрәк;
[31] Там — тәгәл.

Дәвамы бар

*Текстны басмага **Зиннур Мансуров** әзерләде.* ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

СӘМИТОВА ФӘХЕРНИСА (1890-1939), драма актрисасы, Хезмәт батыры (1926). Сәхнәдәге эшчәнлеген 1908 елда, Түбән Новгородка (Мәкәрҗә ярминкәсенә) килгән «Сәйяр» труппасына кушылып башлап җибәрә һәм тиздән труппаның төп артисткаларыннан берсе булып китә. Мәкәрҗәдә куелган «Бәхетсез егет» спектакльдә аның асрау кыз Камилә образында чыгыш ясавын Г.Камал һәм Г.Тукайлар да тамаша кылалар. 1939 елда башкорт театрында (Уфада) Әхмәт Фәйзинең «Тукай» пьесасы буенча куелган спектакльдә Мәрьям образын башкарган. Шул ук спектакльдә Тукай образын тудырган вакытларда бик тә борчылып йөргән Габдулла Шамуковка үзенең киңәшләрен биргән: «Тукайны мин беләм. «Тукай» куела дип ишеткәч, шагыйрь ролен, мөгаен, сиңа бирерләр, дип уйлаган идем, шулай булып чыккан да. Бик әйбәт. Ләкин син уйнарга тырышма. Сәхнәдә үзең булып, табигый килеш хәрәкәт итсәң, шул җитте. Гримны да җиңелчә генә салырсың, чөнки син болай да Тукайга охшыйсың», — дигән, Тукай турындагы кызыклы истәлекләре белән уртаклашкан, аның кайбер гадәтләрен, шаянлыгын, тәэсирләнүчәнлеген сөйләгән.

Әдәбият

Мәхмүтов Һ. «Сәйяр» труппасы //Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988. Б.71-,80-81, 97, 141, 158; Илялова И. «Нур»труппасы // шунда ук. Б.222, 223, 257; Шамуков Г. Тукай образын иҗат иткәндә // Чын мирас. 2014. №4. Б.109-110.

«МУСУЛЬМАНИН» («МӨСЕЛМАН»), 1908-1911 елларда Парижда рус телендә чыга башлаган «гыйльми, әдәби, икътисади» журнал. 1910 елгы 4 декабрьда С.Сүнчәләйгә язган хатында Т. аның татарчада чыгуына өметләнүен һәм анда Россия эчендә «басылмаслык резкий нәрсәләр»ен урнаштырырга теләвен әйтә. 1911 елның аңа ук язылган икенче бер хатында да «Ходай илһам бирсә, бик каты участвовать итмәкче бул»уын белдерә. Бу журнал турында «төрле сүзләр сөйләнгәнгә», Т. бу уеннан кире кайткан, «саклык күрсәткән» (Р.Гайнанов сүзе). Бераздан журналның мөселманнар арасында провокаторлык ролен башкару максатында патша хөкүмәте акчасына чыгарылганлыгы ачыла. Журнал татарча чыгып өлгермәгән.

З.Рәмиев ■

«ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН»

28 сентябрь, 1959 ел. Язучылар союзы каршындагы шагыйрьләр секциясендә Габделҗәббар Кандалый мирасын өйрәнү комиссиясе һәм галимнәр катнашында зур җыелыш була. Анда түбәндәге иптәшләр катнаша: Әхмәт Исхак, Хатип Госман, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Салих Баттал, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Гали Халит, Хәй Хисмәтуллин, Роберт Бикмөхәммәтов, Җәвад Алмаз, Якуб Агишев, Галимҗан Латыйп, Зыя Мансур, Ибраһим Нуруллин, Хисам Камалов, Шәйхи Маннур, Әхмәт Юныс, Шәрәф Мөдәррис. Көн тәртибендә: Габделҗәббар Кандалыйның яңа табылган кульъязмаларын тикшерү. Аның шигырьләре турында сөйләү өчен сүз Хатип Госманга бирелә.

Хатип Госман:

— Без Габделҗәббар Кандалыйның туган авылында булдык. Шунда бер каравылчы карт безгә Кандалыйның кулъязма шигырьләрен тапшырды. Мин аларны Кандалыйның билгеле шигырьләре белән чагыштырып карадым һәм стиль үзенчәлекләренең бер үк икәнен күрдем.

Хәй Хисмәтуллин Хатип Госманга сорау бирә:

— Кандалыйның стиленә каршы булган нәрсәләр сизелмиме? Сәхибҗамал белән Бәдыйга реаль кешеләрме?

Хатип Госман:

— Сәхибҗамал да, Бәдыйга да, Фәрхинур да — реаль кешеләр. Моны диплом яклаучы студентлар исбат итте. Беренче сорау дәлилле түгел. Кандалыйның рухына каршы килгән шигырьләр юк.

Салих Баттал сорау бирә:

— Кандалыйның ритмик үлчәүләре туры киләме?

Хатип Госман:

— Туры килә. Тик Кандалыйның шигырьләре бер үлчәмдә генә түгел.

Әмирхан Еники сорау бирә:

— Сез тапкан дәфтәрдә башка шагыйрьләрнең дә мөнәҗәтләре бар, дидегез. Бәлки Кандалыйныкы дип әйткән шигырьләр башка берәүнекедер? Кандалый стиленә ияреп язгандыр.

Хатип Госман:

— Башка шагыйрьләр бөтенләй аерылып тора. Кандалый стиле ярылып ята. Мин үзем бик камил ышанам.

Афзал Шамов сорау бирә:

— Кандалыйның нәселе бармы?

Хатип Госман:

— Бар. Аларда Кандалыйның китабы да булган, ләкин пожарда янган.

Шәйхи Маннур сорау бирә:

— Укылган шигырьләрдә ритмик,

Салих Баттал

Хатип Госман

Шәйхи Маннур

рифма бозылышлары сизмисезме? Аны бит шагыйрь булмаган кеше күчергән.

Хатип Госман:

— Бу фикер дөрес. Күчереп язучы орфографияне нык боза. Ритмик агышның бозылуы да мөмкин. Ләкин мин кулъязмага сак киләм. Кандалыйның каберен табып булмый. Җир инде тигезләнгән. Нәкый ага Исәнбәт тапкан шигырьләр дә бар *(укып күрсәтә).*

Гази Кашшаф сорау бирә:

— Публикация мәсьәләсе ничек?

Хатип Госман:

— Мин алып кайткан шигырьләргә Язучылар союзы идарәсе хуҗа. Минемчә, сүз башы белән «Совет әдәбияты»нда *(хәзерге «Казан утлары». — **Л.Л.**)* басылса яхшырак булыр. Радио аша чыгыш ясаганда тагын да әйбәтрәк булыр, дип уйлыйм.

Фикер алышулар башлана. Әүвәлге сүзне **Хәй Хисмәтуллин ала:**

— Сүз башында миңа ошамаган әйбер бар. Кандалыйга кадәр булган әдәбиятның бөтенесен дә дини мифология дип чыга. Һәрбер әсәр үзенең чоры белән бәйле. Мәүлә Колый, Утыз Имәниләр бар бит әле. Аларны бөтенләй юкка чыгарып ташлау дөрес түгел. Кандалыйны әдәбиятта борылыш тудырган шагыйрь дип алу дөрес булмас. Аның бит дини шигырьләре күп. Ситдыйк һәм Фәхретдин кебек шагыйрьләрнең 1836 елны ук дөньяви материалга нигезләнеп язылган шигырьләре бар. Кандалый турында язганда үткәнне себерсеп түкмәскә кирәк. Хатип Госман китергән дәлилләр генә бу кулъязманың Кандалый шигырьләре дип әйтергә мөмкинлек бирми. Чөнки бу шигырьләр Кандалый шигырьләреннән күпкә зәгыйфь. Аның иярченнәре шагыйрьләр булуы мөмкин. Кандалыйныкы икәнен тагын да ныграк тикшерергә кирәк булыр. Шуннан соң гына матбугатка чыгарырга кирәк. Аларны Кандалыйга нисбәтле шигырьләр дип кенә бастырырга кирәк хәзергә.

Гали Халит сөйли:

— Бу шигырьләрнең табылуы зур әһәмиятле факт. Табучы иптәш зур батырлык эшләгән. Кандалыйныкы булмаган шигырьләр дә булуы мөмкин, әмма болар тарихи әһәмиятле материаллар. Матбугатка чыгуына ышанабыз.

«Бу шигырьләр Габделҗәббар Кандалыйга иярep язылган шигырьләр», дигән тезисны мин яклыйм. Һәрхәлдә, бу язмаларны укучыларга бирергә кирәк. Сүз башы турында. Хатип Госман иптәш үзенчә яза. Кандалыйның шигъри осталыгына караган кызы-

клы тезислар бар. Хәй Хисмәтуллин фикере дөрес. Аны уйларга кирәк. Мәкаләдә бераз абстрактлык сизелә. Бу шигырьләрнең барысын да югары сәнгатьчә язылган, дип әйтү артык. Принципиаль әйтелсә, шик тудыра. Кандалыйга кадәр булган поэзияне мифологик, дини дип әйтү дөрес түгел. Кандалый поэзиясендә генә кеше образы килеп керә, дип әйтү шулай ук абстракт яңгырый. Кандалый һәм ислам мәсьәләсе куертыла, кара-каршы куела. Әдәби традицияләр үсеше ачык куелмый. Башка халыклар әдәбияты белән Кандалыйның бәйләнеше күрсәтелмәгән. Ә бу Кандалый иҗатында нык сизелә. Язучыларның иҗтимагый-тарихи җирлеген тикшергәндә чебеннән фил ясаулар сизелә. Кандалый поэзиясендә зур тарихи вакыйгаларның чагылышын мин күрмим. Ребус шикеллерәк җөмләләр бар. Минемчә, Кандалый — поэзияне халыкчанлыкка боручы новатор. Урыны-урыны белән көнчыгыш традициясенә, урыны белән халык поэзиясенә таяна.

Җәвад Алмаз:

— Экспедициядә йөргәндә Кандалыйныкына охшаган шигырьләр таптым. Чөнки ул имзасыз язган. Боларда күп куплетлар Кандалый шигырьләре белән туры килә. Мин тапкан шигырьләр белән Хатип Госман тапкан шигырьләр арасында зур охшашлык бар. *(Шигырьләрне укып күрсәтә.)* Безнең кулда өченче китап бар. Мин аны Кандалый шигырьләре, дим. Ләкин әле дәлилләр җитми. *(Кандалыйныкы булуы ихтимал булган «Вәгазьнамә» әсәрен укый.)* Кандалый әдәбиятта борылыш ясамады, дигән сүз белән килешеп булмый. Ул мәгълүм борылыш ясаган кеше.

Шәйхи Маннур:

— Мин сүз башын укымадым. Хәй Хисмәтуллин сүзләре дөрес булса, Кандалыйга кадәр булган әдәбиятны дини дип әйтү, әлбәттә, дөрес түгел. Кандалый үзе генә килеп чыкмаган, ул үзеннән алдагы әдәбиятны укыган. Форма ягыннан алымнары аңа элекке поэзиядән килгән. Ә образлары яңача, Кандалыйча. Кандалый белән безнең поэзиягә лирик герой килә, халыктан алынган сүзләр, материаллар килә. Менә шулар белән Кандалый борылыш ясый. Әгәр дә сүз башында Кандалый Пугачёв хәрәкәтләре белән бәйләнсә, әлбәттә, дөрес түгел. Кандалыйны табигый итеп укучыга аңлатырга кирәк. Кандалый шигырьләрен академик басма итеп чыгарырга кирәк. Әдәпсез дигәннәрен дә җыеп бастырырга кирәк. Җәвад Алмаз укыган соңгы «Вәгазьнамә»нең Кандалыйга һичбер бәйләнеше юк.

Якуб Агишев:

— Кандалыйны хәзер шагыйрь буларак халыкка чыгарырга вакыт җитте. Хатип Госман җыйган шигырьләрне хәзер үк туплап чыгарырга кирәк. Ләкин Кандалыйны укучыга бу шигырьләренә бәя бирү белән генә бирергә кирәкми. Кандалый — гаять каршылыклы кеше. Аны барлык каршылыклары белән бирергә кирәк. Кандалый — реализмга борылыш ясаучы новатор, ләкин аны халык хәрәкәте белән бәйләп бирү дөрес булмас. Кандалыйның периодизациясен табу гаять әһәмиятле. Бу шигырьләрдә бөтенләй дә Кандалыйга нисбәтле булмаган язмалар бар.

Афзал Шамов:

— Без исемсез язылган әйберләрнең барысын да бер авторга гына өеп куймыйбыз микән? Минемчә, Хатип Госманга шикләнебрәк тикшерергә, кайбер шигырьләрен Кандалыйныкы түгел, дип тә исбат итәргә кирәк булган. Минемчә, монда башка шагыйрьләр килеп кермәде микән? Аны аерырга кирәк. Башта иң ышанычлыракларын гына басып чыгарырга ккирәк. Кандалыйныкы булмаганнар да, минемчә бик күп. Мәсәлән, шәкертләр җыры. Бу шәкертләр чыгарган җыр булуы ихтимал. Әсәрләрен эзләүне дәвам итәргә кирәк. Моны гашыйклар гына

күчереп язган. Аларның иҗтимагый мөнәсәбәтләр булган шигырьләрне сызып ташлаулары бик мөмкин.

Роберт Бикмөхәммәтов:

— Минем бер тәкъдим бар: ни өчен безнең Казанда букинистик кибет юк? Шулай иткәндә күп кенә иске китапларны табарга мөмкин булыр иде.

Шәрәф Мөдәррис:

— Укылган шигырьләрнең күбесе Кандалыйныкы икәненә шигем юк. Аларны матбугатка чыгарырга кирәк. Мәрхүм Бәкер Яфаровның (?) гаиләсендә Кандалыйга караган материаллар юк микән? Художникларга Кандалыйның рәсемен тудырырга кирәк.

Гази Кашшаф:

— Кандалыйныкы икәне бәхәссез булганнарын хәзер үк «Совет әдәбияты»нда бастырырга кирәк. Сүз башын яңадан карап чыгарга кирәк. Шигырьләрне чагышытырп карап, сүз башында бирергәдер?!

Әхмәт Исхак:

— Кандалый шигырләре табылу — зур вакыйга. Без аның һәрбер юлын тикшерергә, ышанганчы тикшерергә тиешбез. Без аның сүзлеген, нечкә үзенчәлекләрен, телен беләбез. Кандалыйның бездә булганнарыннан чыгып, табылганнарын исбат итәргә кирәк. Кандалыйның җыентыгын 100 еллыгына чыгарырга, яңа табылганнарын да, исбат итеп, урнаштырырга кирәк. Кандалыйны русча да чыгарырга кирәк. Аны планнан сызганнар. Җыелыш исеменнән Таткнигоздатка әйтергә кирәк.

Хатип Госман сөйли:

— Иптәшләр, шигырьләрне конкрет күрсәтмәде, ягъни, бусы аныкы, бусы моныкы, дип иптәш Хисмәтуллин мин язмаган сүзләрне миңа сылтады. Мин алай димәдем. *(Өзекләр укый.)*

Беркетмә шушы урында тәмалана. Шул сәбәпле, беркетмәне кем язып барганы билгесез.

*Беркетмәне басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ГАБДЕЛҖӘББАР КАНДАЛЫЙ

Хатип Госман (1908-1992)

Габделҗәббарның яшьлек еллары турында мәгълүмат бездә бик аз. Халыкта сакланган истәлекләргә караганда, ул урта буйлы, җиңел сөякле, хәрәкәтчел, зәңгәр күзле, кара чәчле кеше булган. Ул үзенең зиһене, тапкырлыгы, сүзгә үткенлеге белән аерылып торган, туры сүзне кистереп, кыю әйткән, шуңар да үз тиңнәре арасында күпләр белән тыныша алмаган. Башта атасында укыган, соңрак Кизләү, Кышкар, Оры, Шентала мәдрәсәләрендә булган. Шагыйрьлеге мәдрәсәләрдә укыган чакта

[1] 1960 елда Татарстан китап нәшриятында Габделҗәббар Кандалыйның җыентыгы басылып чыга (186 бит). Җыентыкны төзүчеләр — Хатип Госман һәм Җәвад Алмаз. Игътибарыгызга, әдәбият белеменең бер ядкяре буларак, Хатип Госманның әлеге җыентыкка кереш сүз буларак язылган мәкаләсеннән кайбер сәхифәләрне тәкъдим итәбез.

башланган. Кышкар мәдрәсәсендә укыганда шул авыл мулласы турында ул «Мулла белән абыстай» бәетен язган. Бәет тиз арада телдән телгә күчкән, таралган. Мәдрәсә башлыклары, хафага калып, Габделҗәббарны бер көн үз каршыларына бастырганнар, үгетләгәннәр, тәүбә итәргә, язу-иҗат эшләреннән ваз кичәргә кушканнар. Ләкин Габделҗәббар тәүбә итмәгән, ваз кичмәгән. Шуннан соң аны мәдрәсәдән куганнар. Яшь шагыйрь мәдрәсәдән киткәндә үзенең кайнар хисле протест шигырьләрен язган.

Телләр өйрәнүгә һәвәслеге аркасында, ул рус, чуваш, мордва телләрен белгән, гарәпне һәм фарсыны өйрәнгән. Оры мәдрәсәсе хәзрәте, гарәпкә һәм фарсыга осталыгын күреп, Габделҗәббарны башкаларга укытучы иткән. Телләр белүе аркасында ул төрле халыкларның әдәбиятларын укый алган.

1824 елда ул Иртуган авылында муллалык урыны алган, Гөлстан исемле кызга өйләнгән, бер-бер артлы биш баласы туган. Соңрак аның өстенә Әбүбәкер Әхмәров исемле берәүне мулла итеп куйганнар. Җәнҗаллы бу вакыйга турында бер язма сакланган: «Мәзкүр мәсҗетдә имам булды Әбүбәкер Әхмәр угылы. 1841 елда июньнең 14 көнендә мөнбәргә чыкты, хотбә укыды». Габделҗәббар һәм аның яклылар, мәчетне ташлап чыкканнар: «Кире чыктылар: Мәннаф Ногман угылы, Хисаметдин Мохи угылы... карт мулла Габделҗәббар». Моңардан Габделҗәббарны үз күргән кешеләр булуы аңлашыла: алар, махсус мәхәллә аерып алып, 1843 елда аны шунда куйганнар. Бу хәлнең шагыйрь тормышына ничек тәэсир итүен әйтеп булмый, 1848-1849 еллар тирәсендә Кандалыйның башына зур кайгы төшә: аның иң сөекле улы Садретдин солдат хезмәтенә алына.

Шагыйрьнең тормышын күздән кичереп барганда, тагын бер факт игътибарны үзенә җәлеп итә: «Бән, Габделҗәббар ибне Габделмәҗит, Фәрхиҗамал исемле хатынымны 1851 елда 3 гыйнварда хәлг кыйлдым. Имза: Габделҗәббар ибне Габделмәҗит», — метрика дәфтәрендә әнә шулай диелгән. Сүз шагыйрьнең хатынын аеруы турында бара. Моның сәбәбе нәрсәдә икәне мәгълүм түгел. 54 яшьлек кеше үз гаиләсендәге мондый зур эшкә җиңел генә барыр, дип әйтүе кыен.

20 нче елларда шагыйрь турында материаллар җыю белән шөгыльләнгән И.Бәхтиев бер кызыклы мәгълүмат китерә. Кандалый «Сөбәтел-гаҗизин» исемле китапка гарәпчә аңлатмалар ясаган һәм кульязмасы ахырына: «Зур авырлыклар күрергә, ике ел буена төрмәләрдә утырырга туры килде, шул-вакыт менә шул китапны яздым», — дигән юлларны өстәп куйган. Бәхтиев, бу турыда патша администрациясенең берәр документы табылмасмы дип, Ульяновск шәһәренең архивында да тикшеренеп караган, ләкин нинди дә булса документ таба алмаган. Кандалый тормышындагы бу хәл кайчан, ни өчен булган? — Хәзергә бу сорауларга җавап юк. Киләчәк тикшерүчеләр моңар игътибар итәрләр, әлбәттә. Шигырь остасы булу өстенә, Габделҗәббар төрле һөнәрләр дә белгән: кирәк чагында сабын кайнаткан, мич чыгарган, йозак-ачкыч кебек нәрсәләрне төзәткән, китаплар төпләгән.

***

Шагыйрьнең үз кулы белән язган җыентыклары бөтенләй сакланмаган. Күчермә җыентыкларны тапкан кешеләр дә бу хәзинәгә саксыз караганнар, аны дәүләт карамагына тапшырмыйча, үз милекләрендә калдырып, югалтканнар. 1959 елның җәендә шагыйрьнең туган якларында безгә аның күчермә бер җыентыгын табарга мөмкин булды. Өлкән буын хәтерендә сакланган әсәрләр дә язып алынды. Шунысын әйтергә кирәк: шагыйрьнең төрле чыганаклардан алынган бер үк әсәрләре арасында котылгысыз аермалар очрый: кайчакта аермалар зур

да була. Болар, әлбәттә, әсәрләрнең җанлы хәрәкәт белән яшәүләрен күрсәтәләр.

Эзләнү дәвам итәргә тиеш, шагыйрьнең әле без белмәгән әсәрләре табылыр[2].

***

Аның иң күп язганы — кешенең матурлыгы. Кешенең матурлыгы дигәннән Кандалый иң элек, әлбәттә, хатын-кыз матурлыгын күздә тота. Ул сөйгәненең буен-сынын, битен-йөзен, кашын-күзен сокланып тасвирлый. Соң болар тышкы матурлык кына түгелме? Бу сорауга «Белә алмадым» шигырен күзәтү белән җавап бирик.

Килеп ирдем сәбәп берлә өеңә,
Күзем төште сәнең күркәм йөзеңә.
Күреп ирдем сәнең гөл йөзләреңне,
Ишеттем бал-шикәр дик сүзләреңне,
Дахи күрдем мөбарәк буйларыңны...
Белалмадым вә ләкин уйларыңны.

Шагыйрь кызның сылу буен, гөл йөзен күргән, сокланган, ләкин иң әһәмиятлесенә — кызның рухи дөньясы серләренә барып ирешә алмаган, — шунысы бик үкенечле булып калган. Кызның рухында, күңелендәниләр бар икән? — менә иң әһәмиятлесе, иң кыйммәтлесе. Кешене, сөйгәнен шагыйрь тышкы күренешеннән генә түгел, эчке, рухи дөньясы ягыннан да танырга тели, шуңар омтыла. Ни өчен? Чөнки ул үзе белән сөйгән кешесе арасында рухи тиңлек эзли. Аныңча, мәхәббәттә бәхетле булу өчен үз ратуың гына җитми, әле тагын яраткан кешеңнең сиңа карата да шундый ук уйда булуы кирәк. Шушы хәл аның әсәренә гуманистик җылылык һәм шигъри матурлык бирә дә.

***

Поэтик сөйләменә тормыш көче кертердәй барлык нәрсәләрне ул ала. «Сайлаган тазга тарый», «шикәр-бал татлы дип, бармакны йотып булмый», «табык төшенә тары керә», «егермесен унга саткан» кебекләр аның шигырьләрен бизәп бара. Алар өлгесендә шагыйрь үзеннән дә иҗат итә:

Гомер һәм чылтырап
суккан сәгать тик:
Бу форсатлар үтәр тиз,
йөгерек ат тик,
Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән.
Бу кадәрлү катып каның,
Ни хәлгә түзәдер җаның?

«Аягың астында туфрак булыйм», «бер күрергә тилмерәм», «газиз гомрең җилгә койма» кебек фразеологик күренешләр Кандалый әсәрләренең тукымасын тәшкил итәләр. Монда да шагыйрь халык өлгесендә яңа фразеологик әйләнмәләр иҗат итә. Мәсәлән, «Тәнеңдин яра китмәде, күзеңдин кара китмәде» кебекләр. Моннан башка шагыйрь халык иҗатыннан күп санлы традицион сурәт чараларын ала: «зифа буй», «нечкә бил», «йөзең гөл», «кызыл алмам», «каләм каш», «йөзе тулган ай», «күзе — Зөһрә йолдыз», «камыш каләм», «көмеш йөзек», «арсландай егет» һ. б. Болар Кандалый әсәрләренең интонация төсмерен дә баета.

***

Без шагыйрьнең соңгы гомере, ничек авыруы һәм нинди шартларда үлүе турында бернәрсә дә белмибез. Без аның 1860 елда — 63 яшендә үлгән булуын гына беләбез. Хәзерге көндә аның Иртуганда (Иске Кандалда) үлгән булуын да кистереп әйтүче юк. Ул, әлбәттә, шушында үлгән. Иртуган авылының зиратына керәсең. Каберстанда Габделҗәббарга куелган таш күренми! Алай гына да түгел, аның кабере тигезләнгән, хәзер бу кабернең урынын төбәп күрсәтә алучы да юк инде. ■

[2] 1988 елда Миркасыйм Госманов күләмле кереш мәкалә белән Габделҗәббар Кандалыйның шигырьләрен һәм поэмаларын аерым җыентык итеп әзерләп бастырып чыгара.

МИЛЛИ МУЗЕЙДА КҮН ЭШЛӘНМӘЛӘРЕ

Милли музейда «Төрки дөньясында күн эшкәртү һөнәрчелеге» дигән II халыкара фестиваль кысаларында «Төркиләрнең күн эшләнмәләре: сәнгать һәм йолалар» исемле күргәзмә оештырылды. Күргәзмәдә Россиянең төрле төбәкләре, Кыргызстан, Казахстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗаннан күн эшләнмәләре урын алган.

Карл Фукс XIX йөзнең беренче яртысында казан татарларын: «Татар хатын-кызлары келәмнәр җәелгән сәкеләргә урнаштылар, оста итеп бөкләп утырган аякларында алтын белән чигелгән ялтыравыклы читекләре күренеп тора иде», — дип тасвирлый.

Озак еллар дәвамында татар халкы читек тегү белән үз йортларында шөгыльләнгән. XIX йөз башында әлеге шөгыль оешкан кәсепкә әйләнә. Бу вакытта Казанда 34 күн заводы эшли. Танылган Казан сәхтияны кәҗә, сирәк кенә сарык һәм бозау тиреләрен үсемлек орнаменты белән каеп ясалган. Үзләренең югары сыйфаты, полихромик һәм композицион эшләнешләре нәтиҗәсендә Казан күн эшләнмәләре бөтен дөньяга танылган. Үзенчәлекле «казан» яки «татар» итек тегү техникасы мозаик орнамент детальләргә декоратив төс өстәгән.

Күргәзмәдә тиредән эшләнгән нинди генә ядкярләр юк: мендәр тышлары, панно-картиналар, ат иярләре, ук салу өчен садак-җайланмалар...

Кыргызстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, гамәли рәссам Ишенбек Чалановның сыер тиресеннән эшләнгән картиналары күпләрдә кызыксыну уятты. Останың эшләре Россия, Төркия, Бөекбритания, Япония, Кытай музейларында саклана.

Еракларга китәсе дә юк. Милли музей фондларында да күн эшләнмәләрнең гаять гүзәл үрнәкләре саклана. Лалә, лилия чәчәкләре, йөрәкләр, мөгезләр, спираль орнаментлар белән эшләнгән хатын-кыз туфлиләре, читекләр — музейдагы этнография бүлегенең бай мирасы.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.*

МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ МУЗЕЕНДА РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН МИРАСЫ

Чулпан Мөслихова

«Казан» милли мәдәният үзәгендәге Милли мәдәният музее фондында күренекле галим, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең коллекциясе саклана.

Кызы Әсма Шәрәфнең гаилә архивында кадерләп сакланган әйберләрне 1992 елның 25 ноябрендә галимнең оныгы Арслан Шәрәф музеебызга тапшырган.

Р.Фәхреддиннең үзе исән чакта ***Уфада, Нәманганда, Мәккәдә төшкән*** фотосурәтләре, алар артына үз кулы белән язган истәлекле язулар бүген кыйммәтле тарихи чыганак булып тора. Хәләл җефете Нурҗамал Габденнасыйр кызы Төхфәтуллина-Фәхреддинова, уллары, кызлары белән төшкән фотосурәтләр гаилә җылысын киләчәк буыннарга тапшыра кебек. Р.Фәхреддиннең үзе исән вакытында ук басылып чыккан энциклопедик характердагы ***«Мәшһүр хатыннар»***, ***«Гаилә» кебек китаплары,*** ул күп еллар мөхәррир булып эшләгән ***«Шура» журналының кайбер нөсхәләре*** галим иҗаты, тормыш юлы белән кызыксынучылар өчен мөһим чыганак булып тора.

«Татар мәгърифәтче галименең эш кабинеты» экспозициясендә Р.Фәхреддиннең ***өстәл сәгате, язу әсбаплары*** һәм гаиләсенең иң кыйммәтле ядкяре — ***дисбесе*** — әле дә хуҗаларының кул җылысын саклыйдыр кебек. XX гасыр башына караган ***өстәл сәгате*** циферблатында саннар гарәп цифрлары белән күрсәтелгән. Галимнең ***каләме*** кара төстәге металл эретмәсеннән эшләнгән. Нигезгә дүрт ягында ярымшар рәвешендәге аяклы аслык, аңа ромб формасындагы капкачлы ике пыяла ***кара савыты*** урнаштырылган. Алар янында Р.Фәхреддиннең язу киптергеч җайланмасы да урын алган.

Икенче бер экспозициядә галимнең куе коңгырт төстәге ***күннән эшләнгән бумажнигы, кесә сәгате*** куелган. ***Кесә сәгате*** Швейцариянең «Майзер» фирмасында көмештән эшләнгән. Циферблатның артында чокып түбәндәге сүзләр язылган: «1925 сәна мөфти Ризаэддин хәзрәткә хатирә: Таһир Госманов» (Мәскәү бүләге).

Коллекциядә урын алган истәлекле әйберләрнең берсе — галимнең ***шәҗәрәсе, нәсел агачы.*** Әле үзе исән чагында ук Р.Фәхреддин үз нәсел шәҗәрәсен төзи башлый. Оныгы Арслан Шәрәф бабасының традицияләрен дәвам итеп, шәҗәрәне тулыландырып калдыра.

Нурҗамал абыстайның күлмәге һәм ак ефәк шәле музей экспозицияләрендә үз урынын тапты. Күлмәк сыек алсу төстәге йон тукымадан тегелгән. Әлеге күлмәкнең тукымасын Р.Фәхреддин 1926 елда Мәккәгә конгресска баргач, хатынына бүләк итеп алып кайта. Зәйнәп Фәхреддинованың ак киндер тукыманың ике башы ***кызыл тамбур җеп белән чигелгән сөлгесе*** дә музей экспозициясендә урын алган. Фондларда исә ***Зәйнәп Фәхреддинованың фотоальбомы*** белән дә танышырга була. Альбом Зәйнәпнең 1929 елда Казан дәүләт университетының медицина факультетын тәмамлауга багышланган.

Коллекциядәге шкатулка, савыт-сабалар да Фәхреддиннәр гаиләсенең кадерле ядкяре. ■

КЫШТЫМ АФӘТЕ

Александр Филиппов

Без бишенче катта күңел ачып утыра идек. Урамда тынлы оркестр кинәт кенә йөрәкне актара торган моңлы көй уйнап җибәрде. Барыбыз да тынлы оркестр тавышына сискәнеп киттек. Сикерешеп торып, ачык тәрәзәгә ябырылдык. Шәһәр мәдәният йорты янында офицерлар белән гражданскилар бер сафка тезелеп баскан. Безнең командирлар да — шулар арасында. Ишектән кызыл комачка төрелгән табут алып чыктылар. Бу безнең төзүче дусларның Кыштымнан ук таныш булган бер полковник икән. Аны олылап соңгы юлга озаталар иде.

— Аңа бит, моннан китеп, башка җирдә дә дәваланырга була иде, үзе теләмәде. Солдатларның рухын күтәрәм дип, күбрәк доза алган ул… — Моны бу яктагы вакыйгаларның шаһиты әйтә.

— Доза? Нинди доза? Нәрсә дозасы?.. — Бу сорауны без бирәбез.

— Ә-ә-ә… Сезнең бит Кыштым фаҗигасе турында ишеткәнегез юк… — Алар ни өчендер, безнең берни дә белмәвебездән гаҗәпсенәләр.

— Әйе, анда тау куышындагы графит-каолин комбинаты шартлаган, дигәннәр иде. — Тагын берсе шундый ачыклык кертә.

— Графит шартлый димени, булмаганны, каолин дигәне ак балчык инде, ул ничек шартласын? Шахта ишелеп төшкән булса гына инде? — Монысы химия һәм физикадан азмы-күпме хәбәрдар икәнлегебезне күрсәтергә тырышу иде.

— Безне дә шундый язмыш көтә торгандыр, шәт. Ул көнне җир тетрәгәндә безнең бригада Кыштымда мәктәп җиткерүдә эшли иде. Бөтен дөньяны кара сөрем басты, нәрсә булганын да белми калдык. Ә без монда акча артыннан куабыз. — Аннары ул колакка ук иелеп сүзен пышылдау тонына күчерде. — Халык артык нурланыш алудан кырыла, өченче ел Кыштымда атом бомбасы заводы шартлады. Аннан әле дә радиация таралып ята, монда да бар ул. Ул тирәдәге халыкны хәзер без төзегән йортларга күчерәләр… — Бу хәбәр безнең өчен коточкыч яңалык иде. Аннары ул башлаган сүзен төйнәп куйды. — Сез күптән түгел ант биргән солдат, безгә дә бер кәгазьгә кул куйдырдылар. Мин сөйләгән сүзләр шушы диварлар эчендә югалып калырга тиеш. Нинди урынга килеп кабуыгызны белеп тору өчен генә әйтүем…

Ахыры. Башы журналның 10 нчы санында.

**Солдат чаклар.
1960 ел**

Биредә адым саен Эчке гаскәрләрнең кызыл погонлы патрульләре очрап торуы очраклы түгел икән. Урамда яшел яки кара погонлы солдатны күрсә — кара погон безнең парад формасы — шунда ук килеп бәйләнә: нишләп йөрисең син, кая барасың, кем белән очрашасың, исем-фамилияңне язып ала, шикләнерлек сәбәп тапса, шунда ук комендатурага илтеп тапшыра да полктан синең турыда белешмә алганчыга кадәр гауптвахтага утыртып куя. Шулай булгач, үзең эшли торган объекттан аз гына читкә чыктыңмы, син шунда ук ау ятьмәсенә эләгәсең. Бу әле эт тә үтеп керә алмаслык чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган шәһәрдә шулай. Саф белән эшкә барганда да сине шәһәргә санап кертәләр, кайтканда тагын санап чыгаралар. Без моны баштарак төзүче солдатлар арасында тәртип саклау өчен эшләнә торган гамәлдер, дип уйлаган идем. Баксаң, ул дәүләтнең үтә яшерен серен саклау галәмәте булган икән.

Безнең взвод командиры өлкән лейтенант шулай ук «Маяк» ветераны булып чыкты. Бу турыда ул безгә, әлбәттә, берни дә сөйләмәде, сиздермәде. Һаман да шул күп белүче төзүчеләр җиткереп тора. Алар электән монда хезмәт иткән офицерларның күбесен күреп-танып беләләр иде. Алар бер-берсе белән мондагы хәлләр турында ачыктан-ачык сөйләшәләр иде. Өлкән лейтенант атом заводы шартлыйсы елның язында туй ясап, туган ягының бер чибәрен шушы якларга алып килгән. Солдат хәленә керә белүче әйбәт командир иде ул. Бервакытта да безне юкка-барга чираттан тыш наряд белән кудыртмады, башкалардан рәнҗеттермәде. Яше белән дә ул бездән әллә ни күпкә аерылып тормый иде шул. «Маяк»тан килүчеләрнең күбесе шундый сабыр холыклы, солдатларга акырмый-бакырмый торган офицерлар иде. Әмма инде моңа кадәр яшәгән бөтен тормышлары атом тузаны астында калып күмелгән булса да (хәтта искә алуы да тыелган үткән көннәр турында башкача әйтеп тә булмый), алар чиктән тыш ватанпәрвәрләр иде. Бу болганчык, салкын сугыш чорында, бигрәк тә 1956-1957 елларда, Америка Кушма Штатлары Советлар Союзының 70 шәһәрен атом уты белән көйдерергә ниятләгән бер мәлдә, илне бу бәладән «Маяк»та эшләнгән атом бомбасын сынау һәм 1957 елда Галәм киңлекләрендә Җир тирәли әйләнү, шул ук чорда безнең ракетаның очыштагы баллистик ракетаны бәреп төшерүе һәм башка шундый

чаралар коткарып кала. Бу турыда рота замполиты сәясәт сәгатьләрендә еш телгә алырга ярата иде. Алар дөньякүләм атом афәтен булдырмый калуда үзләренең дә өлешләре керүгә горурланалар. Сөйләү рәвешләреннән үк бернәрсә ачык сизелеп тора иде: үзеңнең тормышыңны куркыныч астына куеп булса да илең иминлеген сакла! Девиз шундый катгый. Әмма соңыннан илне таркату өчен атом бомбасының кирәге чыкмады…

Взводный ни өчендер мине якын итеп йөри иде. Бервакыт ул миннән:

— Мич чыгара беләсеңме? — дип сорады.

— Авылда мич чыгаручыны карап торганым, аңа булышканым бар, — дидем.

— Алайса мин сине иртәгә Каслига алып барам, мич төтәсли, карап алырсың әле…

Имеш, шартлау вакытында «Маяк» зонасында булган кешеләр бала табарга сәләтсез булып калган икән, шуңа күрә донор вазифасын чиста зонадан килгән солдатлар үти икән.

Икенче көнне полк штабыннан увольнительныйны ул миңа үзе алып кайтып бирде. Иртәнге аштан соң без Каслига киттек. Егерме мең чамасы кеше яши торган яшеллеккә күмелеп утырган җыйнак кына шәһәрчек иде ул. Командир ике фатирлы йортның бер башында тора иде. Безне аның хатыны каршылады. Балалары юк икән, икәү генә торалар. Мөгаен, булмас та. Гаҗәп бер ачыш ясагандай сөйләнгәннәрен ишеткәнем булды. Имеш, шартлау вакытында «Маяк» зонасында булган кешеләр бала табарга сәләтсез булып калган икән, шуңа күрә донор вазифасын чиста зонадан килгән солдатлар үти икән. Менә сиңа, мә! Мин моңа ышанмадым. Ә кая мәхәббәт? Бозыклык ич бу! Ә бәлки мондый кырын эшләр ихтыяҗи гаҗизлектән, тулы канлы тормыштан нәүмиз булып калудан килеп чыга торгандыр…

Беренче эш итеп, галанка тибында чыгарылган мич буйлап күз йөгертеп алдым. Мич авызы корымланып тора иде. Шактый эш күренә монда. Шулай да мин ризалаштым. (Ә кая барасың!) Өлкән лейтенант без килгән машинага утырып китеп барды. Без бер өйдә аның хатыны белән икәүдән-икәү калдык. Мин ул биргән чиләк белән кызыл балчык, аннары урамдагы колонкадан су алып кердем. Шул арада йорт хуҗасы марҗа түти табын әзерләде. Аннары саф татар телендә:

— Мин эшкә ашыгам, өстәлдәге ризыклар сезнең өчен, тартынып тормагыз, — димәсенме!

Өнсез калдым. Нинди җавап кайтарырга да аптырадым. Бәй, мин үземнең карендәшләремдә кунакта икән бит! Шушы тирәләрдән бик үк ерак булмаган Чибәркүл районындагы нагайбәкләр яши торган бер авылдан икән үзе.

Ә мич чыннан да төтенне суырмый иде. Аны тиз генә сүтеп ташладым. Төтен юлы тышкы морҗа өстеннән ватылып төшкән кирпеч белән томаланган икән. Аны алып ташлап, кирпечләрен яңадан өеп, ике урынлы чуен плитәсен урнаштырып, сылап һәм тигезләп, учакны үрләтеп җибәрдем. Морҗа төтенне генә түгел, ялкынны да гөжләтеп суыра! Чәй кайнатып алдым…

Гражданкада эшче-механизатор һөнәре алырга өлгермәгән солдатларны бөке урынына, кая кирәк, шунда илтеп тыгалар иде. Сумала да кайнатасың. Аның тәнгә, киемгә утырган сөремен юып та бетереп булмый. Җир казучы да буласың. Яңа шәһәр булгач, аның җир асты коммуникацияләрен дә план буенча алдан әзерләп куярга кирәк инде. Урал тауларында җирне көрәк белән түгел, эксковатор белән дә казып булмый. Бердәнбер юл — траншея буласы урынны шартлатып чыгу. Менә монысы чыннан да сапёр хезмәтенә якын инде. Шартлату ул әле

траншея әзер булды, дигән сүз түгел. Андый чакта солдат кулына кәйлә тоттыралар. Урал тавы чакматаш кебек, китереп бәргән саен көлтә-көлтә очкын чәчри дә, бармак башы кадәр таш кителеп оча. Ташның катлам-катлам булып яткан урыннарын казуы ансатрак, кәйләңнең очлы башы белән ташны сугып чатнатасың да, яссы ягы белән ярылган урынына кертеп, каерып кына ташлыйсың. Әмма шәһәр эчендә, йорт яннарында җирне шартлатып казып булмый. Шуңа күрә бөтен эшне кәйлә тоткан солдат башкара. Көн буена кәйлә белән кизәнерлек аралыкта үзең күмелерлек җир казысаң, кичкә таба күз алдыңда аллы-гөлле утлар уйнап тора башлый. Касли-2 шәһәре (хәзерге исемен белмим, әмма анда шартлау булган Озёрск шәһәреннән дә күп гаиләләрне күчерделәр) безгә шул ягы белән нык истә калды. Аның ташларына минем кебек солдатларның маңгай тирләре, каннары... һәм күз яшьләре сеңеп калган. Әйе, каннары, дидем. Кәйлә белән кизәнеп бәргәндә күпләребезнең авыз-борыннарыннан кан бәреп чыга иде. Әйе, күз яше, дидем. Бер минутка кәйлә сабына таянып ялга туктаган арада, маңгай тирен сөрткән булып, бер уңайдан күз яшен дә сыпырып төшерүчеләрне күрергә дә туры килде. Хәле китеп авучылар да булды. Температураң күтәрелмәгән булса, санчасть сиңа ял да, дару да биреп тормый. Сине әле симулянтлыкта гаепләргә дә мөмкиннәр...

«Түбәсе китүче»ләрне күрергә дә туры килде. Кемнедер койма ярыгыннан урманга чыгып асылынырга ботак эзләп йөргән җиреннән тотып алганнар. Кемнедер «комиссовать» итеп, өенә кайтарып җибәрделәр. Полк буенча андый хәлләр булгалап тора иде. Берсен шулай урман эчендә утырган бистәдәге тилеләр хастаханәсенә озатып куйдык. Теге солдатка кая баруыбызны әйтмәскә куштылар. Әгәр сораса, өйгә кайтабыз, диярга. Поездга утырганда безнең кулга бер капчык тоттырдылар. Капчыкта бау иде. Тузына башласа, җәнҗал чыгарса, бәйләп кую өчен. Ул чыннан да безне өенә озатып куючылар, дип белә иде. Тыныч кына утырып барды. Беребез аның каршында, икенчебез янында утыра. Купеда тагын бер-ике кеше бар. Бер-ике тапкыр табигый хаҗәте белән бәдрәфкә барып килде. Көн урталарында өч кешегә бирелгән корды-сарды ризыкларны чыгарып, тамак ялгап алдык. Солдатның билгесезлеккә төбәлгән күзләре кинәт кенә купе сәкесендә яткан капчыкка төште. Бер сүз эндәшми барган солдатның теле ачылды:

— Ә бу капчыкта ни бар? — дип сорап куйды ул.

Анда синең эшең булмасын, дип, җавап кайтармасаң да була иде. Әмма ни өчендер:

— Бер альпинистка тапшырасы бар аны, командир биреп җибәрде, — дип алдаштык.

— Ә мин беләм, — диде бу. — Курыкмагыз, минем беркая да качарга җыенганым юк...

Урманда километр исәбе белән генә белдерелгән бер тимер юл разъездында төшеп калдык. Беренче кар төшкән вакыт иде бу. Үз хуҗалыклары белән яши торган урман бистәсенә охшаган. Терлек сарайларының төз түбәсенә сыртлап печән өеп куйганнар. Сыер мөгрәгән, сарыклар бәәлдәгән тавышлар ишетелеп тора. Морҗадан чыккан төтен, туп-туры күтәрелә дә, һавада таралып юкка чыга. Борынга әчкелтем тәмле чәер исе килеп бәрелә.

— Бу безнең авыл түгел, — диде юлдашыбыз. — Безнең якта каен, имән утыны ягалар, төтеннәре күзгә керә...

Яңадан да капчыкка ымлап:

— Әле кайтып җитмәдек шул, менә бу әйберне тапшырабыз да, аннары Чиләбегә утырып китәбез, — дип алдашырга туры килде.

Урамга кадәр формалин исе чыккан бер баракның ишек төбенә килеп туктыйбыз. Хезмәттәшебез алтакта язуын безгә кадәр үк укып өлгергән дә:

— Мине нигә монда алып килдегез? — дип, өзгәләнә-бәргәләнә башлады.

— Дәваланырга, агайне, дәваланырга... Менә берәр ай ял итәрсең дә, безнең янга яңадан әйләнеп кайтырсың әле, Алла боерса... — дип юатырга тырыштык без аны үзебезчә.

Бу вакыйгадан соң бер-ике ай чамасы вакыт узганнан соң, солдат хезмәтендәге беренче Чыршы бәйрәмен уздырып йокларга яткач, озак та үтмәде, тревога командасы яңгырады. Кышкы формадан киенеп, барлык әйберләрең тутырылган биштәреңне асып, урамга чыгып басарга, дигән команда булды. Һәрбер отделение командиры үз солдатларын исемлекне укып тикшерде. Алар — взводныйга, взвод командиры — ротныйга, алар исә үз чиратларында соңгы дистанция буенча полк командирына рапорт биргәч, «рас-тва»га бастырып, полк капкасыннан ук алып чыгып киттеләр. Безне урман эченә үк кертеп эшләнгән тимер юл тупигына китереп куелган мал вагоннарыннан торган состав янына алып килеп туктаттылар. Пассажирлар өчен тәгаенләнгән беренче вагонда полк штабы урнашты, калганнарына безне кертеп тутырдылар. Хуҗалык ротасындагы танышлар күренмәде. Димәк, алар полкка яңа көчләр кабул итәргә калганнар. Ә без, Уралның организмга тәп-төгәл бер елда җыйнаган уран нуклидларын төяп, Себергә — Красноярск якларына китеп барабыз. Бу — безнең иң зур «байлыгыбыз». Без ул вакытта әле бу турыда уйлый белми идек...

Бу сәфәр — үзе бер тарих. Поезд безне унбиш көн буе өстерәде. Без казах далаларын узганда һава температурасы минус 40-50 градуска җитте. Мондый салкында һава басымы буржуйка төтенен тышка түгел, ә вагон эченә чыгара. Вагон ишеген ачып куярга туры килә. Шунда барганда аяк-кулы өшемәгән кеше калмагандыр. Хәтта кухня-вагонда ашка дип төягән бәрәңге һәм яшелчәләр өшеп, полк ризыксыз калды. Монысы әле — юл нужасы. Андый чакта запаска дип алган солдат коры-сарысы белән дә тукланасың. Шунысы мөһим, безне атом афәтеннән ераккарак алып киттеләр. Безнең урынга башкалар килде. Яңа урынга килеп җиткән көнне үлеп йоклаганбыз. Казарма, күрәсең, салкын булгандыр, иртән торганда юеш чәчләребез мендәргә ябышып каткан иде. Полк казармаларын тимерчыбыклар белән уратып алынган койма артындагы паровоз пары белән җылыталар иде. Без килгән көнне ул ни өчендер эшләмәде. Без монда да буш казармаларга килеп кердек. Элек биредә ирекләреннән мәхрүм ителгәннәр өчен ябык зона булганга охшап тора. Алай дисәң, казармалар урнашу тәртибе нәкъ Касли-2дәге кебек. Шулай да, Урал белән чагыштырганда, без монда иркенгә чыктык. Тиз агымлы Кан елгасы буенда ике елга якын ул чорның удар төзелеше дип игълан ителгән КАТЭК (Канск-Ачинск җылылык-электр комплексы) системасына керә торган Канск ТЭЦын төзүдә бетончы-балта остасы булып эшләргә туры килде. Без монда Уралдан алып килгән изотоплардан азмы-күпме арынганбыздыр, дип уйлыйм. Уралда күлләр илендә торсак та, су күрә алмаган идек. Ә монда тәмәке тартырга туктаган арада да су коенып алырга була. Урман үзебезнеке — кедр чикләвеге җыеп кайтабыз, туйганчы мүк җиләге ашыйбыз, шимбә-якшәмбе көннәрендә тиз агымлы Кан ярының биек тауларына үрмәлибез... Ашарга барыр вакыт җиткәч, ротага кайтып җитәргә генә кирәк. Соңга калсаң, чираттан тыш нарядтан башың чыкмый. Безне монда күбрәк карабодай боткасы белән сыйлыйлар иде. Монысының да үз тәртибе булган, ул организмнан радионуклидларны куып чыгарырга сәләтле ризык икән. Тайга уртасында юлсыз-нисез җирдә берничә йортлы гына таза тормышлы авыллар да очраштыргалап куя. Имеш, алар кайчандыр туган җирләреннән сөрелгән

кулаклар булганнар. Безгә җирле халык белән аралашырга кушылмаганлыктан, аларны читләтеп уза идек…

Мин язмамда берәүнең дә исем-фамилиясен атап әйтмәдем. Аннан соң күбесенеке онытылган да инде. Ни дисәң дә ярты гасырдан артык вакыт узган бит. Тик шунысы кызганыч, Чиләбе атом заводы шартлавы нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы солдатларның хезмәте хәрби тарихчылар тарафыннан беркайда да язып калдырылмаган. Әйтерсең лә алар бөтенләй булмаган. Мин Фәүзия Бәйрәмованың «Караболак» романын укыганнан соң, Александр Колесникның инженерлык гаскәрләре маршалы Н.Ф.Шестопалов редакциясендә чыгарылган «Советские военные строители» (М.: Воениздат, 1988) дигән китабын карап чыктым. Анда 1552 елда Казанны камап алу эшләрендә җитәкчелек итүдә һәм Зөя шәһәрен төзүдә катнашкан Иван Выродковтан алып, космодром төзүчеләргә, Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан хәрби төзүчеләргә кадәр шактый мәгълүмат бирелгән. (Авторга рәхмәт, ул китабының бер бүлеген хәрби төзүче, генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое, милләттәшебез Дмитрий Михайлович Карбышевка багышлаган). Әмма Чернобыль АЭСы һәлакәтенә караганда бик күпкә көчлерәк булган Кыштым афәте нәтиҗәләрен бетерү өчен тырышучы хәрби төзүчеләр турында ләм-мим бер сүз дә юк. Бөтен дөньяга инде әллә кайчан билгеле булган һәлакәт турында һаман да сер саклап утыру кемгә кирәк икән ул?

Язучы Фәүзия Бәйрәмова үзенең «Караболак» романы белән тарихтагы бу бушлыкны — ак тапны япты. Ул бу әсәрендә радиоактив пычрак матдәләр



Александр Филиппов. 2000 ел

«Түбәсе китүче»ләрне күрергә дә туры килде. Кемнедер койма ярыгыннан урманга чыгып асылынырга ботак эзләп йөргән җиреннән тотып алганнар. Кемнедер «комиссовать» итеп, өенә кайтарып җибәрделәр. Полк буенча андый хәлләр булгалап тора иде.

агып ятучы Караболак һәм Тичә елгалары буенда утырган Татар Караболагы, Мөслим һәм башка татар авылларында, атом заводына хезмәт күрсәтүче шәһәрләрдә яшәүчеләрнең фаҗигале язмышын оста сурәтли. Әсәрдә тормыш өчен көчле көрәш бара: яшиләр, гаилә коралар, бала табалар… Әмма атом җене берәүне дә аямый. Зур-зур татар авыллары бушый, алар янында зиратлар үсеп чыга. Җирдә олы фаҗигагә тарыган кешенең иң соңгы өмете — теге дөньялыкта оҗмахка элэгүдә… ■

МӨСЛИМ ТӨБӘГЕ

Илгиз Зәкиҗан улы Исламов. Мөслимнең уңган-булган егете. «Агромастер» җитештерү берләшмәсенең генераль директоры. Безнең, ягъни «Безнең мирас» журналының якын дусты.

Илгиз Зәкиҗан улының төп эшеннән башка тагын бер шөгыле бар. Ул — бик шәп фотограф. Илгиз Исламов төшергән фотосурәтләр аша Мөслим төбәгенең иң гүзәл табигате — матурдан матур күренешләре белән танышырга мөмкин.

Ләбиб Лерон

АСЫЛЗАТ

Илгиз Зәкиҗан улы Исламовка

Күңелендә изгелекләр ятса,
Игелекләр кылыр ир-егет.
Сынауларны кичәр егетләрчә —
Саклап калыр һәрчак хөрлеген.

Эш кадерен, үз кадерен белсә,
Ил кадерләр аны — җир улын;
Тарихларга, дастаннарга керер
Бер фидакарь асыл ир булып!

Хезмәтеңә хөрмәт — Ил таныса
Һәм куанса эшчән нәселең.
Күңелеңә хуш килердәй икән —
Данга илтер һөнәр-кәсебең.

Дөньяларга чыксаң — гыйбрәт ал син,
Илләр гизсәң — фәһем алып кайт.
Эш кешесе хыялый да була:
Бер җай чыкса — Айга барып кайт.

Чит илләрдә булган чакларыңда
Туган якны тоеп ятасың.
Фаразлыйсың: иртәгәсен, бүген
Таңнар бездә ничек атасын.

Мөслим — синең җаннарыңа сеңгән,
Каннарыңа сеңгән һәр төше...
Сискәндерә кышкы яңгырлары,
Хисләндерә җаен кар төшеп.

Юк вакытны табып, Мөслимкәйнең
Урман-болыннарын барлыйсың:
Һәрбер кошын, һәрбер күбәләген
Таныйсың күк — телен аңлыйсың.

Гүзәллекнең серле күренешен,
Матурлыкның моңлы мизгелен
Сурәтләргә алып, күчерәсең
Хәтереңә... Һәм бу — Изгелек!

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АЧЛЫК *тар.* — Мөхәммәд Пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре Мәккәдән Мәдинә шәһәренә күчеп китәргә мәҗбүр булганнан соң, Пәйгамбәр Мәккә халкын ачлык көтүе турында кисәтә. Ачлык еллар борынгы Мисырга да мәгълүм булган. «Йосыф» сүрәсендә Мисырда *кызликъ* (ачлык, кытлык) еллар турында да сөйләнә.

Иҗтимагый афәт буларак, ачлыкны ике төргә бүлеп карыйлар: беренчесе — *абсолют ачлык,* ә икенчесе — *чагыштырма ачлык.* Соңгысы вакытында туклану рационында тереклек өчен кирәкле мөһим компонентлар җитми. «Политик-экономик терминнар» сүзлегендә (1941) *«голодная заработная плата»* — ачыгырлык дәрәҗәдәге эш хакы, *«голодный минимум»* — ачлык минимумы кебек сүзләр теркәлгән.

Халык телендә ачлыкны бүре *сырхавы* дип тә атаганнар. Ачлык мәгънәсендә *йот* сүзе дә бар (*«далага дәһшәтле йот килде»*). Әдәбиятта, русчадан күчереп, *ачлык-патша* дигән гыйбарә йөргән. Ачлык елны *алабута* елы дигәннәр.

Тарихи чыганакларда ачлык турында хәбәрләр шактый еш очрый. 1024 елда Суздальдә ачлык булган һәм руслар Болгардан бик күп ашлык алып торган. 1228-1229 елларда Бөтен Русьта, бигрәк тә Новгород һәм Белозёрскийда, ике елга сузылган көчле кытлык була, шул вакытта болгарлар Идел һәм Ука сулары буенча русларга кәрван-кәрван ашлык озаталар, ә болгар ханы Новгород кенәзенә утыз көймә икмәкне бүләк итеп җибәрә (Габдрахман Таһирҗанов буенча). Рәүф Сабиров (1894-1937, репрессия корбаны) Русиядәге 1231 елгы ачлык турында: «Шушы ачлык елларның соңгысында халык гаять тә күп үлгән һәм Германиядән икмәк китерү аркасында гына халык бөтенләй үлеп бетүдән котылып калган», — дип яза.

1872 елда Самарада гадәттән тыш каты ачлык булуы мәгълүм. 1877 елда Россиядә иген уңмый һәм илдә ачлык башлана. 1883 һәм 1891 елларда шушы ук хәл кабатланган (1891 елның 14 ноябрендә Казанда мөселман балалары бушлай туклана торган ашханә ачыла). 1901 елда да игеннәр уңмый. 1906-1907 елларда Россиянең Европа өлешендә, шул җөмләдән Казан губернасында да ачлык хөкем сөргән. «Ач үлемнән куркусыннан ил җылый!» — дип Тукай юкка гына язмаган. 1911 ел да Россия өчен чагыштырма ачлык елы, ләкин ул Россиянең 195 миллион халкы булган 20 губернасын чолгап ала.

Дөнья күләмендә җир-суларга иң бай дәүләт булган Русиянең шушылай бик еш ачлыктан интегүенең ил-халык

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санында басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

психологиясендәге әчкәреге, ихтимал, генетик сәбәпләре дә бардыр. 1920 ел ук инде Татарстан өчен чагыштырма ачлык елы булган, дип әйтергә мөмкин. Идел буенда 3 миллион кеше гомерен алып киткән 1921-1923 елгы ачлык, 1933-1934 елда Саратов өлкәсе һәм Краснодар крае халкын 10%ка киметкән ачлык, шулай ук 30 нчы еллар башында Украинадагы ачлык, 1947 елгы ачлык большевикларның эчке икътисади сәясәтенә турыдан-туры бәйләнгән.

1922 елда Р.Сабиров (ул вакытта ТАССРның Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы рәисе): «Татарстан Җөмһүриятенең төп халкы булган татарлар, шул ук Татарстанда тереклек итә торган башка халыкларга караганда, ныгырак ачыгалар», — дип язган иде.

Ватандашлар сугышы елларында (20 нче еллар башы) Башкортстанда рәсми рәвештә генә дә 2000нән артык каннибализм (кеше ашау) очрагы теркәлгән.

Кул астындагы мәгълүматларга караганда, ачлык елларында Башкортстан Республикасы һәм Уфа губернасы халкы 650 мең кешегә кимегән (22%ка). Шул исәптән башкортларның һәм татарларның саны 29%ка, ә урыслар санының 16%ка кимүе билгеле. Чуаш һәм мари халкы саны 10%ка кимегәндә, русларның саны 4%ка кимүе билгеле. Бу нисбәт, күрәсең, хәзерге Татарстан территориясе өчен дә дөрес булыр. Тулаем алганда, бу ачлык вакытында Татарстанда ярты миллионнан артык (тарихчы Индүс Таһиров 400 мең санын китерә) кеше ачтан үлә, ә бөтен төбәктә үлүчеләр саны 6 миллионга җиткән.

Идел буенда 1921-1923 елгы абсолют ачлык вакытында берничә халыкара ярдәм оешмасы төзелә. Аеруча билгеле булганнары — Англия һәм Америка дуслары дигән оешмалар. Идел буенда хөкем сөргән ачлык тырнагыннан мөселманнарны йолып калу өчен, бөтендөнья мөселманнары җибәргән ярдәмне туплау максаты белән мөфти хәзрәтләре Галимҗан Баруди һәм казый Кәшшаф Тәрҗемани Мәскәүдә хакимиятләр белән сөйләшүләр алып барган. Мөселманнар өчен 320 миллиард сумлык ярдәм җыйнала.

Бу ачлык вакытында Россиядә эшләгән квакерлар арасында Майкл Эскит дигән кешенең группасы Самара губернасы Бузулук (Бозаулык) шәһәрендә урнаша. Эскит үзенең «1921-1923 елларда квакерларның Россиядәге эшләре» дигән китабында түбәндәгеләрне яза: «Һәр гаиләдә диярлек мин сәкеләрдә каен һәм юкә яфраклары киптергәннәрен күрдем. Кипкәч, аларны тарттыралар, имән чикләвеге белән катнаштыралар, бераз туфрак һәм су өстиләр дә үзләре ипи дип атаган ниндидер бернәрсә пешерәләр. Бу нәрсә мичтә пешкән тирескә охшаган иде... Сабый балалар бөтенләй очрамый диярлек; очрасалар да, алар өрәккә охшаганнар иде. Әнкәләренең күкрәк сөте юк, һәм алар тизрәк үлем килсә иде, дип ялваралар... Балаларның эчләре күпкән, башлары зур, бәдәннәре рахит авыруларындагы кебек... Рәсми хөкүмәт мәгълүматларына караганда, 1 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балаларның 90 проценты инде үлгән...»

Хөкүмәт балаларны кабул итү, төрле урыннарга озату оешмалары төзи, балалар йортлары ача, ләкин аларда балалар күпләп үләләр генә. Бозаулыктагы балалар кабул итү йортын бер квакер түбәндәгечә тасвирлый: «Йорт 50 бала кабул итәргә тиеш иде, ләкин инде кичә үк аның диварлары 654 баланы сыйдырды. Гадәттә көненә 80гә кадәр кеше кабул ителә. Йорт эчендәге сасы исне сөйләп аңлату мөмкин түгел... Килеп керүебезгә без анда көндез дә төнлә дә тынып тормый торган ыңгырашуларны ишеттек. Һәр бүлмәгә, мичкәдәге балыклар шикелле, кимендә йөз баланы салганнар, һәр киндер ятакта 6шар бала. Кровать

аслары да балалар белән тулган. Тиф белән авырганнары, кайберләре ялангач килеш, аерым бүлмәдә салам өстендә ята. Алар өчен урын-җир дә, дару да, дезинфекцияләү эремәсе дә юк. Без балаларга бераз шулпа һәм кием-салым бирә алдык. Аларны караучы табиб-мазар да юк иде».

Галимҗан Ибраһимовның «Адәмнәр» исемле озын хикәясе 1921-1922 елларда Идел-Урал буйларындагы коточкыч ачлык турында сөйли. Язучы беренче җөмләсе белән үк укучыны дәһшәтле вакыйгалар эченә алып керә: «Үлем үзенең кара канатларын җәйде. Җир йөзе гүя шуның астында капланып калды. Тирә-як куркыныч караңгы каберлекләр, ләхетләр белән, бер үлгәч терелеп чыккан җанлы мәетләр белән тулды». Хикәядә мәетләрне ач этләр актарып ятуы, ачлыктан шашынып, үз кызына пычак салган Гәрәйнең төрмә камерасында асылынуы, кеше үтерүләр... — болар барысы да чынбарлыктан алып язылган. Соңгы елларда дөнья күргән рәсми документлар ачлыктан кеше ашаучылык турында коточкыч чынбарлыкны ачып салалар.

«Татар энциклопедия сүзлеге»ндә 1921-1923 елгы ачлыкның Татарстандагы халык санына ничек тәэсир итүенә карата якынча саннар китерелгән: ачлык елларда Татарстан халкы 400-600 меңгә кимегән, ә крәстиән хуҗалыклары саны 86 меңгә (16,2 процентка) кыскарган икән.

1922 елның 22 гыйнварында төзелгән документка караганда, Татарстан Республикасында ачлыктан интегүче кешеләр саны 2 462 599 булган. «Помгол» («Ачыгучыларга ярдәм») оешмасы ачкан ашханәләр саны 1 181 булып, аларда 101 234 кеше тукланган. Американ ярдәм администрациясе исә 2 237 ашханә ачкан, аларда 191 586 кеше тукланган. Балалар өчен туклану пункт-

лары 47 306 балага 798 булган һ.б. Американ ярдәм оешмасы 1923 елда балаларга ярдәмне аеруча көчәйткән. Июнь һәм июль айларында, мәсәлән, 650 000 баланы тукландырганнар. Шул ук вакытта балаларга 124 600 пар аяк киеме, 137 мең оекбаш, 16 922 одеял, 27 521 кыз балалар күлмәге, 26 312 ир балалар костюмы, 11 915 балалар пальтосы һ.б. кирәк-ярак өләшенгән. Генерал Вильсон совет хакимиятенә ачлыктан үлү куркынычы янаган 50 000 баланы Америкага җибәрергә тәкъдим итә. Рустан гайре халыклар комиссары И.Сталин бу тәкъдимне кире кага. Аның кире кагуын «нигезләү» эше Казан имамы Гатаулла Баһаветдиновка тапшырыла. Әхмәтвәли Мәңгәри язуынча, имам хәйләкәр Сталин әмере белән: «Бу балаларның чит җиргә китеп кяфергә әйләнүләренә караганда, биредә калып ачтан үлүләре динебез кушканча булыр. Үлгән сабыйлар ата-аналары өчен Аллаһы Тәгалә белән алар арасында арадашчы булачаклар», — дип «аңлаткан». Гуманлы тәкъдиме кабул ителмәгәч, генерал Вильсонга Америкага кире кайтып китүдән башка чара калмый.

Финляндия татарлары 1922 ел башында Америка Кушма Штатларының АРА дигән ярдәм күрсәтү комитеты аркылы Идел төбәгендәге зыялы фикер һәм каләм әһелләренә азык-төлек посылкалары җибәрәләр (мондый ярдәмнең Фатих Әмирханга, Галиәсгар Камалга, Галимҗан Шәрәфкә, Ризаэддин Фәхреддингә һәм Галимҗан Баруди гаиләсенә барып ирешкәнлеге мәгълүм).

АРА комитетының ярдәме турында Р.Фәхреддин түбәндәгеләрне яза: «Монда (Уфада) американнарның «Җәмгыяте хәйрия»ләре [Америка ярдәм администрациясе — АРА] декабрь унбишләрендә игътибарән ашханәләр ачтылар. Унсигез яшьтән түбән балалар, йөкле хатыннар вә бала имезүчеләр шунда ашыйлар... «АРА» исемендә булган бу җәмгыятьнең Уфа комиссиясенә Нәзарәт тарафыннан вәкил булып Җиһангир ахун Абызгилдин хезмәт итәдер... » (1922, март).

Бу ярдәмнәрне онытырлык түгел. Ләкин, билгеле булганча, хезмәткәрләренең контрреволюцион эштә катнашуын сылтау итеп, 1923 елда РСФСРда АРАның эшчәнлеге тыелган.

Бездә 1932-1933 елгы ачлыкны Украинага гына кагылган, дип әйтү дөрес түгел. Бу мәсьәләне тикшергән Гамир Гарифуллин Украинада 5 миллион чамасы, Казахстанда 6 миллионнан артык, Идел буенда 1 миллион чамасы кеше ачтан үлгән дип саный. СССРда авыл хуҗалыгын күмәкләштерү һәм илне индустрияләштерү менә шундый бәягә төшкән.

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соңгы 1947 ел да СССР күләмендә ачлык ел булып исәпләнә. Бу хакта азык-төлек җитештерү, халык саны, шулай ук үлем-җитем турындагы статистик мәгълүматлар аз. Ачлыкның ни дәрәҗәдә авыр булганлыгын, мәсәлән, ил күләмендә ипи пешерүнең 1940 ел белән чагыштырганда өч тапкыр кимүе бик ачык күрсәтә.

Татар телендәге *йот* сүзе табигый бәла-казалар (мәс., *далада* язын *җепшеткәннән* соң *даланың* боз катламы белән каплануы) аркасында хайваннарның ачлыктан кырылуын белдерә (йотлыгу − бик нык ачыгу). Рус теленә джут рәвешендә кергән.

//Ачлык арысланны да үләксәгә ташланырга мәҗбүр итә. Әс-Самарканди. *Бу сәнә ачлык елы чын халык бәгърен ашый. Кит, китап! Сабыр ит, дип әйтмә, ул халык көчен ашый.* Тукай. *Илсез калмас, телсез калмас өчен, Ачлык тотар көнгә калганбыз...* Газинур Морат. *Ачлык тоту* — ачлык игълан итү. Бу гыйбарә «ураза тоту» сүзе үрнәгендә XX гасыр азакларында барлыкка килде шикелле.

Гарәпчә ачлык — *җуг.* ■

ӘТКӘМ-ӘНКӘМ, БАЛАМ-ОНЫГЫМ ТЕЛЕ

ТЕЛ – ХАЛЫКНЫҢ ҖАН СУЛЫШЫ

Яратам мин борынгы кыпчак теле - татар телен,
ерак борыннан, скиф-сак заманнарыннан бирле,
мең еллар аша, олы фаҗигаләр аша, хәтәрләр аша,
бернинди ятлар шаукымына, көчләүләргә бирелмичә,
халкым аның бөркет чаңылдавыдай тамак төбеннән
чыккан һәм ирләрчә нык авазлы, көмеш чыңыдай саф, йомшак яңгырашын
саклап алып килгән.

● Гаҗәеп үзлек – саннар гармониясенә тәңгәл төзеклек, аһәңлелек бар безнең төрки телдә. Гүяки ул – күк затлары иҗат иткән илаһи тел! Безнең тел – мең еллар тәҗрибәсен эченә алган, бөек фән-сәнгать казанышларын чагылдырган иң борынгы мәдәниятләр теленнән булган тел ул!

● Тел – халыкның җан сулышы.

● Тел бар икән, яши икән – халык та бар, халык та яши.

● Тел – аралашу, аңлашу чарасы гына түгел ул, тел иң беренче нәүбәттә – халыкның рухи байлыгын, меңнәрчә еллык тәҗрибәсен җыйган бетмәс хәзинә.

● Сүзләр – кодрәтле тел агачының мәңге яшел, мәңге яшь яфраклары.

● Тел – милләтне милләт иткән иң беренче шарт.

● Тел – иң соңгы чик, аны да дошманга бирсәң, башка чигенер җир дә юк. Чигенүнең кирәге дә юк.

● Милләт милләт булып калсын өчен – тел алышынмаска, кан югалмаска тиеш.

● Ватан, җир киткәндә дә тел кала, кан кала. Тел белән кан киткәндә, Ватан, җир калса да, милләт китә.

Гаҗәеп үзлек – саннар гармониясенә тәңгәл төзеклек, аһәңлелек бар безнең төрки телдә.

● Бөек дастаннар теле, бөек шагыйрьләр теле. Моңлы җырлар теле, телләр арасында мәгърур тел, туган телем, синдә беренче кешелек сүземне әйттем һәм җирдән киткәндә соңгы хушлашу сүзләрен дә синдә әйтсәм иде!

Мәҗит Гафури
(1880-1934)

АНА ТЕЛЕ

Үз ана телем — минем өчен
Матур, иң тәмле тел,
Үз телем — үз әйберем
Булган өчен ярата күңел.

Шул ана телем белән
Мин максудымны аңлатам;
Шул ана теле белән:
— Бала! — диләр атам-анам.

Шул тел белән иман,
Уку-язу үрәнәм.
Шул тел аркылы укып,
Белеп, булырмын чын адәм.

Әле шул тел белән укыйм,
Язам һәм сөйләшәм.
Шул татар теле белән сөйлим
Берәр көй көйләсәм.

Сәгадәт Ибраһимов, *тел галиме*
(1928-2008)



НӘРСӘ УЛ — ЛАЕШ ШУЛПАСЫН ЭЧҮ?

«Синең әле, энем, Лаеш шулпасын эчкәнең юк». Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасындагы бу юлларны күбебез хәтерли булыр. Кара урман эчендә качкыннарның үткәнне искә алып, үзара бәхәс корулары, ат карагының ат урлау ләззәтен иптәшләренә бик тә тәмләп, үтә белеп сөйләве кемнең генә хәтерендә калмас икән? Арада күпне күргән Шәйхи бабай искә төшерә әлеге сүзләрне. Ул аны үз авылындагы Хәйдәр карттан ишеткән булган. Шунда ук бу әйтемнең кайчан барлыкка килүенә ишарә дә бар.

Аның моннан дүрт йөз егерме еллар элек барлыкка килү ихтималы тарихи вакыйгалар, урыс елъязмаларында китерелгән мәгълүматлар белән дә раслана.

Эчтәлегенә, кулланышына карап, без ачык әйтә алабыз: Лаеш шулпасы эчү — ул инде үз җилкәңдә нинди дә булса бер авырлыкны тату, тормыш тәҗрибәсе туплау, утны-суны кичү, дигән сүз.

Халыкта әйтем булып китәрлек нинди кыен хәлгә нигезләнде икән соң ул? Уналтынчы гасыр урталарына караган елъязмада менә шундый тарихи вакыйга искә алына. Казан каласының хәрби башлыгы 1557 елда, Чулман, Идел буе, Арча ягы татарларын җыеп, шәһәр салырга боера. Менә шул мәҗбүри китерелгән халык көче белән Лаеш каласы барлыкка килә,

Лаеш шулпасы эчү – ул инде үз җилкәңдә нинди дә булса бер авырлыкны тату, тормыш тәҗрибәсе туплау, утны-суны кичү, дигән сүз.

өстәвенә алар шәһәр тирәсен ике метр тирәнлектәге һәм ике метр киңлектәге чокыр белән әйләндереп тә чыгалар. Җәйге челләдә, көзге пычрак, кышкы салкыннарда тамаклары ризыкка да рәтләп туймаган кешеләрнең авыр язмышын чагылдыра икән менә бу өч бөртек сүз — Лаеш шулпасын эчү.

Лаеш каласы халык теленә әнә шул ягы белән кереп калган, ә бу турыдагы әйтем, гасырлар буена буыннан-буынга күчеп, безнең көннәргә килеп җиткән. Бу әйтемне халык тәҗрибә туплауга, күпне күрүгә ишарә рәвешендә әледән-әле әйтә тора, язучылар да аны үз әсәрләрендә куллана килә. Фатих Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» исемле повестенда, мәсәлән, Гафиятулла карт үзенең улы Айдарны, аңа бик үк баш биреп бетермәве өчен, шул ук сүзләр белән битәрләргә җыена:

— Яхшымы — яманмы, бу аның үз өе — үз оясы. Трактористлар бригадиры булдым дигәч тә, борынын бик күтәрмәсен, атасы аның Лаеш шулпасын аннан күбрәк эчкән.

Шәһәр, авыл, елга исемнәренә бәйле әйтем һәм мәкальләр һәр халыкта да бар. Мәкаль нигезенә салынган бу исемнәрнең нинди дә булса бер мөһим ягы истә тотыла. Без телгә алган әйтемдәге кебек, берәр тарихи вакыйга, яисә шәһәрнең ил күләмендә тоткан дәрәҗәсе, яки ул урында эшләнгән берәр әйбернең сыйфаты, урнашкан урынның үзенчәлеге, ераклык-якынлыгы, бер дә булмаса, берәр көлкеле хәл белән тирә-юньгә фаш булуы мәкаль һәр әйтемнәрнең барлыкка килүенә нигез булып яткан.

«Бер көндә генә Мәскәү дә төзелмәгән», «Ялгыш хисап Мәскәүдән әйләнеп кайта», «Телең булса, Киевка барып җитәргә була», «Самовар төяп, Тулага бармыйлар», «Әстерханда сыер бер акча, килә-килә мең акча», «Агыйделнең аръягында — бер энәгә бер сыер», «Зәйнең башы яланлы, Зәй тамагы Баланлы» кебек күпләгән мәкаль һәм әйтемнәрнең үзәгенә шәһәр, елга исемнәре куелган. Бохара, Баку, Казан, Мәкәрҗә, Касыйм, Кәшер кебек авыл һәм шәһәр исемнәре, Идел, Чулман, Нократ, Җаек, Зөя, Кабан ише гидронимнар андый әйтем һәм мәкальләрдә еш очрый.

Шуны да әйтергә кирәк: һәр төбәкнең үз тирәсендә генә телдән телгә күчеп йөри торган шул як авыл исемнәре белән бәйле әйтемнәр дә мәгълүм. Аларны җыю-туплау — безнең бурыч.

Рәшит Әхмәтҗан
(1941-1995)



ӘНКӘЙ ТЕЛЕ

И туган тел! Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык.
Таралган ул... Әгәр син булмасаң,
Бетәр иде күптән югалып.
Югалмадың,
Югалтмадың безне —
Халык исән калган син барга.
Бу дөньяга күзебезне ачтың,
Хакыбыз юк кабат йомарга.
Ләкин күпләр үз йортыннан куды
Бүген сине — үзенең Әнкәсен.
Үз әнкәсен йорттан куган кеше,
Туган илем бар, дип әйтмәсен!
Әйтмәсен!..

Миркасыйм Госманов
(1934-2010)



АНА ТЕЛЕ

«Безнең халык кешенең дөньяга килгәч үк үзләштерә башлый торган һәм белүе һичшиксез кануни булган телен АНА ТЕЛЕ дип атаган, ләкин «ата теле» дип түгел. Гәрчә паспорт өчен миллилекне билгеләгәндә беренче нәүбәттә ата каны исәпкә алынса да.

Бу урында ана теле тәгъбирен искә төшерүем очраклы түгел. Кайчандыр үз телебезне бик нечкәләп белгән, аңа гел дан җырлаган, шуның өчен иреккә чыккач та шактый кыйналган олы шагыйрьләребездән Хәсән ага Туфан халык теленең сыйфатын Аналар тәэмин итә, дип әйткән иде. Күрәсең, ул элеккерәк чор аналарын күз уңында тоткан булса кирәк. Чөнки хәзерге чор балаларыбызда мондый сыйфатлылык сирәгрәк, урыны-урыны белән генә чагыла диярлек. Авылдан чыгып, шәһәрдә бала тәрбияләп ятучы яшь әнкәйләрнең күпчелеге, мәрхүм Мөхәммәт Мәһди кайчандыр бер ачы елмаеп алганча, «Иди, с папой играй», дип җиффәрәләр...

Язмамны дәүләт, империяләр уздыра торган сәяси алымнардан башлап, «тәртәне» аналар һәм, гомумән, хатын-кыз ягынарак борып җибәрүем һич тә очраклы түгел. Чөнки һәрвакытта социаль проблемаларның чыганагы гаиләгә барып тоташа. Киләчәктә булачак процессларның башы, яисә аларны булдырмый торган сәбәпләр гаиләгә, аның сыйфатына, үзаңына бәйләнәчәк. Ә гаиләнең умыртка сөяген хатын-кыз — Ана тәшкил итә.

Бүлгәләү сәясәте хөкем сөргән илдә яшәргә дучар ителгән, хәзер тагын да яңа чор бүлгәләүләр сынавы алдында торган халыкның киләчәге дә, әгәр төптәнрәк уйласаң, урамда һәм җыеннарда «Без — татарлар», дип кычкырып, нотык сөйләп йөрүче ирләргә караган кебек, бала һәм кеше тәрбиясенең төп йөген җилкәсендә тартучы Аналарга да бәйле. Болай әйтеп мин җаваплылык мәсьәләсен гел хатын-кызлар өстенә аударырга җыенмыйм. Шул ук вакытта халык, милләт язмышы ничек хәл ителүдә аларның да өлешләре аз түгеллеген искә төшерергә телим. Милли үзаң, милли рух иң элек Ана теленнән башлана, Ана теле белән тәэмин ителә».

Зөлфәт (1947-2007)

ТУГАН ТЕЛ ТУРЫНДА

Тел ачылгач, әйтә алсаң — «Әни» дип,
Тел ачылгач, әйтә алсаң — «Әти» дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылмас,
Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта әйтә алсаң — «Әни» дип,
Соң минутта әйтә алсаң — «Әти» дип,
Күзләреңә яшьләр тыгылыр,
Туган телең әнә шул булыр.

*Сәхифәне **Рөстәм Акъегет***
Татарстан радиосының
«Тел күрке — сүз» тапшыруы язмаларына нигезләп әзерләде.

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның ноябрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөселман рабочийларының ярдәмнәре

Алафузовлар мәсҗеденең[1] имамы Хисаметдин әфәнде Җәгъфәров, Корбан гаетеннән мәҗрухларга [сугышта яраланганнарга] иганә хосусында вәгазь сөйләп, халыктан көчләреннән килгән кадәр ярдәм итүләрен үтенгән икән. Мөселман рабочийлары шундук үзара 12 сум акча җыеп, имам әфәндегә тапшырганнар.

Имам Хисаметдин әфәнде бу акчаны идарәбезгә китереп, мәҗрухларга иганә кабул итү комитетына тапшыруыбызны үтенде. Имам әфәндегә хезмәте өчен тәхсиннәр укыйбыз.

Кояш. — 1914. — №546. — 2 ноябрь

Яңа елны каршы алу

Менә инде берничә еллар Казан халкы һиҗри елны бик тантаналы сурәттә Шәрык клубында каршы аладыр. Шәрык клубының бу кичәсе гадәттә бик күңелле вә рухлы үтә. Менә Казанның бөтен мөселман зыялылары вә могтәбәраны диярлек җыела — гадәттә бәйрәм һәйәтен [сурәтен] ала. Бу елда да яңа елны каршылау кичәсе булды. Әгәр сугыш вакытына махсус бер рух төшенкелеген истисна итсәк[2], бу ел да ул кичә хәятле вә күңелле узды. Шулвакытта гына булса да, дөньяны каплап алган бәлане онытып торган шикелле бер хәл хөкем сөрде.Төрле төстәге утлар һәм чыршы ботаклары белән җыештырылган клуб бинасына энә ташласаң, җиргә төшмәслек дәрәҗәдә күп халык җыелган иде. Монда иң садә бер шәкерттән башлап, адвокат вә врачларыбызга кадәр хазир иделәр.

Әүвәл мәгънәсез генә, ләкин көлкеле генә ике пәрдәле бер водевиль, аннан соң музыка вә Кавказ биюләре кыйсеме вә аннан соң инде яңа елны каршылау мәрасиме башкарылды. Гадәттә бер ягында һилял [яңа тулган ай] белән туа торган яңа ел, бу ел гомуми бәлагә матәм йөзеннән, һилял урынына чәчәкләр белән генә туды. Тәбрикләшү вә яңа ел өчен ватаныбызга вә гомум бәни адәмгә [адәм балаларына] хәерләр теләшү мәрасиме тәмам булганнан соң, халыкның бер кыйсеме клубтан таралды. Зыялылар кыйсеме фирка-фирка булып, буфетка җыелып анда кечкенә ашны уздырдылар.

Кояш. — 1914. — №551. — 9 ноябрь.

Суга мохтаҗлар

Тиреслек башы якыннарында торучылардан 99 кеше имзасы илә, Казаков мәсҗеде[3] янына водопровод ясалуына ярдәмдә булынуын үтенеп, вилаять вәлисе [губернатор] җәнапларына бер гариза тәкъдим ителгән. Бу үтенеч шәһәр управасына тапшырылган.

---

[1] Алафузовлар мәсҗеде — Алафузовларның җитен туку фабрикасындагы мәчет.

[2] Истисна итсәк — исәпкә алмасак мәгънәсендә.

[3] Казаков мәчете — 1876 елда хәзерге Татарстан урамы очына сәүдәгәр М.Н.Казаков иганәсенә төзелгән мәчет. 1975 елда сүтелә.

r Имамнар вә мәҗрухлар

Казан имамнары, үзара сүз беркетеп, шәһәр шифаханәләрендәге мөселман мәҗрух гаскәриләрнең хәлләрен белешеп, аларга вәгазь вә нәсыйхәт кылып йөрергә карар биргәннәр. Имамнар, шифаханәләрне кыйсемнәргә [өлешләргә] бүлергә вә һәр кыйсемгә бер имам билгеләп, шушы имамга, үзенә тәхсыйс ителгән [билгеләнгән] шифаханәләргә кереп йөрү, мәҗрухларга Коръән уку вә имам кирәк вакытларда җитешү вазифаларын йөкләргә уйлаганнар. Бу карар вә бу уйларны, мәҗрухларны башкару идарәсенә гарыз итүне [белдерүне] дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләренә тапшырганнар.

Кояш. — 1914. — №552. — 10 ноябрь.

***

Вознесенская урамында[4] барып ятканда Мәлихә Мөхәммәдҗанова дигән Пеләтәндә[5] торучы 50 яшьлек карчыкны бер ломовой чанасы белән бәрдереп, иңбаш, кул вә аягын имгәтеп, качып киткән. Ломовойның номерын күреп калучылар булган. Качып киткән 285 нче номерлы ломовой өстеннән протокол куелган.

q Яшерен мунчалар

Шәһәр управасының мөһәндислек [инженерлык] шөгъбәсе [бүлеге] Идел буендагы болыннарда җир үлчәп йөргәндә, шәһәр болыннарына мунчадан чыккан төсле су акканын сизгән. Тикшерә торгач, бу суның чынлап та Бишбалтадагы яшерен мунчалардан чыканын белгән. Бу мунчалар, рөхсәтсез ачылган булып, кеше башыннан унар тиен алынып кертеләләр вә чиктән тыш шакшы тотылалар икән. Боларны яхшырту вә яхуд бетерү чараларына керешелгән.

r Кеше үтергән өчен

Бу елның 20 нче гыйнварында Мокрая урамындагы[6] Кузьмин трактирында дүрт татар, утырып эчкәннән соң, шулар арасыннан Нигъмәтуллин дигәне иңсәсеннән чалынган хәлдә шифаханәгә җибәрелгән булган. Тикшерелә торгач бу Нигъмәтуллинның шул көннең көндезендә ат базарында Хөснетдинов фамилияле ат карагы дип танылган кеше белән ачуланышканнары вә сугышканлыклары, Нигъмәтуллин көчле булып, ат карагын җиңгәнлеге, ат карагының: «Очрарсың әле, мин сине үтерми куймыйм», — диеп янап калганы беленгән. Нигъмәтуллин чалынган хәлдә күренгәч, эчеп утырган татарларның һәммәсе кулга алынган вә ат карагы өстеннән кан тамчылары эзләре табылган булган. Трактирда татарлар утырган өстәл янындагы көзге артыннан канлы озын пычак та табылган булган. Инде хәзер окружной судта шул эш каралгач, окружной суд ат карагы Хөснетдиновны бөтен хокукыннан мәхрүм итеп, 2 ел да 9 айга арестантская ротага хөкем итте.

q Дарулаган

Ягодныйда[7] Гайнетдин фамилияле үзен дәвалауга «бик маһир» диеп йөри торган берәү бар икән. Бу берәүнең авыру кеше күрсә дарулау тамы-

---

[4] Вознесенская урамы — хәзерге Островский урамы.
[5] Пеләтән — Иске Татар бистәсенең көньягында булган авыл. XIX гасыр башында бу урынга мөселманнар күпләп күченә. Әҗем мәчете һәм мәхәлләсе барлыкка килә.
[6] Мокрая урамы — хәзерге Коротченко урамы.
[7]Ягодный — Казанның көнбатышында булган бистә. Хәзер бу бистәдән мирас булып, Слободская урамы гына калды.

ры тибеп куя икән һәм дарулап җибәрә икән. Өченче көн шушы «табиб»ка Мөхәммәдҗанов фамилияле 60 яшьлек каенатасы килгән вә чәй янына утыргач, аркам сызлый, дип зарланып куйган. Кияү табибның дарулау тамыры кычытып китеп, каенатасын диванга яткызып куйган да, шүрлектән серная кислота алып, аркасына сибеп ышкый башлаган. Каената: «Бик әрнетә бит», — дигәч, кияү мирза: «Күпме каты әрнесә, сәламәтлек өчен шулхәтле яхшы була», — дип ышкуын дәвам иткән. Берничә минут ышкыгач, каената чыдый алмыйча, кычкырып торып, урамга чыгып киткән. Бу арада кияү мирзаның кулын да кислота байтак ашап өлгерән икән, ул да урамга чыгып карга ышкына башлаган. Болар икесе дә карда аунаган җирләреннән алынып, Бишбалта шифаханәсенә җибәрелгәннәр.

Кояш. — 1914. — №554. — 12 ноябрь.

Җәмгыяте хәйриябездә

Җәмгыяте хәйрия идарә әгъзаларының җыелышы түбәндәге карарны биргән. Казан җәмгыяте хәйриясе мәҗрухларны тәрбия итешүдә мәзкүр максуд белән ясалган мөселман мөәссәсәләренә [оешмаларына] ярдәм итәргә тиештер. Моны киңрәк сурәттә вөҗүдкә чыгару [гамәлгә ашыру] өчен җәмгыятьнең үз суммасы аз. Шунлыктан бу максудка махсус иганә җыярга тиештер.

Җәмгыяте хәйрия исеменнән мәҗрухларны тәрбиягә катыштыру өчен Казанны өч районга бүлеп, шул районның һәрберсенә иганә җыючылар тәгаен ителгән. 1 нче район — Болакның аргы ягыдыр. Бу якта җәмгыять файдасына ике кеше: Хафиз әфәнде Әхтәмов һәм Зыя әфәнде Ваһапов иганә җыячактыр. 2 нче район — Болак вә Кабан белән Мәскәүский вагон юлы арасындагы җирләрдер. Бу урында Зиннәтулла әфәнде Госманов, Хаҗимөхәммәд әфәнде Әхтәмов һәм Габдрахман әфәнде Бикбов иганә җыячаклардыр. 3 нче районга Мәскәүский вагон юлы белән бүленгән икенче якның бөтенләе керәдер. Бу районда Габдрахман Үтәгәнов, Мөхәммәдгали Сәхапов һәм Салих Исмәгыйлов әфәнделәр иганә җыячаклардыр.

Бу иганәләрдән, җәмгыяте хәйрия, Казандагы мөселман лазаретында 2-5 кровать һәм җәмгыятьләребез иттифакы тарафыннан тәэсис ителә [төзелә] торган күчмә лазаретта берничә кровать тәрбия ителәчәктер.

Кояш. — 1914. — №559. — 20 ноябрь.

Кара түгелгән

«Сарай» номерлары астында Пригожин дигән кешенең мех кибетләре бар. Нәкъ шушы кибетнең өстендәге бер номерда язу карасы складе бар икән. Шушы кара складындагы шешәләр ватылып кара түгелгән дә мех магазинына аккан. Магазин хуҗасы, 5 мең сумлык мехыма зарар тиде диеп, полициягә хәбәр иткән. Вакыйга хакында протокол куелган.

Кояш. — 1914. — №560. — 21 ноябрь.

Әйберләр сатыла

19 һәм 20 октябрьләрдә «Әйбер җыю көне»ндә җыелган нәрсәләрнең мебельләр, картиналар, рамнар вә музыкальный инструментлардан гыйбарәт булган кыйсеме 30 нчы ноябрьдә көндезге сәгать 11дән башлап сатыла башлаячак. Әйберләрне һәр көн көндезге сәгать уннан өчкә кадәр Гостиный двордагы[8] аукционный залда һәм складларда, әмма рояльләрне шәһәр ломбардларында күрергә мөмкиндер.

[8] Гостиный двор — хәзер Милли музей урнашкан бина.

q Тамаша урыннарында

Өченче көн 25ендә «Новый клуб[9]»та Габдулла Кариев тәхте риясәтендәге [җитәкчелегендә] «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан Гаяз Исхаковның «Мөгаллимә»се тамашага куелды. Сәхнәнең бай вә җитешлекле булуы, артистларның үз рольләрен пөхтә иттереп уйнаулары аркасында пьесада еш-еш кына очраган аерым-аерым күренешләр, аерым-аерым бүлекләр чын мәгънәсе белән матур вә рәссаманә төзелгән вә үтәлгән манзаралар тәшкил итәләр. Беренче пәрдәдәге музыка вакытындагы вә икенче пәрдәдәге карт хәзрәт утырышларындагы телсез вә сүзсез манзаралар хосусый сурәттә мөмтаз[10] булып торалар.

Пьесада Гаяз Исхаков каләменә генә хас «чыгарып кулына тоттыру»лар, «ыштан балагыннан шалкан төшерүләр» күк җирәнгеч тәгъбирләр вә ифадәләр [аңлатулар] очраганы шикелле, һичтоткарсыз чәй эчертүләр күк артист хәлен бер дә игътибарга алмаулар, чиксез озын хатлар укыту, мәгънәсез озын нотыклар сөйләтү күк тамашачыларны ялыктыра торган урыннар да юк түгел. Муллалар иштиракь иткән [катнашкан] мәҗлестә бер нәрсә шәрәфенә [хөрмәтенә] эчү гадәте мөселман арасында булмаса да, мөхәррир монда бер «новаиҗат» ясап ташлый.

Мөхәррир үзенең аерым-аерым шәхесләрен колакларыннан тартып китерә дә сәхнәгә кертә, китерә дә сәхнәгә кертә... Карт хәзрәт белән аның хатынын алты мең чакрым кадәр җирдән ни өчен өстерәп китереп керткәне аңлашылмый. Сәхнәгә сөйрәлеп кертелгән артистның да кертелүенә ихтыяҗ сизелми...

Әсәр бер-бер артлы килгән аерым-аерым, матур-матур гына манзаралардан гыйбарәт булса да, барын бергә җыйгач, тулы бер мәгънәгә дәлил кылудан гаҗиз кала. Менә шушы аерым кисәкләрне артистлар иттифакъ белән менә дигән яхшы итеп тасвир иттеләр. Гадәттәгедән күп артык булган мөселманнар бу манзараларны бик яраттылар.

Гыймад Нугайбәк.

Кояш. — 1914. — №566. — 28 ноябрь.

r Яшь кызларның һәдиясе

4 нче мәчет[11] мәхәлләсендәге Ләбибә Хөсәения[12] идарәсендә булган кызлар мәктәбе шәкертләреннән ноябрь башында мәҗрухлар файдасына иганә җыелып, инспектор җәнапларына 19 сум 11 тиен акча тапшырылды. Һәм ноябрьнең 28ендә шул ук кызлардан вә мөгаллимәләрдән түбәндә язылмыш нәрсәләр җыелып, окружной инспектор йортына тапшырылды. Сугыш мәйданындагы гаскәриләргә һәдия [бүләк] буларак 50 данә кулъяулыгы, 8 данә җылы күлмәк һәм 44 данә һәртөрле ситсы күлмәк, 31 перчатка, 10 оекбаш, 13 сөлге, 5 пар киндер аяк чолгавы, 1 данә дәстерхан [ашъяулык], 1 данә ыштан, 7 коробка конверт, 5 пачка почтовый кәгазь, 1 төргәк конверт һәм кәгазьләр, 6 дюжина күлмәк төймәсе, 28 кәтүк җеп, 12 кәгазь энә, 40 карандаш, 24 кадак шикәр, кадак-өч чирек чәй, 19 данә капчыклар чәй-шикәр илә, 4 тартма малиновый напиток, 10 кусок исле сабын, 1 пот кер сабыны. Җәмалетдин Хөсәенов.

Кояш. — 1914. — №567. — 30 ноябрь.

---

[9] Новый клуб — элекке Травматология һәм ортопедия институты бинасы, биредә хәзер кунакханә эшли.

[10] Мөмтаз — башкаларына караганда өстен булу мәгънәсендә.

[11] 4 нче мәчет — хәзерге С.Садыйкова урамындагы Зәңгәр мәчет.

[12] Хөсәенова Ләбибә Һади кызы (1880-1920) — педагог. 1904 елда Казанда кыз балалар өчен мәктәп оештыра. «Ләбибә Хөсәения мәктәбе» дип танылган бу уку йортының 1914 елның 29 апрелендә (13 маенда) булган янгында тулысынча янып бетүен һәм өч ай эчендә яңадан төзелеп, көзен укулар башлануын истә тотыйк.

«Ядкяр»челәр «Волга» лагеренда, иң өстә рәссам Рәшит Имаш, шагыйрә Шәмсия Җиһангирова, шагыйрь Мөдәррис Әгъләм, Батулла, шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова, КДУ студенткасы Хәбирә Шаһиева, шагыйрь Роберт Миңнуллин. 1974, 5 май

Рабит Батулла

КӨЛКЕ КӨЛӘ КИЛӘ, АРТЫННАН КУА КИЛӘ...

Мин гомерем буе сатира язып яндым.

Нәкый Исәнбәт,
1965, 15 март.

ШТМ КАЙДАН БАШЛАНА?

1969 нчы елда мин көлке театры оештырырга алындым. Кече күләмле әсәрләр, театраль миниатюралардан торган сценарий яздым. 22 декабрьдә Актерлар йортында Шаяннар-тапкырлар мәҗлесенең (ШТМның) беренче, оештыру кичәсе булды. Равил Шәрәфи, Рәшит Шамкай, Айдар Хафиз, Фирдәвес Хәйруллина, Ирек Баһман, Рафаэль Сәхәби һәм башка артистлар белән без анда төрле пародияләр, җәмгыятьтәге көлкекызганыч җитешсезлекләр турында сатира-юмор, пародия шәкелендә халыкка сөйләдек. Кичә зур уңыш казанды.

1970 елның 26 гыйнварында ШТМның «Бакчага ыргытылган ташлар» исемле көлке кичәсе булып узды. Анда артистлар төркеме белән язучылар ярышты. Артистларның капитаны Шәрәфи, язучыларныкы — Батулла иде. Кичәне Айдар Хафиз алып барды.

Актерлар йорты каршында ике юнәлештә эш башлаган идек. Аның беренчесе — «Ядкяр» исемле, Татарстанның иҗат яшьләре оешмасы. «Ядкяр» яшь иҗатчыларның яңа әсәрләре белән тамашачыларны таныштыру, яшьләргә иҗади ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә иде. Рәссамнар, музыкантлар, артистлар, язучылар бергә тупланып, гаҗәеп күркәм эшләр майтара башлаган иде.

«Ядкяр» исемле бу тәшкилатның планына багыйк.

1. Оештыру кичәсе, ШТМ шәкелендә узды. 1969, 22 декабрь. Автор, режиссёр, сөйләүче — Батулла. Кичә зур уңыш казанды.

2. «Бакчага ыргытылган ташлар». ШТМ. Сатира театры, 1970, 26 гыйнвар. Автор, режиссёр, сөйләүче — Батулла. Кичә зур уңыш казанды.

3. «Аваздашлар». 1970, 23 февраль. Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташның иҗатына багышланган лирик кичә. Автор, режиссёр, сөйләүчеләр — Батулла һәм Дания Нурлы. Зур уңыш казанды.

4. «Дүрт Ринат». Шагыйрь Ренат Харис, актер Ринат Таҗи, композитор Ринат Еники, балет артисты Ринат Ибәтуллинның иҗат кичәсе. Автор, режиссёр, сөйләүче — Батулла. Зур уңыш казанды.

5. Сәгыйть Рәми шигърияте. Өстәгеләр рөхсәт итмәделәр. Сәгыйть Рәми ул пессимистик шигырьләр яза, ул буржуаз шагыйрь, диделәр.

6. Дәрдмәнд шигърияте. Рөхсәт итмәделәр. Промышленник, эксплуататорны пропагандаларга алындыңмыни? — дип, Обкомның культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин миңа өстәл төйде.

7. Ренат Харис белән Мирсәет Яруллинның «Кеше» ораториясен тәкъдир итү кичәсе. 1970, 23 апрель. Уңышлы узды. Бу әсәр өчен авторлар икесе дә Муса Җәлил исемендәге комсомол бүләген алды.

8. Сәнгать яңалыклары кичәсе. 1971, 15 февраль. Рифкать Гомәровның «Саз» ансамблен тәкъдир итү. Зур уңыш казанды.

9. «Җирнең гыйсъянчы углы». Һади Такташ. Автор, режиссёр, сөйләүче — Батулла. 1970, 28 декабрь. Сценарийны обкомнан «печеп» чыгардылар. Мине җиңә алмагач, сценарийны Нур Гыйззәтуллинга биреп тунатканнар. Өстәгеләр әйтте: «Менә, профессиональ белгеч Гыйззәтуллин Такташның «теге» шигырьләрен сәхнәдән укырга ярамый, диде». Кичә уңыш казана алмады. Шагыйрь Нури Арслан әйтте:

— Өметләрне акламадың, Батулла! Такташның беренче чор иҗатыннан башка Такташ юк! — диде.

10. Язучы һәм драматург Батулланың иҗат кичәсе. Өстәгеләр рөхсәт итмәде. «Батулла кем булган әле ул

кадәр, аерым кичә оештырырга?» — дип, сценарийны кире бордылар.

11. Композитор Фасил Әхмәтовның иҗат кичәсе. Әйбәт булды.

12. Композитор Мирсәет Ярулинның иҗат кичәсе. Әйбәт булды.

13. Һәр кичәдә яшь рәссамнарның күргәзмәсе. Һәрвакыт уңыш казана килде: Эрот Зарипов, Рәшит Имаш, Бакый Урманченың сөлгеләр күргәзмәсе...

14. Творческие портреты русскоязычных поэтов: Рустема Кутуя, Валерия Синева, Николая Беляева. Сценарист, режиссёр, ведущий — Батулла. Имел успех, особенно — Рустем Кутуй.

Һәм башка, һәм башка кичәләр, кичәләр...

Минем кушуым буенча композитор Фасил Әхмәтов белән шагыйрь Разил Вәлиев «Ядкяр»нең үз җырын яздылар. Аны хәзер дә еш кына җырлыйлар. Бу җырны без «Ядкяр»нең гимны дип йөри идек. Ул озын гомерле булды, шөкер.

«Ядкяр»дә танышып, композитор Луиза Хәйретдинова белән шагыйрь Зөлфәт татар балаларына «Мәкерле песи» исемле беренче опера иҗат иттеләр.

«Ядкяр» кушуы белән Нурихан Фәттах татар әкиятләренә нигезләп «Энҗеле үрдәк» исемле пьеса язды, ул пьеса Курчак театрында куелды һәм озак еллар уңыш белән барды. Режиссёры — Батулла.

Рөстәм Мингалимов та беренче пьесасын шушы иҗади берләшмәдә иҗат итте. «Шүрәлеләр үч алмый» исемле ул пьеса Әлмәт театрында еллар буе уйналды.

Гәрәй Рәхим дә «Ядкяр» кушуыннан Тукайның «Кәҗә белән сарык» шигырен пьесага әверелдерде, ул да Курчак театрында куелды. Режиссёры да Батулла иде.

Рәссамнарның күргәзмәләре, композиторларның яңа әсәрләрен тәкъдир итү кичәләре аена икешәр, өчәр тапкыр була торды. Яшь рәссамнарга күргәзмәдә катнашу ул дәрәҗә иде. Шуңа күрә рәсамнар бик теләп ШТМга, «Ядкяр»гә ярдәмгә атлыгып торалар иде. Алар артистларга, язучыларга шаржлар ясый, сәхнәне җиһазландыра.

Лирика кичәләрендә сәнгатьнең бөтен төр әһелләре дә актив катнаша иде. Шулар өстенә «Ядкяр» ел саен яз башында «Идел» лагерына дүрт көнлек иҗат исәп-хисабына туплана иде. Беренче көн — әдәбият көне, икенчесе — театр көне, өченчесе — музыка көне, дүртенчесе — рәссамнар көне була иде. Яшьләрнең кыюлыгы, сәхнәдән яңгыраган сатира, пародияләр күпләргә ләззәт бирсә дә, байтакларның эчен пошыра башлады. Бу эшкә хәтәр оешмалар килеп катнашты.

«Ядкяр» өч елдан артык эшли алмады, аны яптылар. Мин моның шулай бетәчәген алдан ук сизенә идем, шуңа күрә, оешманың исемен дә «Ядкяр» (Мәрхүмнәрнең якты истәлеге) дип кушкан идем. Шулай итеп, «Ядкяр»нең дә башына суктылар. Мине ул эштән алып ыргыттылар.

ШТМны ни өчендер туктатмадылар, шөкер. «Тегеләрнең» үзләренең рәхәтләнеп көләсе килгәндер, мөгаен. ШТМ 1969 елдан 1986 елгача эшләп килде. ШТМның репертуарына күз салсак, андагы байлыкка шаккатыр идек. Бер том театраль миниатюралар, яңа җырларны тәкъдир итү кичәләре, әйтик, Фасил Әхмәтов белән Равил Фәйзуллин иҗат иткән «Китәсез дә мени, аккошлар»ны беренче тапкыр Вафирә Гыйззәтуллина «Ядкяр»дә башкарган иде. Бу җыр аның репертуарында гомере буе саклана килде. «Саз», «Ләйсән» ансамбльләрен, шагыйрьләрнең яңа шигъри китапларын, рәссамнарның яңа эшләрен тәкъдир итү кичәләре... санап бетергесез эшләр...

Беренче ШТМда «өйгә эшне» артистлар белән язучылар уртакка эшләргә тиешләр иде. Кәмитен драматурглар язарга, шул кәмитне

артистлар уйнап бирергә, дип килешенде. Кәмитне мин яздым. Аны Равил Шәрәфи, Роберт Әбүл, Хәлил Мәхмүтләр башкарды.

Сәхнә уртасында ике учы белән оят җирен каплап, шәп-шәрә Роберт басып тора, әлбәттә, ул бөтенләй үк шәрә түгел, яшел яфрак сыман трусик кигән иде ул. Аның янында Тәңре-Шәрәфи басып тора. Тәңре янында — Җәбраил фәрештә.

— Менә, Тәңрем, сез бу адәмне ясадыгыз инде, хәзер аны нишләтәбез? — ди Җәбраил-Хәлил.

— Язып куябыз! — ди Тәңре.

— Ничек язып куябыз, ни дип язып куябыз соң?

— Пропискасы бармы?

— Юк, Тәңрем, аның пропискасы юк.

— Ни өчен аны прописать итмәдегез?

— Патамушта, аның торырга урыны юк.

— Яз! Торырга урыны юк, диген!

— Яздым.

— Хезмәт хакын күпме ала?

— Аның хезмәт хакы юк,Тәңрем!

— Исеме ничек?

— Аның исеме дә юк бит әле, Тәңрем! Кем дип языйм соң, Тәңрем?

— Адәм көлкесе! Исеме юк, торыр урыны юк, пропискасы юк, хезмәт хакы юк, киярго киеме юк! Яз! Курчак театры артисты, диген!

Кәмит уйналып беткәч, зал тулы шыгрым тамашачының алкышлаганын, кычкырып көлгәнен карап торган кеше хәйран калыр иде. Бу — ШТМның беренче пародиясе булды.

Уңыш казандык казануын, ләкин курчак театры артистлары безгә бик каты үпкәләгән иде.

— Нигә инде син, Батулла абый, безне мыскыллыйсың, үзең дә курчак театрында эшләп киткән кеше, хәзер бөтен кеше бездән көлә, — диләр.

— Җанкисәкләрем, мин сезне мыскыл итмәдем, без сезне якладык, без курчак театры артистларына прописка, торыр урын, өс-башын карарлык хезмәт хакы бирсеннәр, дип уйнадык, — дигәч кенә аңладылар бичаралар.

Дөресе шул, Курчак театрына артист буларак кабул ителгән кешеләр торыр урынсыз, теркәлүсез, ярымач иде.

Әйе, пародия өчен рәхмәт әйтмиләр, үпкәлиләр, хәтта каргыйлар иде. Шул ук Роберт Әбүл бик шәп пародист иде, мәрхүм, беренче ШТМда ул танылган опера җырчысы Мөнирә Булатова булып җырлаган иде. Гаҗәеп шәп пародия иде ул, тавышы, үзен тотышы, барысы да югары сәнгать дәрәҗәсендә эшләнгән чыгыш иде ул. Тамашадан соң кемдер артистканың үзенә: Роберт Әбүл сезне сәхнәдә мыскыл итте, дип барып әйткән дә, әлеге ханым Әбүлне очратып, үпкәсен сөйләгән. Иң уңышлы номер буларак, тамашачы күпме генә сораса да, Әбүл кабат шул шәп пародиясен кабатламады. Ул артистка белән ара бозылудан курыкты булса кирәк…

Пародия өчен рәхмәт әйтмиләр, үпкәлиләр, хәтта каргыйлар. Шагыйрь Зөлфәт Гариф Ахунов булып бик оста сөйли иде, Гариф абыйның татарча аһәң белән урысча сөйләве, сөйләгән саен бер үк сүзләрне кабатлавына менә дигән дусларча шаяру иде Зөлфәтнең чыгышы. Гариф абый да Зөлфәткә үпкәләп йөрде. Бигрәк тә Ахунның хатыны Шәһидә апа ачулана иде, ул хәтта безне чакыртып орышты да.

— Гариф абыегыз олы кеше, депутат Верховного Совета, туктатыгыз бу эшегезне! - дигән иде.

Дусил Касыймов драматург Хәй Вахитне бик яхшы «уйный» иде. Равил Шәрәфи исә Хәким Сәлимҗанов булып сөйли башласа, көлке чыганагына әверелә. Мин Сибгать Хәким булып кыланырга остарып киттем. Шушы составта без бервакыт ШТМ да «Худсовет утырышы»н күрсәттек.

Зөлфәт Гариф Ахун булып җыелышны башлый:

— Туаришши! Среди нас сидит адин русский писатель — Рустем Кутуй, паэтому я вынуҗден прачитайт свой даклат на русском языке. У нас, у многонациәнәлного наруда иес адин пагавуркы: әдин рукав пинҗәкә никәгдә не бывает каруче другой рукав пинҗәкә…

Халык чыдый алмыйча көлә.

«Сибгат Хәким» сүз ала:

— Аны… урысларда сигез меңләп язучы бар… без белгәне егермеләп булыр… әнә… казакъларда өч йөз язучы… бездә нибарысы йөз егерме генә союз члины… сан кирәк хәзер союзларга… казакъларда язмаганны да союзга алалар… Бу яза бит әле — алыйк!

Тамашачы гөрләтеп кул чаба.

«Хәй Вахит» та сүзгә кушыла:

— Әйе, әйе, алырга кирәк Мостафа Ногманны союзга, ул чыннан да Лилин турында шигырьләр яза бит… Мин дә шигырьдән башлаган идем бит, әнә драматург булып киттем, хи-хи-хи… Ә драматурглар мәсъәләсендә менә миннән үрнәк алыгыз, иптәшләр, хи-хи-хи… мин елына икәшәр, өчәр пьеса куйдырам Камал театрында, хи-хи-хи…

Халык чыдый алмыйча көлә.

Зөлфәт-Ахун шаркылдап көлеп утыручы тамашачыларны каләме белән графин кагып туктатырга тырыша:

— Шаулашып-көлешеп утырмагыз әле залда, монда җитди җыелыш бара, туаришши… Рустем Кутуй, куда пашул! Субрание ишшу ни кончился бит… Шәйхи абый Маннур, тәмәкеңне җыелыш беткәч тартып керерсең!.. Хәзер сүз атаклы артист, татар классикасын сәхнәләштерүче «Хәким абый Сәлимҗанов»ка бирелә.

Равил Шәрәфи нәкъ Хәким абзый булып торып баса,

калтыранган куллары белән битен сөртеп ала:

— Марсил улым, син нишләптер бу арада атаңның инссинировкаларын куймый башладың, әллә үпкәләдең атаңа! Минем «Татар хатыны ниләр күрсәтми» дигән инссинировкамны ни өчендер туктаттыгыз? Бер Туфан Миңнуллин белән генә театр алга бара алмый бит инде...

Залдагы алкышларны, залдагы көлешне тасвирлап бетереп булмас иде. Кайберәүләр Сибгать абыйга, Хәким абый Сәлимҗанов янына барып: Батулла белән Шәрәфи сезне мыскыл итте, дип әләкләгән. Хәким абый Сәлимҗанов кинорежиссер Фатих Шәрәфиев белән Равил Шәрәфиевнең сөйләшеп торганын күреп, алар янына килгән дә, калын-олы гәүдәле Фатих абыйга ишарә итеп:

— Монда ике Шәрәфи бар. Берсе — тук Шәрәфи, — Чандыр, озын Равилгә ымлап ул: — Икенчесе — чүп Шәрәфи, — дип китеп барган.

Сибгат абый да миңа бик каты үпкәләгән иде. Гәрәй Рәхимгә ул минем турыда болай дигән:

— Әйттем мин шул Батуллагызга... каты әйттем... Артис булалмадың... режиссёр булып карадың, барып чыкмады... язучы булырга тырыштың — булмады... хәзер даһиларны мыскыл итеп йөрергә генә калдың инде, дидем...

Берничә тапкыр ШТМга килеп карагач, Сибгат абый үзгәрде, акыллы карт аңлады: пародия ул — мыскыл итү түгел, пародия ул теләсә кемгә тәтеми, пародия ул бары тик мәшһүр шәхесләргә генә эләгә!

Илһам Шакировка бер генә артист та пародия ясый алмады. Ринат Таҗидан башка. Таҗиның Илһам булып җырлавы

ШТМ – 2013 җиңүчеләрен Татарстан Мәдәният министрлыгының традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Фәнзилә Җәүһәрова белән жюри рәисе, танылган әдип Камил Кәримов тәбрикли

ШТМ да иң уңышлы чыгышларның берсенә әверелде. Илһамга пародия ясар өчен тавыш кирәк, моң кирәк һәм Илһамның башкару манерасын да яхшы белергә кирәк иде. Ринат Таҗи әнә шул якларын тотып алган, Илһамның бормаларын отып алган иде, бу пародияне һәрвакыт сөеп каршы алалар иде.

Драматург Данил Салиховның Габдулла Рәхимкулов булып җырлавы да пародия шәкеленең алгы урынында тора. Аның чыгышын да кат-кат кабатлаталар иде.

«Галиябану» пародиясе дә уңыш казанды. Пародиянең авторы — Батулла, Галиябану ролендә — Вафирә Гыйззәтуллина, Хәлил ролендә — Рафаэль Сәхәби, Исмәгыйль ролендә — Сәлим Мифтах.

Сәхәби-Хәлил җырлый-җырлый сәхнәгә чыга. Тәрәзә пәрдәсе ачыла, тәрәзәдә Галиябану-Вафирә башы күренә, ул да җырлый, дуэт башкарыла. Сәхәби Вафирәне тәрәзәдән тартып ала, ул исә «авыр», Сәхәби аны көчкә күтәрә, егылып китә яза. (Халык көлә.) Кочаклашып үбешкәндә генә кача-поса пират киемендә, бер күзе кара чүпрәк белән бәйләнгән Исмәгыйль-Сәлим чыга. Аның кулында — алтатар.

Сәлим. Хәлил, кит Галиябану яныннан, юкса мин сине как шандарахну! (Халык көлә.)

Вафирә (артык куркыккан булып). Исәмгыйл абый, атма! — дип гәүдәсе белән Сәхәбине каплый. Сәлим аны бер кырга алып ата.

Сәхәби алтатар көпшәсе алдында коелып төшә.

Сәхәби. Ты чего, Исмай! Ты из-за этой чувихи что ли?

Сәлим. Молчать!

Сәхәби (кунычыннан хәнҗәр чыгарып Сәлимгә кизәнә). Мин сине хәзер сасы кәҗә тәкәсе кебек бугазлыйм!

Вафирә. Хәлил, пычагыңны әрәм итмә шуның канына буяп!

Сәлим. Атам!

Сәхәби (кинәт пинҗәген ачып җибәрә, бер шешә аракы, колбаса күренә).

Сәлим. Давай, наливай-ка! (алтатарын Галиябануга бирә, Сәхәби шешәсен, кабымлыкларын өстәлгә куеп, колбаса турый, Сәлим аракыны стаканнарга бүлә, егетләр Галия-

Шаян-шук күңелле җитди жюри бәя куярга әзерләнә

бануны онытып, пирәшлиләр. Галиябану, алтатарын күкрәгенә кыскан көе, җыр башлый. Җыр барышында Сәлим исереп егыла. Сәхәби исерек җыры җырлап чыгып китә).

Вафирә. Ундүрт яшьтән сөешеп үсеп, каушау насыйп булмады!

Икенче яктан Сәхәби кулына соскы тотып чыга да, соскысын күтәреп, Вафирәнең алтатарны чигәсенә китергәнен гамьсез генә күзәтә. Вафирә, җырын тәмамлап, чигәсенә көпшәне тигезгәндә Сәхәби соскысы белән идәнгә сугып шартлау тавышы чыгара. Вафирә ава. Сәхәби бик мөһим бер эш башкарган кебек, ике кулындагы тузанны кагып, вәкарь белән генә Галиябану һәм Исмәгыйльнең өстеннән атлап чыгып китә.

Миниатюра тәмам. Зал шартлап кул чаба. Бу пародияне икенче елны да кабатлаттылар.

Ләкин олы буын вәкилләре арасында тәнкыйтьчеләр дә табылды:

— Изге Галиябануны, татар классикасын мыскыл итү ярмый! — дип байтак мыгырданып йөрделәр.

ШТМ ДӘВАМ ИТӘ

Ике ел Мәскәүдә укыган чагымда да (1977-1979) ШТМны ясый идек. Казандагы оештыру эшләрен, билетлар бастыру, белдерүләр элү, мин язган миниатюралардагы рольләрне артистларга тарату эшләрен Фирдәвес Хәйруллина башкара иде. Төгәл, җиренә җиткезеп башкара торган иде, мәрхүмә. Шулай беркакыт мин ШТМга Мәскәүдән ике кунак алып кайттым. Үзбәк шагыйре Торсынбай Адашбаев белән әзәрбайҗан язучысы Риза Фазыл иде кунакларым. Алар шаккатты. Быркылып торган юмор, шартлап көлүләр залны гына түгел, кунакларны да яктан еккан иде. Шунда Риза әфәнде әйтеп куйды:

— Сезнең тормышыгыз шактый авыр-мөшкел бит, сезне кысалар, ә сез һаман көләсез! — диде.

Мин дә әйттем:

— Дустым Фазыл, тарлавыкка китереп кыссалар, көлми нишлисең?! Татарлар елмаеп үлделәр! Җылап ни файда!

ШТМ программасында «Гайбәт авыз иҗаты» исемле миниатюра бар

иде. Анда өч карчык татар сәнгате өлкәсендәге яңалыклар турында сөйләшеп утыралар. «Илһам Шакировны Усман Әлмиев үтергән икән», дип башланып китә иде ул. Беренче сүзеннән үк халык көлә башлый, кәмит беткәнче көлке дәвам итә. Бу пародияне яулык кына бәйләп, өч егет башкарган иде. Ул әле дә булса уйнала иде, төп нөсхәсеннән аермалы буларак, яңалыклар белән баетылып, «Мөршидә белән Хөршидә» исеме белән Илтөзәр белән Радик һәм «Мунча ташы» театрының атаклы артистлары Шәмси белән Гамил тарафыннан гел-гел уйналып торды.

ШТМ (Шаяннар-тапкырлар мәҗлесе) исемле сатира, пародия-юмор театры, 17 ел яшәгәннән соң (1986 елда) үзеннән-үзе туктады, сүрелде, сүнде. Ләкин ШТМ үлмәде, аннан «Салават күпере» исемле кече күләмле әсәрләр театры бүленеп чыкты, театрның җитәкчесе — Шамил Галиуллин, баш режиссёры — Батулла иде. Анда яшь артистлар белән бергә Шәрәфи, Шамкай, Гөрпинә, әдәби пародияче Ләбиб Лероннар катнаша иде. Бу театр ике елга якын яшәгәч, таралды. Аннан соң «Зәй утлары» театраль миниатюралар халык театры (җитәкчесе — Ринат Гәрәев), «Мунча ташы» театры (җитәкчесе — Шәмси Закир), «Шаян сәхнә» (Камил Кәрим), «Шаян шоу», «Биш татар» (җитәкчесе — Алмаз Хәмзин) коллективлары барлыкка килде.

Шулай итеп, пародия шәкеле татар эстрада сәхнәсендә көннән-көн лаек урынын яулый бара, хәзер пародиячесе булмаган бер генә концерт коллективы да юктыр, мөгаен. Шунысына шөкер итәм, пародия өчен хәзер артистларны тотып тукмамыйлар. Өйрәттек бит тәки! Ләкин бүгенге пародия әһелләре бу жанрның асылын аңламый кебек. Алар көлке ясарга кылана гына кебек тоела миңа. Ир кеше хатын киеме киеп, артык бизәнеп, артык кыланып сәхнәгә чыкса, бу зәвыксызлыктан баш аска иелә, тамашаны ташлап чыгып качасы килә башлый.

Сүз иярә сүз чыккач, әйтеп китәргә кирәктер, мөгаен. ШТМны таныту, аны үстерү өлкәсендә «Татарстан яшьләре» гәҗите бик тә мактаулы эш башкара килде. Көлке көннәренә аерым битләр багышлап, ШТМ буласын алдан ук хәбәр итеп, белдерүләр бастырып, ШТМ узгач, анданиләр булганын укучыларга сөйләп, сәхнәдә уйналган кәмитләрне бастырып чыгарып, «Т.Я.» ШТМны үстерде, үзе дә үсте, шөкер.

Татар халкында сатира булмаган, ШТМ булмаган, дип сөйләүчеләр, беренче КВН 2004 елда гына булды, дип язучылар — үзләре адәм көлкесе бит инде. КВН (Клуб весёлых и находчивых) ны 1969 елда ук без ШТМ (Шаяннар-тапкырлар мәҗлесе) дип гамәлгә керткән идек бит инде, ШТМның тагын бер тирән мәгънәсе бар — «шытым», ягъни «нәсел, дәвам, алмаш» дигән сүз дә бит әле ул ШТМ. Нигә инде шул матур гыйбарәне «ШТК» дип үзгәртергә? «Клуб» сүзен турыдан-туры тәрҗемә итүгә караганда җыен, җыелу урыны «мәҗлес» дип алу отышлырак түгелмени? «Мәҗлес» сүзе татарда бары тик ашау-эчүне генә аңлатмый, халык хөкүмәтен «Милләт мәҗлесе» дип йөртү дә, «клуб» урынына «мәҗлес»не куллану да сөйләм теленә дә, язма телгә дә уңайрак.

Яшәсен «Шаяннар-тапкырлар мәҗлесе» — ШТМ!

Редакциядән: *Озын-озак еллар тукталып торганнан соң, ШТМ хәрәкәте, ниһаять, моннан ун еллар чамасы элек, җанланып китте. ШТМны тергезүгә ул чагында Татарстанның Мәдәният министры урынбасары булып эшләгән Илфак Ибраһимов (Рабит Батулланың шәкерте, шагыйрь Мөхәммәт Мирза) күп өлеш кертте. Хәзерге ШТМ исә Республиканың традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Фәнзилә Җәүһәрованың зур тырышлыгы белән дәвам итә.* ■

Мирасворд

... Бакыр шлем (иск.)

Габдулла ... (дин эшлеклесе, нашир, педагог)

... Абзгильдин

Актриса ... Гарбо

Суга юл ачу

Татар халык жыры

Касыйм һәм Казан ханы

Ныгытма, кальга

Татар халкында өйне бизәү җиһазы

Киптерелгән абрикос

Дини бәйрәм

... Гумилёв

Фин-угор халкы

Сорау алмашлыгы

1908-1917 елларда Оренбургта чыккан журнал

... Синха (санскрит грамматиты һәм шагыйре)

... Шә (кытай әдибе)

Боерык, фәрман

«Диване лөгатет төрк» сүзлеге авторы

Рахит (иск.)

Ишарә

Алтын Урданың Көнбатыш олысы идарәчесе

1917 елда Казанда Шәһит Әхмәдиев чыгарган газета

Шагыйрь Мәүла ...

Композитор Бату ...

Берәр нәрсәнең чите, яны

Элек җир өчен крестьяннардан алынган салым

Борынгы грек астрономы һәм математигы

Балетмейстер ... Таһиров

Язучы ... Хафизова

Татар фольклорында такмаклап башкарылучы җыр

Очкыч

Польша каласы

Актер ... Пачино

Колак, тамак, борын табибы

Япония автомобиле

1906-1918 елларда Казанда чыккан газета

Юкәдән үрелгән кәрзин (диал.)

Калкансыман биз авыруы

Рәис Габдулла төзеде.

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: сөлес, Фаяз, Верде, ирү, Зәки, рәкабәт, им, кяр, Нил, Кира, Окс, ирән, Расих, тел, егәр, кыпчак, Чак, гаян, Батырша, най, янар, өяз, «Пе», урак.
Өстән аска: «Суверенитет», Ге, лар, Кәлилә, хөр, Сөембикә, нык, Әминә, яр, язу, Кашан, «Карчыга», апа, Фәүзия, ирек, рә, рос, чин, ялик, ки, Исхакый.

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
Елъязмасы / ноябрь

- **210 ел элек (1804)**

17 ноябрьдә Казан университеты ачыла. 2010 елның 2 апреленнән – Казан (Идел буе) федераль университеты.

- **200 ел элек (1804)**

Тел галиме, мәгърифәтче Габдүш (Габдулла) Әхтәм улы Ваһапов (1814-1876) дөньяга килә.

- **120 ел элек (1894)**

17 ноябрьдә тел галиме, педагог, филология фәннәре докторы, профессор Латыйф Җәләй (1894-1966) дөньяга килә.

- **110 ел элек (1904)**

25 ноябрьдә дирижёр, скрипкачы, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык артисты Ильяс Әүхәдиев (1904-1968) дөньяга килә.

- **95 ел элек (1919)**

4 ноябрьдә «Кызыл Шималь» газетасы яңадан чыга башлый.

- **90 ел элек (1924)**

Галимҗан Ибраһимовның «Казах кызы» романы китап булып басылып чыга.

- **75 ел элек (1939)**

5 ноябрьдә «Кызыл Татарстан» газетасында Фатих Хөснинең «Әдәби мирас мәсьәләсе (Каюм Насыйри, Фатих Әмирхан, Дәрдмәнд)» дигән мәкаләсе басыла.

18 ноябрьдә Татарстан язучылар Союзының киңәйтелгән җыелышында шагыйрь Сәгыйть Рәмиевның әдәби мирасын җыю һәм өйрәнү турында карар чыгарыла.

- **70 ел элек (1944)**

1нче Белоруссия фронтында «Кызыл Армия» исемле татарча газета чыга башлый. Хәрби корреспондентлар: Гадел Кутуй, Ибраһим Гази, Гариф Галиев.

- **65 ел элек (1949)**

«Совет әдәбияты» журналында Әнвәр Давыдовның «Алтын көз» исемле поэмасы дөнья күрә.

- **55 ел элек (1959)**

23 ноябрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында Дәрдмәнднең тууына 100 ел тулу уңаеннан зур кичә үткәрелә.

- **25 ел элек (1989)**

26 ноябрьдә Уфада Галимҗан Ибраһимов исемендәге татар мәдәниятен сөючеләр клубы Гаяз Исхакый иҗатына багышланган кичә уздыра. Анда галим һәм язучы Ибраһим Нуруллин «Гаяз Исхакыйның татар әдәбиятында тоткан урыны» дигән темага лекцияләр укый.

ИЛЬЯС АЙДАРОВ

Александровлар пассажы.
Кәгазь, акварель. 2004 ел

Ильяс Сәйяр улы Айдаров 1956 елның 29 гыйнварында Казан каласында туа. Мәскәү Архитектура институтын тәмамлый. Аның иҗатына төрле алым-техника һәм жанрлар төрлелеге хас.

Ильяс Сәйяр улы — Россия Сәнгать Академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның халык рәссамы, атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Аның әсәрләре Европа, Азия һәм Америка кыйтгаларындагы шәхси һәм дәүләти тупланмаларда, галереяларда урын алган.

Шамил йорты. Кәгазь, акварель. 2004 ел

«Бөек Болгар өчен сугыш». Киндер, майлы буяу. 2014 ел

www.beznenmiras.ru

ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132
РОССИЯДӘ – 70275

Халкыбызның ерак гасырларга барып тоташкан бәяләп бетергесез бай тарихи үткәне, тирән тамырлы әдәбияты, мәдәни җәүһәрләре – милли мирасы бар. «БЕЗНЕҢ МИРАС» журналы битләрендә ерак гасырлардан сакланып килгән һәм әле моңа кадәр дөнья күрмәгән тарихи, дини-иҗтимагый хезмәтләргә, борынгы һәм хәзерге заман әдәбияты үрнәкләренә, сәнгать әсәрләренә бәйле мәгълүматларга киң урын бирелә, чорыбызның мөһим вакыйгалары, әдәбият, сәнгать яңалыклары яктыртылып барыла.

2015 елның беренче ярты еллыгына язы-лу бәясе –
420 сум

БЕЗ - МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «БЕЗНЕҢ МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!

12+

4 612750 670172